Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

07

июль 2022

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Барабаннар кемнеке дә, балалайка кемнеке?
41 бит

«Папайланган сары тузганак»
53 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +
07
(343)
июль 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

56

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Ямаш Игәнәй

ТАРИХИ МИРАС

4 Башкортларда һәм керәшен татарларында дәвалау ысуллары. *Н.Катанов*
11 Мамадыш районындагы керәшен авылларында борынгы мөселман зиратлары. *Н.Гариф*
17 Гасырларны берләштергән хезмәт. *В.Гали*
22 Апаз керәшеннәренең нәсел тамгалары. *Г.Закиров*
25 Бер төзелеш тарихыннан. *А.Казаков*
28 Ильяс Бораганиның кабер ташы. *А.Гайнетдинов*
30 Истанбул мәктүбләре. *Ф.Кәрими*
36 100 ел элек татар дөньясы
38 «Тәтеш тауларында чабып йөри идем...»

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хәсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

СӘНГАТИ МИРАС

41 Барабаннар кемнеке дә, балалайка кемнеке? *А.Чанышев*
46 «Бала уйнатканда» җыры

ТАТАР ГАМЕ

48 Нәҗип Нәккаш: «Әбидән калган Коръән кисәкләре җәлеп итте»
53 «Папайланган сары тузганак». *Е.Митюшкина, Л.Петрова*
56 Керәшеннәр каян килеп чыккан? *Р.Әхмәтҗанов*
60 Күренекле галим һәм педагог. *Г.Шакирова*
65 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

66 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
72 Ислам. Дини сүзлек
73 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*
74 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ӘДӘБИ МИРАС

76 Шагыйрь Сирин һәм Мөхәммәт Парсин. *Ә.Шәрипов*
80 Гомерләр уза икән ул... *Ф.Зариф*
86 Егор Уткин шигырьләре

ХӘТЕР САНДЫГЫ

87 Сыннар мәҗмугасы турында хыял. *З.Хәбипова*
93 Сугыш кайтавазы. *Д.Кәшипова*
96 Истә, һаман да истә!
98 Фани дөньяның бөек Бакые. *Х.Миңнегулов*

80

103 Юбилей мөнәсәбәтләре илә. *Л.Лерон*
106 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

108 Миләш

СИХӘТЛЕ МИРАС

109 Миләш дәвалый

ТАТАР РИЗЫГЫ

110 Түнтәрмә – куандырырлык тәмгә!

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Июль*

Заказ №О-1952. Тираж – 2285 данә. Формат 70х100 1/16
Басарга кул куелды: 29.06.2022. Чыгу көне: 06.07.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Резидә Яманованың «Чишмәләр» әсәреннән фрагмент

87

Җирне гөл итәм дигәннәр әйләнгән гөлгә,
Җирне көл итәм дигәннәр әйләнгән көлгә.

Ямаш Игәнәй



Шагыйрь, журналист, 1982 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстанның Сарман районындагы Ләке авылы тумасы Ямаш Игәнәй (Ананий Нестерович Малов, 1938-1997)

ЯМАШ ИГӘНӘЙ*

(10.01.1938-1.03.1997)

Авыл ызбасында керәшен туе –
Чал тарихның нәни ярчыгы.

***

Янымда чагында – зур түгел,
Бары тик шатлыгым чаклы син.
Янымнан киттеңме – зураеп,
Кояшлы күгемне каплыйсың...

***

Ир бәхете белән ир язмышы –
Шыткан гөлләр бер үк тамырдан.

***

Бәхетсезлек – кайгы һәм күз яше...
Үлем чәчсәң – кайгы һәм күз яше...
Ни чәчәсең икән – шул тишелер...

***

Кеше җаны – кыңгырау:
Кайгы какса, шалтырар...
Шатлык какса, шалтырар...
Кем ишетер – шул юрар...

*Шагыйрь, журналист Ямаш Игәнәй (Ананий Нестерович Малов) Татарстанның Сарман районындагы Ләке авылында туган. 1955 елда – Сарман урта мәктәбен, 1958 елда – Лубян урман техникумын, 1967 елда Казан дәүләт университетының журналистика бүлеген читтән торып тәмамлый. 1965-1978 нче елларда Ямаш Игәнәй Баулы һәм Мамадыш район газеталарында хатлар бүлеге мөдире булып эшли, 1993-2001 нче елларда исә керәшен татарлары өчен татарча һәм русча чыккан «Керәшен сүзе» газетасының җаваплы мөхәррире вазыйфасын башкара. Ямаш Игәнәй 1997 елның 1 мартында Чаллыда вафат булды һәм туган авылы зиратында җирләнде.

Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде. ■

Башкортларда* һәм керәшен татарларында дәвалау ысуллары

Николай Катанов

Керәшен кызларында дәва бар. ***Рамил Гали фотосы***

Әлеге мәкаләдә тәкъдим ителгән дәвалау ысуллары имче карт һәм карчыклар – халык табиблары ярдәмендә гасырлар дәвамында тупланган тәҗрибә нигезендә гамәлгә ашырылган. Кендек әбиләреннән, имче һәм сөннәтче бабайлардан, борынгы дәвачылардан килгән традиция хәзерге көндә өзелде дияргә дә була. Шунлыктан бу язмаларны элекке кешеләрнең яшәү рәвеше, рухи дөньясы, матди булмаган мирасыбыз буларак кабул итүегезне һәм аны дәвалау практикасында кулланмавыгызны үтенәбез. Әмма тарих тәгәрмәченең гел әйләнеп торуын онытырга ярамый. Медицинада оптимизация һәм коммерция дәвам итсә, халкыбыз әлеге ысулларга кире кайтырга бик мөмкин. Табигатькә һәм кешеләргә мәхәббәтне арттыру өчен дә кайбер ырымнарга игътибар зыянга булмас дип уйлыйбыз.

Редакциядән

* Биредә сословие, ягъни социаль катлау күз уңында тотыла. Бәләбәй өязендә башкортлар яшәмәгән диярлек.

1897-1898 нче елларда Уфа губернасының Бәләбәй өязе керәшен татарларында һәм башкортларында мин ике төркемгә бүленгән дәвалау ысуллары белән таныштым: беренчесе – дини кагыйдәләргә таянган (ислам һәм христиан диннәре), икенчесе – яшәү-көнкүрешкә, тормыш тәҗрибәсенә һәм төрле уйдырмаларга нигезләнгән им-том рәвешләре. Беренче төркем инде ярыйсы ачыкланганлыктан, икенче төркемгә кергән ысулларга җентеклэбрәк тукталып китәм.

Башкортларда да, керәшен татарларында да төрле ышанулар һәм сынамышларга нигезләнгән дәвалау ысулларын кулансаң, авыруларның, барысыннан булмаса да, байтагыннан арынырга була. Кешеләргә ул зәхмәтләрнең күпчелеге, башкортлар һәм керәшен татарлары аңлавынча, ике җенестән дә булган явыз рухлар тарафыннан иңдерелә. Халыкта ул рухларга каршы торырлык дәвалар бар, ләкин алар, картлар ышануынча (ә карчыкларда башка фикер), барлык авыруларны да савыктыра алмый. Зәхмәт китерүче рухларга каршы, картлар әйтүенчә, башкортларда – мулла догасы, керәшен татарларында священник (поп) келәве иң көчле чара.

Соңгы 20-30 елда, картлар күзәтүенчә, урыс халкы килгәннән соң, рухларның күбесе, халыкны бимазалау-борчу гадәтләрен ташлап, башка урыннарга киткәннәр. Менә Агыйделдә дә Су анасы үзенең галәмәтләрен күрсәтми – ул бөтенләйгә киткән яисә тыйнакланган булырга тиеш.

Кайбер башкортлар һәм типтәрләр миңа Су анасының холкы үзгәрү сәбәбен Агыйделдә Якимовлар пароходчылыгы эшли башлавы белән бәйләп аңлаттылар. Шүрәленең дә шуклык-шаярулары беткән дип санарга була. Ул хәзер Урал тавы битләрендәге чиксез кара урманнарда тереклек итәргә ниятләгән. Рухларның күбесе урыслардан курыкканлыктан, урыс авыллары тирәсендә бөтенләй күренми.

Башкортларда дәвалау ысуллары

Дәвалау ысуллары турында сүз башлаганчы башта бераз авырудан саклану турында сөйлим:

• Кичке якта җиргә егылмаска. Егылганның өстенә өй иясе яисә абзар иясе утыра – кеше авырый башлый.

• Зиратка, бигрәк тә яңа мәет җирләнгән көннәрдән соң, керергә ярамый. Анда убыр, ут ягып, саксыз динсезләрнең җаннарын яндырып утыра.

• Авырлы хатыннарның балалары телсез, чукрак яисә авыру булып тумас өчен, ирләренә кояш баеганнан соң күзгегә карарга ярамый.

Күз авырту. Күзләр авыртса, чәй чүбен (заварка), чүпрәккә төреп, авырткан күзгә куясы. Файдасы тимәсә, күзләрне шар формасындагы яхшы сабын белән юарга.

Баш авырту. Башы озак авырткан кеше муллага бара. Мулла кәгазьгә баш авыртуыннан дога яза. (Төрле авыруларга кагылышлы догалар җыентыклары Казанда унар мең данә басылып тора.) Ул доганы укый, як-якны өшкерә, дога язган кәгазьне авыруның башына бәйли һәм авырту бетә.

Теш сызлавы. Теше сызлаган кеше тәмәке тартса – авыртуы бетә.

Очкылык тоту. Очкылык тота икән – димәк, кайдадыр, кемдер искә ала. Әлегә бу хәлгә каршы чара юк.

Йөткерү. Йөткерү башланса, кеше борыч эчә яисә ашый. Шуннан йөткерү туктый.

Кан алдыру. Кешенең каны артык күбәеп китсә, ул борчый башлый. Аның артыгын алдырырга кирәк. Кан алдыру өчен иң кулай вакыт – язгы сука чоры, шимбә көннәре.

Бизгәк. Бизгәк – кешегә оялаган явыз рух. Аны куып чыгарыр өчен, йоклаган кеше янына кинәт килеп өстенә салкын су сибәргә кирәк: явыз рух куркып чыгып кача. Башка ысул да бар. Бизгәк ирләрдә булса, ул хатын-кыз рәвешендә курчак ясый, хатын-кызларда булса – ирләр рәвешендә. Авыру, курчакны күлмәк эченә бәйләп, бер-ике көн шуны киеп йөри. Бизгәк, курчакны кеше дип белеп, аңа күчә. Курчакны урамга чыгарып ыргыталар һәм авыру савыга. Тагын бер ысул: ярканат канатын кисеп алып чүпрәккә төрәләр дә күлмәк эченә бәйләп кияләр, бизгәк ярканаттан куркып кешедән китә.

Томау. Томау төшкән кешенең чәенә борыч салып бирәләр. Файдасы тимәсә, мәтрүшкә үләненнән чәй ясап эчерәләр.

Пешкән җәрәхәт. Кешенең кулын яисә аягын кайнар су пешерсә, җәрәхәтенә күп итеп агач мае сөртәләр.

Өшетү. Кешенең бармаклары, колагы өшесә, шулай ук агач мае сөртәләр.

Таз, кутыр. Тазлы урынга сыер мае сөртәләр, ләкин урыс табибына бару яхшырак.

Эч китү. Авыруның чәенә караҗиләк салып эчерәләр, эч китү туктала.

Күз тию. Әгәр дә берәрсе, көнләшеп, кешегә: «Кара әле, нинди матур, нинди яхшы!» – дип әйтсә, ул авырый башлый, зәгыйфьләнә, үлеп китүе дә бар. Шундый нәтиҗәләрне кисәтү өчен, авыруга агач гөмбәсе төтенен иснәтәләр – ул савыга.

Акылдан язу – шашыну. Җиңел рәвештәге авыруны мулла Коръән сүрәләре укып төзәтә, авыр хәлдәгеләрне урыс табибы гына савыктыра ала.

Эт тешләве. Кулны, аякны эт тешләсә, ярага агач мае сөртәләр яисә эч мае ябалар.

Сызлавык. Сызлавык чыкса, куян тиресе кисәген кайнар суда тотып, аны эчке ягы белән ябалар. Ул сызлавыкны суырып ала, кеше савыга.

Керәшен татарларында дәвалау ысуллары

Керәшен татарлары хастаның күбесен явыз рухлар гамәле дип саный. Алар зыян салырга кешенең ялгышканын сагалап кына тора: йә ярлылык, йә уңышсызлыкка дучарлык, йә авыру зәхмәте китерәләр. Саклану өчен уяу булырга, әби-бабайлар сүзен онытмыйча, бик сак йөрергә кирәк. Сынамышларның начары да, яхшысы да була. Аларны санап китеп, дәвалау ысулларына күчәрбез.

• Утын яисә башка йөк төялгән арба очрау тазалык, уңыш китерә.

• Юл аркылы узучы елан – тазалыкка, уңышка; каршыга килүчесе – авыруга, уңышсыз нәтиҗәләргә.

• Кыр эшләре башкарганда буразнага, ызанга ятып йокларга ярамый – чирлисең.

• Кичке якта берәү егылса, аның өстенә явыз рух утыра, ул авырый башлый, авыруны кисәтү өчен, рәттән өч мәртәбә төкерергә кирәк.

• Төнлә көзгегә карарга ярамый, сукыр калуың бар.

• Җирдәге ят кеше кисеп ташлаган тырнакларга бассаң, авырып китүең мөмкин, чөнки башкаларга яхшылык теләүче тырнак кисәкләрен идән астына җыярга тиеш.

• Кайбер кешенең балалары еш үлә. Озак яшәсен өчен, яңа туган баланы тәрәзәдән атасына бирәләр дә: «Мин бала сатам, аласыңмы?» – дип сорыйлар. Ата кеше бала сатучы әбигә 3-5 тиен акча бирә, шуннан соң баланы буучы өй иясе аларга тими башлый.

• Яшен – Алланың агачлар яисә этләр артына качарга яраткан явыз рухларга аткан уклары. Шунлыктан, яшенле яңгыр вакытында, үлемнән яки авырудан сакланыр өчен, агачлар, этләр янында торырга ярамый.

• Өй иясе еш кына бала тудыручы хатыннарның, күкрәк балаларының, өлкәннәрнең тыннарын кыса, буа. Бу хәлдән догалар гына коткара ала.

• Елга һәм таулыкларда явыз рухлар була. Алар атларны, кешеләрне куркыталар, төрле авырулар китерәләр. Шул кабахәтләрнең берәрсен күреп, куркып, юлда ат туктаса, балта яки пычак алып, чукынып, ат-арба тирәсен өч мәртәбә әйләнеп, җиргә сызык сызарга кирәк. Явыз рух, биредә эшнең җитди икәнлеген күреп, бик тиз качып китәчәк.

• Өермә эчендә явыз рух утыра, аның кеше эченә дә керүе йә авыру газаплары китерүе мөмкин. Шул хәлләрне булдырмас өчен, чиксез рәхимле Ходай Тәгалә исеменнән: «Безгә кагылма, килгән җиреңә кит!» – дип әйтергә һәм артыннан өч мәртәбә төкереп калырга кирәк.

• Терлек абзарында атларны яратып, ялларын үрүче рух яши. Мал-туарны яратмаса, ул аларны интектерә, ә хуҗага авыру зәхмәте йә борчулы сагышлар китерә. Күңелсез хәлләрдән сакланыр өчен, терлек абзарына кергәндә сызгырып, малтуар рухы телендә ым бирергә кирәк.

• Кояш баеганнан соң, Су рухы еш кына озын җирән чәчләрен тарарга ярга чыга. Бизгәк тоту, хәлсезлек, салкын тию – аның кылмышлары. Шунлыктан кичке якта елга һәм сазлыклар тирәсенә якын бармаска кирәк.

• Зур урманнарда кешене исеме белән чакырып алып, кытыклап үтерүче рух яши. Урманда зур саклык белән йөрергә, чакырган тавышларга җавап бирмәскә кирәк.

• Кызамык, чәчәк – мунчада яшәүче хәтәр рух гамәлләре. Кызамык, чәчәк авырулыларны мунчага кертмәскә кирәк. Югыйсә мунча хуҗасы булган рухның авыру кешене бөтенләй эштән чыгаруы ихтимал.

Әгәр кеше, әйтелгән очракларда саклана калса, төрле авырулардан котылып кала.

Хәзер инде авыру хәлдәге керәшен татарларының ничек дәвалануларын күзәтеп китәбез.

Күбенү. Корсак күбенгәндә уклау алып тугыз тапкыр: «Юл читенә китсен!» – дип кабатларга, әйткән саен корсак ягына төкерергә кирәк. Авыруны кабат китермәс өчен, болан мөгезе сыныгы кисәген хач белән янәшә муенга тагарга кирәк.

Күз авыртуы. Күз сызлап авыртса, аңа елан кабыгы бәйлиләр, чөнки бу – еланнар патшасы эше. Елан кабыгына җиде яисә өч мәртәбә чиксез рәхимле Ходай Тәгалә исеменнән: «Түгәрәк елан, җиз елан, кит! Китмәсәң, башыңа эләгер миннән!» – дип әйтәләр. Авыру елан кабыгына күчә, күзләр төзәлә. Бу им булышмаса, юл буеннан яфрак алып, шул ук сүзләрне әйтеп, аны күзгә бәйлиләр.

Бүсер. Авырткан урынга: «Каты бүсер, нык бүсер, кит моннан! Китмәсәң кирәгеңне бирермен!» – дип, өч мәртәбә кабатлыйлар. Аннан соң шул ук сүзләрне аракы яисә тозлы суга әйтеп, авыруга эчерәләр.

Кан алдыру. Кешене борчый башласа, канын алдыралар. Иң кулай вакыт – айның кимү чоры. 40 яшьтән өлкәнрәкләргә кан алдырырга ярамый.

Кан агу. Балта, пычак белән киселгән урыннан аккан канны туктату өчен, җәрәхәткә өч мәртәбә: «Кызыл энә белән, кызыл җеп белән кызлар җөе тегәм! Бакыр энә белән, бакыр җеп белән бакыр җөй тегәм! Тимер энә белән, тимер җеп

белән тимер җөй тегәм!» – дип әйтәләр. Шуннан соң кан агу туктый.

Бизгәк тоту. Су рухы кешегә һәртөрле әшәкелекләр кылганлыктан, кеше дә төрле чара эзли, аны дәваланудa куллана. Атның теш казнасыннан акыл тешен яктыга чыгармыйча алып, авыруның муенына асарга. Тагын бер ысул: авыруның муенына тере саескан телен алып асарга. Өченче ысул: авыру берәр кирәкле әйберне башы, гәүдәсе тирәсендә өч мәртәбә әйләндереп, урамга чыгарып ыргыта; бизгәк кирәкле әйбер белән урамга чыга, әйберне урамда табып алган кешегә ябыша. Дүртенче ысул: авыру, ялгызы калып, берничә тырнак, чәч очларын кисеп, таяк ярыгына яшерә, кеше күрмәгәндә урамга чыгарып ата; бизгәк урамда кала. Бишенче ысул: авыруның муенына ярканат асалар. Алтынчы ысул: бизгәк рухы елан патшасыннан курыкканлыктан, авыруның куенына кинәт көтмәгәндә яңа үтерелгән елан салалар, авыру куркып кала, кеше савыга.

Сию. Кешене еш, әмма әзләп сию интектерсә, мунча ташын табып, өстенә өч тапкыр сияргә, сигән чакта: «Бу чын дәва (им) булсын, зәхмәтем бетсен, мәңге кабатланмасын!» – дип кабатларга кирәк. Башка ысул да бар: хуҗалары күрмәгәндә пумалага 1-3 тапкыр сияргә. Өченче ысул: башка кешеләр югында сабан яисә сука өстенә сияргә. Дүртенче ысул: кеше югында тәгәрмәч тишегенә сияргә. Бишенче ысул: елга суында агымга каршы басып тугыз мәртәбә: «Тугыз ил артына китсен, җирдә бетсен! Мәңге булмасын!» – дип әйтергә. (Борынгы бабаларыбыз ышанууынча, елга һәм сулыкларга сию катгый тыела. Мондый гамәл сәламәтлеккә зыян сала.)

Тырнак бозылу. Тырнак бозылуны еланнар патшасы китерә. Бозылган бармакка елан кабыгы бәйлиләр, өч мәртәбә түгәрәк бакыр еланнарны куалар. Башка ысул: бармакка юл буенда үскән яфрак бәйлиләр.

Култык астындагы шеш. Кешенең култык астына каты шеш чыкса, аны мондый сүзләрне тугыз кат кабатлап имлиләр: «Тугыз юл узып кит, җиргә уп! Сине җил алып китсен! Килгән җиреңә китеп олак! Бер айда бет, бер көндә бет!» – диләр.

Өянәк тоту. Өянәкле кешенең күлмәген авыл читендәге баганага яисә кыр капкасына элеп куярга кирәк. Авыру күлмәкне алган кешегә күчә.

Кул киселү. Кул киселгән яра кутырласа, аны өч кат: «Кутыр бетсен, бакыр җиргә упсын!» – дип әйтеп дәвалыйлар.

Бала тапканда кызышу авыруы. Бу авыруның сәбәбе – бала табучыны явыз рух басуы. Аннан котылыр өчен, бала табучыга чәшкедән 5-7 мәртәбә: «Җирән атка атланып юртырмын, канатларын кагындырып, тоякларын типтерермен! Кит, мәлгун! Кит, кабахәт! Сиңа каршы чиксез көчле Ходай Тәгаләне чакырам!» – дип әйтеп, өшкерелгән су эчерергә кирәк.

Колак арты бизе шешү, күкрәк бакасы, дифтерит. Бу өч авыру – бакалар патшасы булган рух әшәкелекләре. Аларга өч кабат: «Бака, бака, юеш бака, нык бака, кит моннан, китмәсәң, мин сине Ходай Тәгалә исеме белән кыйнармын!» – дип әйтергә кирәк. Башка чара: бәләкәй кашыкка тоз алырга, өстенә бал салырга да өч мәртәбә: «Бака – баштан, тимер таштан бетәр! Аркасы белән бозга катсын, күкрәге белән комга батсын! Бер айда, бер көндә китсен!» – дип кабатларга. Аннан соң, балны, бармак белән алып, шешенгән урыннарга сөртергә. Өченче чара: авыртулы урыннарга тозлы май сөртәләр дә өч кабат: «Бака – баштан, тимер таштан бетәр! Борыны белән бозга катсын, аркасы белән комга батсын! Кит, артыңа карамыйча, кышкы көн булса да!» – дип әйтәләр.

Күз тию. Берәрсенең күзе тиеп, кеше интегә башласа, аны имән гөмбәсе төтенендә тотарга кирәк. Башка чара: күз тиюдән интегүчене имәннең кояш чыгы-

шы ягыннан җыеп яндырылган әкәләләре төтенендә тотарга һәм тугыз мәртәбә: «Сине кисәтәм, кара күз, сарык күзе, соры күз! Яман күз килгән җиренә китсен!» – дип әйтәләр. Өченче чара: күз тиюне куар өчен 5-7 мәртәбә: «70 кара егет күзе бу кешегә тимәсен, иске аяк киеменә тисен, бу кеше савыксын, күз тиюе килгән җиренә китсен!» – дип әйтәләр.

Сифилис. Төкереккә манчылган бармак белән 11 дарудан – канәфер, нашатырь, ачуташ (квасцы), күкерт, купорос, ак буяу, чикләвек һ.б. төеп ясалган порошок сөртәләр дә: «Ак алмачуар ат астында – алтын өстәл, өстәлдә ризык, бал! Сине шунда чакыралар! Шунда кит, биредә сиңа пычагым калмаган!» – дип әйтәләр.

Буылу. Чәй чәшкәсенә бер чеметем тоз салып, пычак белән болгаталар: «Ходай Тәгалә биргән чараны кулланам. Алтын пич тора, пичтә алтын таба, табада алтын алма! Шул алманы алтын кул, алтын чәнечке белән алган кеше буылу зәхмәте белән авырсын, бу кеше түгел!» – дип, өч мәртәбә әйтәләр дә суны авыруга эчерәләр. Бер мәртәбә алтын, икенче мәртәбә көмеш, өченче мәртәбә бакыр дип әйтү кирәк диючеләр дә бар.

Елан чагу. Елан чагуга каршы: «Сездән үтенәм, изгеләр, еланны куарга булышыгыз! Елан кыска койрыклы, кыска кара башлы, ике башлы ата елан, сары башлы кара елан, ялтыраган бакыр, чәчтән нәзек, кылычтан үткен! Ал моннан чаккычыңны, калдыр яхшылыгыңны!» – дигән өшкерү сүзләре әйтәләр.

Эт тешләве. Эт тешләсә, аның бер учма йонын кисеп алып, яндырып көйдерәсе дә җәрәхәткә ябасы. Котырган эт таласа, ул кешегә 41 йорттан берәр кашык су җыеп эчерәләр. 41 йорттан берәр телем икмәк тә җыеп ашаталар. Суны да, икмәкне дә ишектән түгел, тәрәзәдән җыялар.

Кара хәлсезлек. Бу зәхмәтне өч мәртәбә: «Әй сез, 88 ак тау астында яшәгән 88 ак елан, зәхмәтегезне алып китегез! Бу кешене борчымагыз!» – дип әйтәләр. Аннан соң кызыл, кара, сары, зәңгәр еланнарга сүз әйтәләр.

Керәшен татарларындагы им-том (әфсен-төфсен) сүзләре башлыча күрше мөселман, башкорт, типтәр һәм мишәрләрдән алып үзләштерелгәнлектән, сүзне мөселманнар кебек: «Бисмилла...» – әйтеп башлыйлар да: «Бу минем сүзем түгел, Әйшә-Фатима сүзе», – дип тәмамлыйлар. «Әйшә», «Фатима»ларның кем булуын керәшен татарлары белми. Шунлыктан алар исеменнән соң чукынып та куялар.

***

Уфа губернасының Бәләбәй өязендә яшәүче төрки халыклардагы медицина дәрәҗәсен санап кителгән дәвалау чаралары җитәрлек яхшы күрсәтә. Миссионер-священниклар фәнни медицина нигезләрен белмиләр. Рус табиблары бик зур төбәкләрдә эш алып барсалар да, башкорт телен дә, татар телен дә белмиләр, шунлыктан җирле халыкта әбиләрдән калган ысуллар белән дәвалау әле байтакка сузылыр. Алай дәвалану кыйбатка да төшми: бары – 3-5 тиен, кайсы очракта 15-20 тиен тора. Җирле халыкта: «Чирмешләр, чуашлар яхшы дәвалыйлар, оста күрәзәлек итәләр», – дип саныйлар, телләрен белмәгәнлектән, мин аларның ысулларын язып алмадым.

Төрки халыкларда кулланылган өшкерү сүзләре миндә байтак күп, тәртипкә салып бастырып чыгарылырлар.

Ахырда 1895-1898 нче елларда Казан татар матбугатында чыккан басмалар турында берничә сүз. Уфа губернасының Бәләбәй өязендәге муллалар сырхауларны – мөселман башкорт, мишәр, типтәр, татарларны һәм мәҗүси чуаш, чирмешләрне

шул басмаларга таянып дәвалыйлар. Муллалар әйтүенчә, аларга дәваланырга православныйлар да (татар, рус, чуаш, чирмешләр) киләләр.

1897 елда М.Чиркова варислары типолитографиясендә агалы-энеле Кәримовлар бастырган җыентыкта дога итеп кулланылган кыска Коръән сүрәләре китерелгән. Аларны өшкергәндә укып Ходай Тәгаләдән гөнаһларны кичерүярлыкау, байлык китерүне сорыйлар. Су басудан, янгыннан, кылычтан, пычактан, ярлылыктан, уңышсызлыктан, бик күп хасталардан (баш, йөрәк, кул, аяк) һ.б. саклауны сорыйлар. Шул ук догалар һәм әфсенннәр кешеләрне җир тетрәүдән, шайтан кагылуыннан, дошман зыяныннан саклый. Догалар һәм әфсеннәр хисапсыз могҗизалар кыла алалар: аларны хәтта фәрештәләр дә санап, язып бетерә алмас. Шулай ук «Дәвалау нәтиҗәсе чиксез» исемле җыентыкта һәртөрле авырулардан – баш авыртуыннан, күз тиюдән, убыр-сихерчеләр кагылудан; мылтык, кылыч зыяныннан, елан агуыннан, ашказаны чәнчүеннән саклаучы гарәп хәрефләре һәм цифрларыннан серле тезмәләр; шунда ук бичураларны, өй ияләрен, процентка акча бирүчеләрне (рибачыларны) куа торган хәреф-цифр тезмәләре китерелә. Бу могҗизалы тамгалар, галәмәтләр берәр әйбергә языла яисә, кәгазьгә язылып, бөти итеп йөртелә.

Сихри көчкә ия булган язмалар аерым кәгазь битләрендә «Янда йөртер өчен догалар» исеме астында бик зур санда басылалар. 1898 елда университет типолитографиясендә Ш.Хөсәенов варислары 50 000 данә бастырып чыгардылар. Әлеге догалар йокысызлыктан, туктаусыз елаудан, бичуралардан, баш авыртудан, өй ияләреннән, күз тиюдән, башлыча, балаларны саклыйлар. Каббалистик тезмәләр рәтендә мөселманнарга яраклаштырып, чиркәү тарафыннан 4 августта һәм 22 октябрьдә христиан изгеләре рәтендә билгеләп үтелә торган Җиде Ефес яшүсмере исеме дә язылган. Әлеге җиде яшүсмер һәм аларның этләре Кытмырның исемнәре балаларга туктаусыз елаудан котылуга булыша. Урыс халкында таралган ялган догаларда җиде яшүсмернең исемнәре элек заман өлкәннәргә нерв авыруларыннан, балаларга йокысызлыктан котылырга булыша дип санала иде. Казан татарларының башка җыентыкларында җиде яшүсмернең исемнәре кешене дошманнарыннан һәм рибачылардан коткара; кешене, аның малын уттан, судан, юлбасарлардан, ә игенне саранчадан саклый, имеш.

Ниһаять, кайбер муллалар пациентларын 1895 елны М.Чиркова варислары типографиясендә Тәтеш өязенең крестьяны Ибне Ямин Юсупов бастырган «Медицина кенәгәсе, кайбер даруларның файдасы» исемле җыентыкны кулланып дәвалыйлар. Җыентык гарәп теленнән тәрҗемә ителгән, күләме – 16 бит. Гарәп телендә китапны 980-1036 нчы елларда Бохарада яшәгән данлыклы гарәп юристы, философ һәм табиб Әбүгалисина язган, XV-XVI гасырларда аның хезмәтләре Көнбатыш Европа илләрендә киң таралган. Европада Авицена исемендә йөргән Ибне Синаның китабында бик күп даруларның исемнәре, үзенчәлекләре һәм кулланыш рәвешләре китерелгән. Тәрҗемәче кайбер даруларның тасвирламасын өстәгән һәм барысының да атамаларын рус телендә китергән. Кызганыч ки, бу китап мөселманнар арасында аз таралган. Төрле дарулар исәбендә биредә сарымсак, керосин, борыч, нашатырь, камфора, торма, суган, сөт, балавыз, бөтнек, төнбоек, имбир, дарчин (корица), мускат чикләвеге, канәфер (гвоздика) язылган. Дәвалау файдалары белән бергә, аларның косметика өлкәсендә кулланылышы да күрсәтелгән.

*Русчадан **Николай Петров-Текин** тәрҗемәсе* ■

Мамадыш районындагы керәшен авылларында борынгы мөселман зиратлары

Нурулла Гариф

Мамадыш районының без йөреп чыккан керәшен авылларының барысында да борынгы мөселман зиратлары бар. Россия борынгы дәүләт актлары архивыннан да җирле халыкның элек мөселман булып, төрле елларда чукындырылуы турында бай мәгълүмат алдык. Биредә керәшеннәрдән язып алган истәлекләрне һәм архив чыганакларын чагыштырып тәкъдим итәбез.

Албайда яшәүче Генадий Мишурин: «Борынгы зират урыны шушы инде».

Албай авылында яшәүче Анна Ивановна истәлекләре. Язып алынды: 29.09.2019.

«Авыл бик зур, бик күренекле иде. Элек бу татар авылы булган. Иван Грозный вакытында, чукындырудан куркып, Албай халкының батыррак, кыюраклары хәзерге Катмыш авылы урынына качкан. Урыслар, җир эзләп, Комаровкадан Албайга күчкәннәр. Бәйрәмнәрдә керәшеннәр – үзләре, урыслар үзләре аерым бәйрәм иткән. Хәзер монда урыслардан бер хатын гына калды инде. Иван Гроз-

ный Өчнарат, Саурыш авылларын да керәшенлеккә чыгарган булган. Алар хачларын ап-ак нигә төреп, сандыкка куйганнар да яңадан татарга чыкканнар.

Албайның уртасына өске яктан асфальт юл түшә бит. Менә шул юлга каршы ике йорт зират өстендә утыра. Берсе – Башуриннар, икенчесе Мишуриннарныкы. Элекке Албайның иске зираты шунда булган».

Урта Әрнәш-Албай авылының көчләп чукындырылганга чаклы документлары 1619[1], 1678[2], 1719[3], 1724[4], 1748[5] нче елларга карый. 1762-1770[6] нче еллар арасында уздырылган 3 нче ревизиядә исә Урта Әнәш кешеләренең чукындырылганын күрәбез. Биредә чукындырылган гаиләләрнең исемнәре татарча да, урысча да бирелгән. Шуңа да карамастан, анда әле татарлар яшәүләрен дәвам итәләр. Әмма, ревизия материалларыннан күренгәнчә, керәшеннәргә татар кызын килен итеп алырга яисә татарга кияүгә бирергә ярамаган. Татарларның да кызларын күрше авыллардагы дин кардәшләренә биргәнлекләре күренә. Шулай ук авылдан татар авылына күчеп китүчеләр дә булган. Мәсәлән, Күкчишмә авылына.

Югары Мәшләк авылында яшәүче Аркадий Новиков (1952) истәлекләре. Язып алынды: 27.09.2019.

«Без бәләкәй чакта радио баганасы суздылар. Менә шул багана төпләрен казыганда кеше башлары, сөякләр күп чыкты. Матур мәрҗәнле муенсалар да бар иде, тәреләр чыкканын хәтерләмим. Малай чагында шуларны кызыксынып карап йөргәнемне бик яхшы беләм. Хәзер ул телефон баганалары юк инде. Бу зират елга кырыенда, авыл уртасында урнашкан. Аннан аста чишмә дә бар. Бу тирәдә чишмәләр күп бит безнең: 100 метр саен чишмә».

1742 елгы архив документында Югары Мәшләк турында: «... новокрещенные из иноверцев», – дип язылган. Бу елда авылда 73 ир кеше яшәгән. Алдагы ревизиядә әлеге авылдан, чукынудан качып, Олы Мәшләккә күчкән татарлар да шул авылның ревизиясендә күрсәтелгән[7].

Югары Әрнәш-Казаклар авылы җирлегендәге борынгы «Татар зираты» турында

2018 елның 27 августында юл уңаеннан Югары Әрнәшкә кайтучы Генадий Егоров (1964) утырды. Мәшләк авылында туган. Сөйләшеп киттек. Тарих белән кызыксынуымны белгәч, ул Югары Әрнәш-Казаклар авылындагы фермалар янында борынгы зират булуы һәм бу турыда хатынының әтисенең апасы – **Мария апа**ның яхшы белүе турында әйтте. Мин аны Казакларга чаклы илтеп куйдым һәм без Мария апаларга кердек.

1938 елгы **Мария апа** сөйләгәннәрдән: «Зират турында Матрена түти сөйләде. Безнең авылның фермалары бар. Минем төп йортымның бакчасы шул

[1] РГАДА. Ф. 1209. Оп. 1. Дело 153. 1619 г.
[2] РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Дело 1102. 1678 г.
[3] РГАДА. Ф. 350. Оп. 1. Дело 160. 1719 г.
[4] РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Дело 1130. 1724 г.
[5] РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Дело 1143. 1748 г.; РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Дело 1155. 1748 г.
[6] РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Дело 1207. 1762-1770 гг.
[7] РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Дело 1143. 1742 г.

фермаларның беренчесенә терәлеп тора. Әүвәлрәк чорда бакчаның ул башы гел түмгәкле иде. Менә шул беренче ферма белән янәшәдәге елганың яры ишелгәндә кеше башлары чыга иде. Олы кешеләр элекке чорда монда зират булган дип сөйләшәләр иде. Матрена түтинең шул баш сөяген юып, күмеп йөргәнен ишетеп беләм. Зираты булгач, аның авылы да булгандыр инде, алары турында белмибез. Зират дигән урынның каршы ягында, тау өстеннән чишмә чыга. Хәзерге зират сугыш вакытында гына барлыкка килде әле. Аңынчы Албайга илтеп күмә идек».

Генадий Егоровның күршесе **Мария апа** (1939): «Безгә 5-6 яшьләр тирәсе булдымы икән, Матрена әби белән берничә тапкыр яр буенда чыккан сөякләрне күмәргә йөргәнне хәтерлим. Олы кешеләр аны «Татар зираты» дип сөйләделәр. Ул чакта анда кечкенә генә агачлар, каеннар үсеп утыра иде».

Безнең фикеребезчә, «Татар зираты» – авылның чукындырылуга чаклы булган зираты. Авыл кешеләренең бер өлеше качып киткән, икенче өлеше төп урынында калган һәм чукынган. 1742 елгы архив документында Югары Әрнәш турында: «...служилые, до прежней переписи крещены, состоящие подушном платеже с ясашными», – дип язылган. Боларның «чабаталы морзалар» булуы ихтимал. Авылда 19 ир кеше, барлыгы 4 гаилә яшәгәнлеге әйтелә.

Түбән Әрнәштә яшәүче Анна апа Кирилова (Кряшкова) (1927) истәлекләре

«Татар зиратының сукаланмаган килеш вакытын хәтерлим. Без бит сугыш вакытында Албайга укырга йөрдек. Шунда чирәмлек бар иде, бу – зират урыны, дип, анда кеше кертми торганнар иде. Аның дүрт ягында дүрт багана да бар иде. Күпмедер вакыт узгач, сукаладылар ул урынны. Сукалагач, төгәл урынын белүче кеше юк инде. Хәтсез зур урын иде ул. Әмма аның чирәме генә минем күз алдында. Без ул чагында бала гына бит әле. Өлкәннәр: «Олы, кече йомышларыгызны монда үти күрмәгез!» – дип кисәтеп торалар иде. Элек анда асфальт юл юк иде. Безнең авылдан чыгып Албайга барганда сул кул якта кала иде ул».

1742 елгы архив документында Түбән Әрнәш турында: «...до прежней переписи новокрещенные из иноверцев», – дип язылган. Бу елда авылда 34 ир кеше яшәгән.

Кече Сон-Колышчы авылында яшәүче Василий Максимов истәлекләре. Язып алынды: 29.09.2017.

«Без Колышчы авылы җирлегендә урнашкан, археологик истәлекләр исемлегенә кертелгән Болгар зираты янында басып торабыз. Зират урыны беренче тапкыр 1954 елда сөрелгән. Аңа чаклы бу урын болын, печәнлек җире кебек урын булган. Анда кабер урыннарындагы түмгәкләр беленеп тора иде, дип сөйлиләр. Бу урынны сөрергә безнең авыл трактористлары каршы булган. Шул сәбәпле, Түбән Сон авылыннан трактористны чакырып сөрдергәннәр. Ул тракторист шул ук елны тракторы капланып үлгән дип сөйлиләр. Мин бу урынны берничә тапкыр тикшердем инде. Чикләрен билгеләп, картасын да төзедем. Безнең авылда 1680 елда «новокрещенный» дигән кешеләр булган. Бу зират инде аңа чаклы булган дип әйтә алабыз».

1724 елгы чыганакта ул: «Кече Сон, яңа чукынганнар», – дип теркәлгән[8]. 1742 елгы архив чыганагында: «…новокрещенные из иноверцев», – дип язылган. Авылда 94 ир-ат яшәгәнлеге мәгълүм.

Таулар авылыннан Илһам (1966) истәлекләре. Язып алынды: 2016 елның августы.

«Авылыбызның керәшен зиратында («Солылы-борайлылар зираты») гарәпчә язулы, тәбәгәнәгрәк 4-5 таш бар иде. Мин аларын әле үзем күреп беләм. Аларның зурлыгы җирдән 30-40 см чамасы иде. Хәзер алар инде күренми, ватылып, үлән арасында күмелеп калганнар. Эзләсәң, аларны табарга була. Анда тагын, без барып күргән, 1,6 м чамасы зурлыктагы таш бар. 8-9 кисәккә ватылган ул. Таш гарәп язулы, язма Аллаһ исеме белән башлана.

Шомырбаш зиратын гел яңартып торалар. Аларда шунда яшәп тә ислам динен тотып, татарлыгын югалтырга тырышмаган бабайның кабере бар. Алар аны үз зиратларына кертмәгән. Шомырбашта завферма булып эшләүче Иван Степаныч – Шәнгиләр нәселе бар иде. Менә шул абый: «Минем ерак бабай күмелгән анда», – дип сөйләде миңа. Аның әбисе Җамал әби иде. Ул безнең авылга төшеп, әбиләрдән догалар, намазлар укырга өйрәнеп йөрде. Аның әтисенең керәшенчә исеме Никулай иде. Җамал әбинең оныгы Генадий Иваныч әле авылда яши.

Шомырбаш авылының эчендә татар зираты бар. Ул урында Микуш дәдәйләр – Таҗилар. Әле алар яңа йорт төзеделәр. Аның базын казыганда да, түбән өйләр базын казыганда да, кеше сөякләре тулаем чыккан…»

Үри Чаллысы авылы приходына кергән Таулар авылы татарларының кире мөселманлыкка кайтулары турында 1869 елның 30 апрель-1876 елның 17 мартына чаклы булган документлар җыелмасы бар.

Үри авылында яшәүче Валерий Иванов (1952) истәлекләре. Язып алынды: 26.11.2016.

«Үридә Керәшен Казаклары Чаллысыннан килен булып килгән, 1900 елгы Үлинә түти бар иде. Урысчасы Ольга булгандырмы инде аның. Ул болай дип сөйли иде: «Әби, аягын бөкләп, мөселманча догалар укып, тәсбих тартып утырыр иде, үзенең түшендә тәресе бар иде». Менә бит ничек булган. Әби Ямашныкы иде. Элек бит Ямашны да чукындырган булганнар».

1742 елгы архив документында Үри Чаллысы турында: *«В селе Богородском, что было Исен, Уреево Челны тож, государственные ясашные, до прежней переписи новокрещены из иноверцев»*, – дип язылган. Исемлектә чукындырылганнан соң күршедәге Таулар һәм Бирдебәк авылларыннан, шулай ук Татар бистәсеннән һәм башка өлкәләрдән китерелгәннәрнең дә ике төрле исемнәре бирелгән. Бу вакытта авылда 166 ир кеше яшәгән. 1719 елгы ревизиядә Үри Чаллысында 14 мөселман татар, 15 яңа чукындырылган татар гаиләсе исәпкә алынган. Мөселман татарлар, җирләре чукындырылган татарлар исәбенә тартып алынгач, Казан чукындыру конторасы указы нигезендә, күршедәге Бирдебәк авылына күчеп китәргә мәҗбүр булалар. 1742 елгы ревизиядә алар Бирдебәк авылында күрсәтеләләр.

[8] РГАДА. Ф. 350. Оп. 2. Дело 1130. 1724 г.

Кече Бөрсет-Владимир авылында яшәүче Матрена Сергей кызы Кирилова (1937) истәлекләре. Язып алынды: 11.09.2018.

«Авылның элекке бер зираты әнә теге башта булган. Аны әле күптән түгел генә тотып алдылар. Бу – бик борынгы зират. Авылның яңа зиратын да әллә ничә тапкыр зурайттылар инде. Анда элек иске ташлар бар иде[9]. Кайберләре бөтен иде, бала-чага ватып бетергәндер инде аларны. Аларның язулылары да бар иде. Ул без белә, укый ала торган язулар түгел, иске гарәп язулы иде».

Евдокия Василий кызы Абдряшова (1932) истәлекләре.

«Биектауда изге чишмә бар безнең. Аны, кайчандыр татар изгеләре күмелгән җир дип әйтәләр. Имеш, анда 3 кеше күмелгән, алар татар мөселман нәселләре булган. Әле без белгән елларда да Югары Соннан, Ишкиләрдән килеп, шунда үгезләр чалып, корбан ашы үткәрәләр иде. Мин хәзер белмим инде, Югары Соннар килә торганнардырмы, әмма безнең авыллар, биш елдан биш елга корбан чалып, анда ботка пешерәләр. Менә быел да булды ул. Электән шулай дус яшәгәннәр. Алар элек бергә яшәгән булганнар. Традицияне дәвам итәләр. Быел да Валерий Молов дигән кеше тәкә биреп, анда корбан уздырды.

Элек «Иске зират»та татарча гарәп язулы ташлар бар дип әйтәләр иде. Минем үземнең ул зиратка кергәнем юк, ишеткәнем генә бар. Үзегез белгәннәрне укып керегез, дога булыр. Ул зиратны безнең Динар Пасыев киртә белән тоттырды».

1678 елгы документта Кече Бөрсет (Владимировка) авылы турында: «Починок на поляне Малого Берсута (Владимировка), в ней новокрещенные…» – дип язылган. 1742 елгы архив чыганагында: «…до прежней переписи новокрещены из иноверцев», – дип күрсәтелгән. Бу вакытта авылда 101 ир кеше яшәгән.

Шомырбаш авылында яшәүче Галя апа Федорова (1941) белән Микуш бабай (1937) истәлекләре. Язып алынды: 2016 елның августы.

«Безнең кушамат «Таҗилар» – Микушның бабасы Таҗи булган. Безнең урында – зират. Аны электән беләләр иде инде. Йорт каршында, юлның теге ягындагы су өчен колонка казыганда да кеше баш сөяге чыкты, диделәр, әмма аысын үзем күрмәдем. Безнең хәзер яңа өй. Иске өйне, безнең Валя туганда, 1964 елны җиткездек. Баз казыйбыз икебез. Миңа хатыннар урамнан кычкырып китә инде: «Казы әле, казы әле түбән өеңне (базны шулай диләр), белерсең, аска таба төшкәч!» – дип. Озак та узмады, баш сөяге килеп чыкты. Мин бик каты курыктым. Сикереп чыгып та киттем, аннан соң каты чирләдем дә. Ул баш сөяген әни, әйбәтләп алып, юып, төреп, әнә шунда, бакча башындагы яр кырыена илтеп күмде. Башка әйберләр чыкмады. 1540 елгы татар зираты булган бу. Безнең монда Назар бабай бар иде. Ул барып, архивка кереп, моны белеп кайтты.

[9] Авыл Советы рәисе бу турыда: «Владимир авылы эчендәге борынгы зиратның гарәп язулы кайбер кабер ташларын совет чорында сарай нигезенә салганнар», – дип сөйләде.

Күршедәге Шәнги бабайлар (Кузнецовлар) урынынан да, каршыдагы Әпәлиләр ягыннан да чыккан ул. Мин монда 55 ел торам, кабер ташлары күргәнем юк. Безнең элекке йорт тегендәрәк иде, йортның яңасы бу зиратка таба күчте инде... Яңа йортка фундамент казыганда да сөякләр күп чыкты... Бу авылның чиге булгандыр инде. Өстә дә чишмәләр бар безнең. Без бу урынны (Микуш бабайларның йорт биләмәсенә зират урынының исән калган, бозылмаган калкулы бер өлеше керә) икенче тапкыр тотып алдык инде. Безгә койма тотканда олырак кешеләр: «Сезгә бу урынны тотып алган өчен зур савап була инде», – дип әйттеләр. Авыл кешесе монда зират булганлыгын электән үк белгән инде. Элек бу урында агачлар юк иде. Әнә теге якта (тыкрык аша Микуш бабайларның сул ягы. Бу урын хәзерге вакытта ташландык хәлдә) элек бер пуҗым бар иде. Бу зиратны элек анда яшәүче кешеләр (кушаматлары – «Тукраннар» – Токрановлар) карап торган.

Шәнгиләрнең ерак бабалары күмелгән мөселман каберенең каен агачын кисеп, ул урынны зират эчендә калдырып, быел коймасын тотканнар. Элекке вакытларда зиратны ул якка зурайттырмаганнар иде. Элек татар динен тоткан өчен кертмәгәннәр инде. Хәзер зиратта бетенесе дә бергә ята, сугышмыйлар... Зиратта Җамал әбинең бабасы күмелгән булырга тиеш. Аны, мөселман булган өчен, зират кырыена күмгәннәр. Җамал әбинең әтисе Никулай исемле иде, шуның атасы инде ул. Җамал әбинең оныгы Генадий Иваныч авылда яши.

1678 елгы халык санын алу кенәгәсендә: «Починок на пустоши вершине речки Шунгуту...» – дип, авыл турында мәгълүмат бирелә. 1719 елгы беренче ревизия кенәгәсендә: «Ташландык авыл булган Шомбытбаш авылы урынында яңа чукындырылганнар (новокрещенные)...» – дип, беренче тапкыр керәшен авылы буларак искә алына. Износков 1882 елда: «Авыл XV гасыр ахырында барлыкка килгән. Анда татар морзалары яшәгән», – дип билгеләп уза.

***

Шулай итеп, хәзерге көндә керәшен авыллары булып саналган әлеге авыллар 1678 елгы документта – мөселман авыллары, ә инде 1742 елгы чыганакта яңа чукынганнар буларак күрсәтелгән.

Күрүебезчә, архив чыганакларында керәшеннәр турында: «Новокрещенные из иноверцев», – дип язылган. Безнең төбәктә «иноверецлар» фәкать мөселман татарлары гына булган. Әгәр мәҗүси арлар яки чирмешләр булса, алар турында «из язычников» дип язганнар.

Авылларның исемнәре беренче чукындырылган кеше исеменнән чыгып үзгәртелгән. Мәсәлән: Тукбулат – Иванаевога, Чиялебаш – Никофоровога, Кече Бөрсет – Владимировка, Әҗмәк – Васильевога әйләнгән.

Авыллардагы борынгы зиратлар, халык телендәге истәлекләр дә – керәшеннәрнең борынгы бабалары мөселман булганлыкка ышанычлы дәлил. Без керәшен авылларындагы мөселман зиратлары урынын мөмкин булганча төгәл билгеләргә тырыштык. Һәр зиратка кечкенә генә булса да истәлек билгесе куелса, һичшиксез, борынгы әби-бабаларыбыз рухына бер ядкяр булыр иде. ■

Гасырларны берләштергән хезмәт

Вәрис Гали



Табигать-анабызның гүзәл бер почмагында – Көмеш сулы Нократ һәм Чулман елгалары буенда – мәгърур таулары һәм нурлы кояш астында шаулап утыручы урманнары, тургай җырына күмелгән алтын башаклы иген басулары, салкын сулы челтер чишмәләре, аллы-гөлле чәчәкле тугай-болыннары, камышлы һәм төнбоеклы күлләре, җиләкле елга-үзәннәре белән күңелне үзенә тартып торган Мамадыш ягы – Татарстаныбызның иң матур, борынгы һәм тарихи вакыйгаларга бай төбәкләренең берсе.

Сафагәрәй хан белән Сөембикә ханбикә, Емельян Пугачев, Екатерина II, Александр Радищев, Владимир Короленко, Михаил Салтыков-Щедрин, Владимир Ульянов, Надежда Крупская, Владимир Азин, Василий Чуйков, Лев Троцкий һәм башка бик күп тарихи шәхесләрнең эзләре саклана биредә.

Ифрат дәрәҗәдәге тырыш халкы, Шәйхи Маннур, Әхмәт Гадел, Ринат Мөхәммәдиев, Зиннур Мансуров, Шаһинур Мостафин, Рафаил Газизов, Вәрис Мингалиев, Марат Закир кебек прозаиклар һәм шагыйрьләр; Заһидулла, Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннар кебек күренекле композиторлар; рәссам һәм галим Нәҗип Нәккаш; Миңгол Галиев, Георгий Ибушев, Гөлназирә Талипова кебек җырчылар һәм башка күп талантларны биргән Мамадыш ягы.

«Иделнең кызы, дип сөйлиләр Нократны.
Биредә таңнарның иң матур атканы!
Җыр белән уяна, хезмәттә көй яза
Әй ямьле, соклангыч Мамадыш яклары!» –

дип, шигъри юлларга салган аның гүзәллеген якташыбыз Шаһинур Мостафин.

Шөкер, халкыбызның авыз иҗаты әсәрләренә, ягъни милләтебезнең иң кыйммәтле ядкярләренә дә бай ул. Бу төбәк халык иҗаты кебек олы мирасны читләтеп үткән, шул чишмәнең суын татымаган, аның гүзәллеге, тылсымлы көче белән илһамланмаган кеше бик аздыр бездә. Габдулла Тукаебыз әйткәнчә, татар халык авыз иҗатының «авыздан – авызга сөйләнеп, бабадан – атага, атадан бала-

га ишетелеп, бер кәгазьгә язылмаса да, буыннан-буынга күчеп, халык күңелендә бер дә онытылмый торган», һәрберсе төбәгебезнең йөзек кашы булырдай бик күп жанрлары – дастан, бәет, мөнәҗәт, риваять, хикәят-кыйсса, легенда-мифлары, әкият, мәзәк, җыр, такмак, мәкаль-әйтем, табышмак, тизәйткеч, сынамыш, уен-бию җырлары, халык уеннары, йола поэзиясе, балалар фольклоры бәһасез мирас булып безнең көннәргә килеп җиткән. Шунысы куанычлы: соңгы вакытта менә шул халык җәүһәрләрен бергә туплап, Гөлфинур апа Дувалова «Мамадыш төбәге халык иҗаты: үткәннән бүгенгегә» дигән саллы гына китап бастырды. Анда җитмешләп мифик хикәят, сиксән риваять, йөз утыз мәзәк, мең өч йөзләп дүртьюллыктан торган җырлар, илле мөнәҗәт, йөз утыз биш бәет һәм башкалар тупланган. Алар районыбызда ут күршеләр булып, туганлашып, ярдәмләшеп яшәүче төрле милләт вәкилләреннән язып алынган.

«Гөлфинур апа Дувалова «Мамадыш төбәге халык иҗаты: үткәннән бүгенгегә» дигән саллы гына китап бастырды. Аңа җитмешләп мифик хикәят, сиксән риваять, йөз утыз мәзәк, мең өч йөзләп дүртьюллыктан торган җырлар, илле мөнәҗәт, йөз утыз биш бәет һәм башкалар тупланган.

Мәгълүм булганча, халык авыз иҗаты әсәрләре – милләтебезнең иң кыйммәтле байлыкларының берсе. Алар әдәби һәм тарихи мирасыбызның гүзәл бер өлешен тәшкил итәләр. Фольклорны халыкның күмәк акылы, сәнгатькә сәләте тудырган. Ул, форма ягыннан гасырлар дәвамында камилләшеп, сүз сәнгате югарылыгына күтәрелгән. Гөлфинур апаның Мамадыш төбәге халык авыз иҗатын тупларга алынуы үзе үк – зур тәвәккәллек һәм изге гамәл. Дүсмәт төбәге авыллары тарихына багышлап алдарак язылган китаплары кебек, аның бу китабы да киләсе буыннарга менә дигән ядкяр булып калачак.

Игътибарыгызга әлеге китаптан кайбер өзекләрне тәкъдим итәм.

Дүсмәт урманы җенле

Бер карчык үзенең оныгы белән төштән соң урманга җиләккә дип менгән, ди, имеш. Җиләк күп икән, савытларын тиз генә тутырганнар да кайтыр юлга чыкмакчы булганнар. Әмма тегеләй барып карыйлар, болай барып карыйлар, тик килгән сукмакларын һич тапмыйлар икән, кыскасы, адашканнар. Төрле якка карап: «Ау-у-у», – дип кычкыра башлагач, бик ерактан хатын-кыз тавышы ишетелгән боларга. Бик сөенешкәннәр, әмма бу тавыш боларны һаман да эчкәрәк кенә алып керә икән. Инде караңгылана да башлаган. Нишләргә дип аптыраган карчык белгән ырымнарын исенә төшергән. Малайның күлмәген кире ягы белән әйләндереп кидерткән, аяк киемен уңын сулга алыштырып куйган, җен-шайтаннарны куркыта торган догаларын укый башлаган, ди. Шулай итә торгач, көч-хәл белән килгән сукмакларына чыкканнар болар.

Чынлап та, булган хәл бу. Дүсмәтнең тау урманы адаштыра, дип, гомер-гомергә зарланалар. Чөнки бу урман аша «үлек юлы» узган. Элек мәетләрне шушы урман аша Юкәче зиратына алып барып җирләгәннәр.

Белгечләр раславынча, Дүсмәт урманы аномаль яктан куркыныч зонага керә. Шуның өчен ырымнарны белергә кирәк.

Сөйләүче: Николай Арсентьевич Васильев (1950 елгы). Дүсмәт авылы.
Язып алучы: Гөлфинур Зәйнулла кызы Дувалова (1949 елгы).

Им-томнар, юраулар

Керәшен әбиләребез, бабаларыбыз бик тә сабыр, кешелеклеләр иде. Догаларыбызны да үзләре белгәнчә укып, Ходаебызга шөкер кылып яшәделәр. Без үскәндә, авырткан җирләребезне дәвалаучы Анный исемле әбиебез бар иде. Без, ташбашларның, күбрәк башы авыртты. Баш авыртканда, чиста юкә мунчаласын алып (озынлыгы – 80 см, киңлеге – 5-6 см), маңгай аша колак өстенә куеп, муен артындагы ялганчы чокыры турысында әйбәтләп кысып тота. Учактан күмер алып, маңгай, ике колак, ялганчы чокыры турысындагы мунчалага тамга сала. Соңыннан шул мунчаланы, кул белән тотып, сузып карый. Әгәр дә колак сызыклары туры килмәсә, баш мие кайсыдыр якка авышкан була. Шуңа карап, төрле үләннәрдән ясалган дәвасын бирә. Шул үләнне эчеп, бер ун минут ятып торасың да, баш авыртуың да юып алгандай бетә. Шулай итеп, Анный әбиебез безнең кан басымын үлчәгән инде.

Без, малайлар, тагы эчебез катып интегә идек. Авызга нинди үлән туры килә, барысын да ашадык бит. Мондый чакта Чумар әби килә иде ярдәмгә. Арт ягыбыз чыгып аптыратса да, бик тиз генә утыртып куя иде. Яра ташы дигән ап-ак таш бар иде әле тагы әбиләребездә. Берәр җиребез киселсә, канаса, шуны кырып, әз генә яраңа сибәләр дә, ул да бик тиз төзәлә иде. Бик саклап, кадерләп кенә тоттылар ул ташны. Рәхмәт инде ул әбиләребезгә, урыннары оҗмах түреннән булсын. Амин!

Сөйләүче: Владимир Иванович Григорьев (1947 елгы). Дүсмәт авылы.
Язып алучы: Гөлфинур Зәйнулла кызы Дувалова (1949 елгы).

Серле орчык

Нәнәм минем нугыт карый иде. Нугыт дигәннәре җеп эрли торган өр-яңа орчык була. Ул аны бервакытта да эшкә тотмады, чиста бистәргә төреп кенә йөртте. Теләсә кайда утырып карамады, үз урыны бар иде. Орчыкның нечкә башында чип-чиста нечкә җеп. Орчык җебен тоткан уң кул дерелдәргә дә, калтырарга да тиеш түгел. Аяк тездән бөкләнеп, күтәрелеп тора һәм уң кул шуңа куела. Җепне очыннан тотып, ирен (авыз) тирәли сәгать теле уңаена әйләндереп, иман укып, килгән кешенең йомышын тыңлап, барысын да әйтеп бирә иде нәнәм. Орчыкның юан башы сул кулның уч төбенә тияр-тимәс тора. Мин, сабыйга, бер могҗиза шикелле. Тормышта иминлек булса, тып-тын тора. Болганасы булса, кечкенә түгәрәк ясап әйләнә башлый. Үлем-китем булса, ул аны бервакытта да әйтмәде. Кеше чыгып киткәч, үзалдына сөйләнеп, эче пошып кала иде.

Серле орчык күп вакытлар сакланды әле бездә. Картайгач, ул эш белән шөгыльләнмәде инде нәнәм.

Сөйләүче: Владимир Иванович Григорьев (1947 елгы). Дүсмәт авылы.
Язып алучы: Гөлфинур Зәйнулла кызы Дувалова (1949 елгы).

Җөри авылындагы Тәпи чишмәсе турында риваять

Борын-борын заманнарда кулына баласын күтәргән бер хатын ерак юлдан кайтып килә ди. Баласы тумыштан йөри алмый икән. Ял итәргә, сусавын басарга бер чишмә янына туктаган бу. Балага да эчерткән чишмә суын, Ходайдан ялвара-ялвара баласының савыгуын сорап, тәпиләрен юган. Ходай Тәгалә ишеткән бу ялваруны. Бала, озак тормый, яшел чирәм буйлап тәпиләп тә киткән. Шул вакыйгадан соң бу чишмә суын изге дип атый башлаганнар һәм бик күпләр үзләренә файда тапканнар.

Сөйләүче: Анастасия әби Федорова (1928 елгы). Җөри авылы.
Язып алды: Галина Робертовна Иванова (1967 елгы).

«Көмеш тәңкә» ансамбле Тәпи чишмәсендә. Җөри авылы

Владимир авылының Биек тау чишмәсе турында риваять

Авылдан ерак түгел биек тау түбәсендә бер чишмә ага. Чишмәнең тирә-ягы яшел чирәмлек белән капланган, як-якта иксез-чиксез иген басулары җәелеп ята. Якында гына катнаш урман күренеп тора. Элек заманнарда бер елны бик нык корылык булган, үләннәр кибеп, җирләр ярылып беткән. Илья пәйгамбәр шулвакыт, тау башына менеп, корбан чалган, шуннан соң яңгырлар яуган, бар дөнья иркен сулыш алган, ә тау өстендә чишмә бәреп чыккан. Аны Биек тау чишмәсе дип атаганнар. Ул агып чыккан урында бүгенге көндә дә биек тал үсә.

Биек тау чишмәсе. Владимир авылы

Бик борынгы заманнарда бу чишмә янында Яңа Сон, Татарстан һәм Владимир авылы кешеләре, элек шушында яшәгән изгеләргә табынып, бергәләп Корбан үткәрә торган булганнар. Корбанга бары тик ак төстәге хайваннарны гына – үгез яки сарык чалганнар. Бу чишмә янында Корбан чалу йоласы хәзерге вакытта да дәвам итә, шөкер.

Сөйләүче: Александра әби Бахрова (1923 елгы). Владимир авылы, 1990 ел.
Язучы: Елена Алексеевна Бачкова (1967 елгы).

Кыз урлау йоласы

Кыз урлау йоласы дигәннән, элек бигрәк тә керәшен халкында киң таралган була ул. Безнең Комазан башы авылында гомер итүче килен-җиңгәчәйләрнең барысы да диярлек башка керәшен авылларыннан урлап кайтылган кызлар дип әйтсәк тә була.

Әйе, бу, чынлап та, шулай. Элекке йола буенча, керәшен егетләре кәләшне урлап кайтырга тиеш булганнар. Күп очракта бер дә таныш булмаган, күз күрмәгән кызлар була әле ул. Әле дә мәзәк хәлләр сөйлиләр бу хакта. Бервакыт шулай безнекеләр Кумырык авылына киткәннәр кыз урларга. Әмма урлыйсы кыз клубка чыкмаган ул көнне. Киткәннәр болар кызның өенә, чакырып чыгарабыз, дип. Кыз урынына, балта күтәреп, атасы чыкмасынмы егетләр каршына! Имеш, менә сезгә кыз!.. Егетләр сөйлиләр иде инде, кайчакта, буранда адашып, буш кайткан чаклар да буладыр иде, дип. Кайчакта бер чанага ике егеткә ике кыз урлап та кайта идек, дип. Андый вакытта урын таррак була инде чанада. Мин үзем дә Зояны урлап алып кайттым шулай. Әйбәт яшибез, Аллага шөкер.

Урлап кайтканның икенче көнендә яшь киленгә иң беренче эш итеп су юлын күрсәткәннәр. Су юлын күрсәтүче кеше егет ягыннан берәр туганы булырга мөмкин. Шул көннән бирле килен су ташый да су ташый инде... Авыл халкы тәрәзәдән әкрен генә күзәтә: ничек киенгән, төс-биткә, буй-сынга ничегрәк, көянтә-чиләген бик атындырмыймы, суы түгелеп бетмиме кайтканда... Аккош кебек йөздереп кенә кайта алса, әйбәт була инде.

Сөйләүче: Альберт Степанович Спиридонов (1950 елгы). Комазан башы авылы.
Язып алучы: Гөлфинур Зәйнулла кызы Дувалова (1949 елгы).

Тырлау буйларында Питрау
(Халык җыруы)

Питрау бәйрәмнәрендә без җөриек,
Ике кулыбызга гөл учлап.
Сез туганайлар белән бер күрешкәч,
Күңелләрем кала тынычлап.
Җөриләрдә чуар күке кычкыра,
Тырлау буйкайларын бер итеп.
Әйдәгез, туганнар, җырлашыек,
Питрау торсын бүген гөр итеп.
Карлыгандай, ай, кара күзегез,
Каләм карасы күк кашыгыз.
Шулкадәре зурлап бәйрәм ясарга
Ничек җитте сезнең башыгыз?!
Безнең гомеркәйләр узып бара
Минутын-сәгатен санамый.
Җыелышкан чакта сайрашыйык,
Питрау үткәч, кош та сайрамый. ■

Апаз керәшеннәренең нәсел тамгалары

Габделфәрт Закиров

ТР Милли архивындагы документта һәм төп нигездә саклана торган сырлы бәләктәге нәсел тамгасы

Бала вакыттан үзебезнең нәсел тамгасын белә идем. Бервакыт әти белән колхоз амбарына ашлык алырга бардык. Ул 1930-1932 нче елларда колхоз төзегән вакытта авыл халкыннан җыеп алынган нечкә бүрәнәләрдән бурап салынган келәтләрдән тора иде. Шунда әти миңа: «Улым, менә бу келәт безнеке иде», – дип, шуларның берсенә төртеп күрсәтте. Мин аннан: «Син аны каян таныдың?» – дип сорадым. Ул, мине келәт янына ук алып барып, игътибарымны бер бүрәнәгә салынган тамгага юнәлтте. Ул вакытларда безнең йортта андый тамгалы әйберләр бик күп иде: каба, күәшкә, җилпуч, куна, струк, агач сука, сүс сугу станогы, киндер капчыклар, шыбын агачы һәм әтинең армиядән алып кайткан котелогы белән флягасы. Шуларның берсе – сырлы бәләк хәзерге көнгә кадәр сакланган. Бу тамга минем хәтергә бик нык кереп калган иде. 2016 елда Татарстан Республикасының Милли архивында үземнең нәсел ыруымны эзләгән вакытта Апас авылы керәшеннәреннән 86 гаиләнең ислам диненә чыгарга рөхсәт сорап 1906-1907 нче елларда Казан губернаторына язган гаризаларының исемлеген таптым һәм анда карт бабайның һәм бабаемның гаризаларын күрдем. Барлык 86 кеше дә үзләренең гаризаларына нәсел тамгасы белән имзаларын куйганнар.

Хәзерге вакытта авылда үз тамгаларын белүче кешеләр бик аз инде. Бу тамгалар авыл кешеләренең көндәлек тормышлары белән бәйләнешле бер та-

рихи күренеш булып тора. Алар кайчан барлыкка килгән, нинди тамга нәрсәне аңлата, һәр кеше үз тамгасын үзе уйлап чыгарганмы, әллә аларны җитәкчеләр биргәннәрме? Болары безгә билгесез. Минемчә, бу тамгалар бик күп еллар элек, рун язулары чорыннан ук барлыкка килгән.

Шушы тамгалар белән кешеләр үзләренең җир кишәрлекләрен, хуҗалыкта куллана торган эш коралларын, армиядә хезмәт иткәндә үзләренең киемнәрен һәм башка әйберләрен тамгалаганнар. Туганнарын җирләгәндә дә кабер өсләренә үзләренең нәсел тамгаларын салып таш куйганнар.

Кызганыч ки, Апаз авылы керәшеннәренең каберләре өстендәге тамгалы ташлар сакланмаган. Бәлки, алар, озак еллар зиратны чистартмагач, җир белән күмелеп беткәндер. Олы кешеләрнең сөйләве буенча, бу тамгалар нәселдә буыннан-буынга күчеп килгән. 1907 елда төзелгән исемлектә дә бер үк тамгалар берничә гаиләдә очрый. Димәк, бу гаиләләр бер нәсел кешеләре диярга кирәк. Мәсәлән:

Василий Иванов (Бәшир Ибраһимов);
Григорий Иванов (Нури Ибраһимов), Григорийның улы Федор (Фәйзрахман Нуриев), аның улы Габделфәрт, аның улы – хәзерге вакытта **Арча муниципаль район хакимияте башлыгы Илшат Нуриев.**

Федор Степанов (Фәйзрахман Хәбибрахманов);
Алексей Степанов (Хәйрулла Хәбибрахманов).

Иван Кириллов (Ибраһим Солтанов);
Михаил Иванов (Гарифулла Ибраһимов).

Василий Николаев (Фәйзрахман Мөхәммәдҗанов);
Николай Васильев (Мөхәммәдҗан Бәширов), аның улы Петр Николаев (Сибгатулла), Петрның улы Сәүбән, **Сәүбәннең улы – җәмәгать эшлеклесе һәм сәясәтче Фатыйх Сибагатуллин.**

Федор Васильев (Ибраһим Абдуллин). Бу тамга аның балаларына – Ефим Федоровка (Хәким), Иванга (Ибрай), Архипка (Габдерәшид), Александрга (Самигулла) күчкән. Аларның нәсел дәвамчылары әлеге тамганы беләләр.

Әтиемнең сөйләве буенча, безнең тамга бик ерак бабайлардан килә. Нәселебез Апаз авылына иң беренче булып килеп урнашкан кешеләрнең берсеннән – 1640-1650 нче елларда туган Иваннан башлана. Шулай итеп, бу тамга безнең нәселдә тугыз буынга хезмәт иткән. Нәсел тамгалары хуҗалыклар өчен яңа куллану әйберләре күпләп чыгарыла башлагач, җир кишәрлекләре беткәч, әкренләп кулланудан чыгалар һәм онытыла башлыйлар.

Хәзер авылда бик күп кеше яңа йортлар, каралты-куралар төзеде. Алар кирәк булмаган иске-москыларны чүплеккә чыгарып ташладылар, яндырдылар. Безнең йортта да бу тамганы белүче калмаган иде инде. Мин исләренә төшердем. Аны истә тоту өчен, чормада йөз елдан артык яткан тамгалы сырлы бәләкне сакларга куштым.



Апаз кешеләренең нәсел тамгалары

1907 елдан соң инде биш-алты буын бу тамгаларны кулланмый үсте. 1867 елдан бирле авылда белем йорты, мәктәп эшли. Бөтен кеше укый-яза белә. Ә менә безнең әти мәрхүм укый-яза белми иде. Шуңа күрә нәсел тамгасын гомере буе кулланды.

Нәсел тамгасы кулланыштан чыкса да, хәзерге көндә аны белгән кеше үзенең карт керәшен әби-бабаларын таба ала. Мәсәлән, мәктәп музеенда яткан тамгалы-сырлы бәләк аркылы аның хуҗасы кем икәнен белеп, аннан соң, архив документлары нигезендә, үзеңнең нәсел-ыруларыңны бик җиңел табып була.

Нәсел тамгаларын тирәнтен өйрәнеп, аларны чагыштырып, безнең авыл кешеләренең кайдан килеп урнашканнарын да ачыкларга мөмкин. Бәлки, әле кайбер кешеләрнең чормаларында, келәтләрендә нәсел тамгасы салынган әйберләр әле дә саклана торгандыр.

Бу тамгаларның башка өлкәләрдә яшәгән керәшен һәм удмурт тамгалары белән чагыштырып карарга кирәк. Чөнки кайбер чиркәү документларында Апаз авылы кешеләренең православие динен кабул иткәннәрен «удмуртлар» дип язганнар, ә ислам динен кабул иткәч, алар татарга әйләнгән. Шуңа күрә ислам динен кабул итмәгән чуашларны, вотякларны (арларны) татарлар «аппаклар» дип йөрткәннәр. Бәлки, шуннан авылның исеме – Апаз килеп чыккандыр дигән мәгълүмат та колагыма керде. ■

Бер төзелеш тарихыннан

Айдар Казаков

Волость идарәсе бинасы. XX гасыр башы

Мәкаләм җирле хакимият өчен кирәкле булган, башланып та, салынып бетмәгән бер бинаның тарихына бәйле. Бу – Казан губернасының Спас өязендәге Пичкасс авылы волость идарәсе бинасын төзү тарихы. 1910 елның 1 мартында Спас өязе земствосының 3 нче участогы башлыгы Андриан Алексеевич Булыгин исеменә волость старшинасы Степан Андреевич Чичирин тарафыннан расланылган Пичкасс авылында кирпечтән волость идарәсе салуның зарурилыгы аңлатылган рапорт һәм волость җыелышының карары (ул заман теле белән әйткәндә, «Приговор». – А.К.) җибәрелә. Ул Җыелыш карарларын теркәп баручы кенәгәгә (кызганыч ки, сакланмаган) унынчы сан астында теркәлгән.

Аңа, волость судьялары Галим Ибраһимов, Гайнулла Сәйфуллин, Иван Колчин, Иван Денисов белән берлектә, 14 авылның старостасы һәм һәр авыл җәмгыятеннән сайланылган 190 гласный кул куйган. Рапорттан һәм карардан күренгәнчә, волостьлар оештырылганнан бирле, волость идарәсе, волость суды, волостьнең ссуда-саклык кассасы белән волость писаренең фатиры, «әлеге шартлар өчен яраклаштырылмаган, түбәсе салам белән капланылган булу сәбәпле, анда саклана торган документларга, шактый зур суммадагы

акчага һәм кыйммәтле кәгазьләргә янгын чыккан очракта юкка чыгу куркынычы янаучы, вакытлыча файдалануга алынылган крестьян избасында урнашкан».

Төзелеш эшен башкарып чыгу өчен, Спас өязе земство управасыннан 7000 сум күләмендә заем алырга да карар кылынган.

Эшне башлап җибәрү, аның барышын күзәтүдә тоту өчен, 9 кешедән торган махсус комиссия төзелә. Әлеге комиссия составына 2 нче Кожаевка авыл җәмгыятеннән – Лаврентий Карпунин (волость старшинасы), 1 нче Кожаевка авыл җәмгыятеннән – Александр Дебрин (волость писаре), Әҗмәрдән – Галим Ибраһимов, Көектән – Ибраһим Абдрахманов, Ямбактыдан – Җиһанша Гайнуллин, Иван Мельников (Вожи), Сергей Привалов (1 нче Пичкасс җәмгыяте), Иван Калашников (2 нче Пичкасс җәмгыяте) кертелгән.

Әмма барлык финанс эшләре Иван Колчин җитәкчелегендә башкарылган, чөнки ул төзүчеләргә аванс бирү, кирәкле материалларны сатып алу кебек мөһим мәсьәләләрне хәл иткән, аның исеменә тауар квитанцияләре дә җибәрелгән. Мөгаен, ул заманнарда бу кеше волость казначее вазыйфасын үтәгәндер.

Әлеге комиссия үзенең эшчәнлеген 1910 елның 7 июнендә башлап җибәргән һәм волость идарәсе өчен сатып алынылачак кирпечнең сыйфатын тикшереп, сатып алучы Бураково алпавыты Юрий Васильевич Трубников белән килешү төзү өчен ошбу авылга килеп төшә. Алпавыт идарәчесе Верасовка төзелеш эше өчен кирәк булган 150 мең күләмендәге «соры» һәм «алпут» кирпеченең 1000 данәсен 12 сумнан сатарга кушылган була. Комиссия, кирпечнең сыйфатын тикшергәннән соң, әлеге шарт белән ике мөһим сәбәп аркасында килешергә мәҗбүр була. Беренчедән, Бураково Пичкасстан нибары 7 чакрым гына ераклыкта урнашкан, икенчедән, якын-тирәдәге авылларда андый яхшы сыйфатлы кирпеч булмаган.

Төзелеш эшләрен башлап җибәрү өчен таш, агач һәм түбә калаеннан тыш, ихата урыны да кирәклеген истән чыгарырга ярамый.

Төзелеш эшендә һәр авылның кешеләре турыдан-туры яисә читтән катнашканнар. Мәсәлән, Пичкасстан – Вавила Кузьмич Колчин, Трофим Наумов Сударев, Долгоруководан Елисей Семенович Васин төзелеш урынына таш чыгарып, аны ташу өстендә эшләсәләр, кайбер авыл кешеләре, мәсәлән, Пановкадан – П.Ф.Ганин, Көектән – Шәриф Миңнегәрәев, Пичкасстан Илья Рычков белән Спиридон Колчин үзләренең иске йорт һәм амбарларын утынга дип сатканнар. Әлеге корылмаларның бәясе якынча 10 сумнан алып 20 сумга кадәр йөргән.

Барлык төзелеш материаллары әзер булганнан соң, 14 август көнендә Спас өязе земство идарәсенең техникы Александр Бартош үз эченә кабул итү бүлмәсен, көтеп тору урынын, волость идарәсен, волость судын, ссуда-саклык кассасын, волость писаренең фатирын, бөтен кирәк-ярак корылмаларын һәм хезмәт бүлмәләрен (мунча, кухня, акча саклау бүлмәсе белән архив) дә алган проектны төзеп бетерә. Төзелеш эшләрен 1911 елның 14 апрелендә башлап, шул ук елның 9 октябрендә тәмамлау күз алдында тотыла. Минем уйлавымча, төзелеш эшләре комиссиясе әгъзалары эшчеләрне чит төбәкләргә һәм күрше өязләргә чыгып та эзләгәннәрдер. Моның шулай булуын Түбән Новгород губернасы Ардатов өязенең Ичалово волостендагы Арчиловка авылы игенчесе Сергей Тимофеевич Храмов, Лаеш өязенең Алексеевск авылы игенчесе Иван Иванов Шишкин белән подряд килешүләре төзү дәлилли.

Храмов белән гомуми күләме 777 сум 70 тиенгә тигез булган төзелеш подряды, бер яктан, комиссия әгъзалары һәм күрше авыллардан чакырылган понятойлар һәм, икенче яктан, төзү эшенә алынган кеше Казандагы Карл Генрихович Горштейнның нотариаль конторасында расланылган. Ә менә ихата урынын 200 сумга саткан Пичкасс кешесе Лаврентий Иванович Хлыстов белән килешү Спас өязе нотариусы Никифоров тарафыннан расланылган.

(Хөрмәтле укучым яисә әлеге мәсьәләләрне тирәнтенрәк өйрәнергә теләүче яшь галим, әгәр дә Сез киләчәктә бу мәсьәләне тикшерергә алынсагыз, Казан губернасының нотариаль конторасы фондыннан тиешле мәгълүматлар таба алырсыз дип уйлыйм.)

Әлеге комиссия төзелеш эшләрен тикшергән вакытта берәр җитди кимчелек тапса, аларны бетерүне таләп итә алган, ә инде төзүче үзенең кимчелекләрен шуннан соң да төзәтмәсә, эшләнелгән эше өчен акчасын бирмәскә дә хокуклы булган.

Тәрәзә рамнарын ясау, аларга пыяла кую һәм рамнарны ак буяуга буяу эшләренә Алексеевск кешесе Иван Шишкин алынган.

Барлык эчке эшләрне башкаруга, ике канатлы, бизәкләп эшләнелгән капка ясауга, 8 түгәрәк «голланд» миче белән кухнядагы плитәле зур мичне үзенең материаллары хисабына чыгаруга Пичкасс кешесе Алексей Григорьевич Попов билгеләнгән. Аның белән төзелгән подряд килешүенең суммасы 2792 сумга тигез булган.

Ул заман теле белән әйткәндә, әлеге «җәмәгать эшләре»нә барлык авылларның кешеләре дә тартылган, чөнки бу акча эшләүнең реаль чыганагы саналган.

Икешәр ат белән килүчеләр Бураководан 10 000 данә кирпеч ташыган. Бу Әҗмәр кешеләре арасында – Нурулла Гафиятуллин, Гомәр Госманов, Пичкасстан Петр Ширяев булган. Кирпеч ташучыларга бирелгән барлык квитанцияләрнең өзелеп алыныла торган өлешләре («ярлыклары») сакланып калган. Гомумән алганда, әлеге эш 187 битлек документта тасвирланган.

Комиссия уздырган иң беренче тикшерү вакытында төзелештә зур күләмдәге җитди кимчелекләр ачыкланган һәм комиссия тарафыннан аларны кыска вакыт эчендә бетерергә күрсәтмә бирелгән.

Ниһаять, 1911 елның 9 октябрендә Андриан Александрович Булыгин һәм комиссия әгъзалары катнашында төзелеп беткән бинаны кабул итү булган. Төзелешне карап чykканнан соң, комиссия Сергей Тимофеев Храмовка калган 277 сум 70 тиен акчаны: «Бирмәскә карар кылдык, чөнки кайбер урыннарда кирпеч кыек салынган, измә аз, хәтта бөтенләй диярлек юк, тышкы җөйләр ялтырап ята, тәрәзә һәм ишек уемнары бернинди тәнкыйтькә дә чыдамый...» – дип хәл иткән.

Әлеге эштә соңгы сүзне техник Бартош әйткән, 10 октябрь көнендә төзелгән актка ул болай дип язган: «Төзелеш эшләре үтә дә кәнагатьләнмәслек итеп үткәрелгән».

Хәзерге заман төзелешләре белән моннан 110 ел элек башкарылган төзелешләр арасындагы уртак сыйфатларга һәм җитди кимчелекләргә игътибар иткәнсездер дип уйлыйм. Без тарихтан гыйбрәт ала белмибездер, күрәсең... ■

Ильяс Бораганиның кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Ильяс Борагани

Ильяс мирза Әхмәдша улы Борагани – атаклы каллиграф, нәшир, мәгърифәтче, педагог, тюрколог. Ул 1852 елның 22 апрелендә Кырымның Бакчасарай шәһәрендә татар морзасы гаиләсендә дөньяга килә. Җирле мәктәп һәм мәдрәсәдә белем алганнан соң, И.Борагани Истанбул университетын тәмамлый. Ул бераз вакыт Кырымда эшләп, аннан 1882 елда Петербургка күченә. Ильяс мирза 1893 елда биредә беренче мөселман типографиясен ача һәм гарәп, фарсы, төрек, татар, рус телләрендә күпсанлы китаплар бастыра. Китап сәнгатендәге тырышлыгы өчен ул хәтта дәүләт тарафыннан медаль белән дә бүләкләнә. И.Борагани берара Россия империясенең Тышкы эшләр министрлыгында каллиграф булып та хезмәт итә, 1898-1908 нче елларда Петербург университетында төрек теленә һәм шәрык каллиграфиясенә багышланган лекцияләр укый. 1919 елда ул «Салават» дип аталган татар газетасы чыгара башлый. Ильяс мирза 1920 елда Стәрлетамак шәһәренә күченә, биредәге кешеләрне типография эшенә өйрәтә. Соңыннан ул Уфа шәһәрендә яши һәм җирле нәшрият бүлеген җитәкли.

Моңарчы әлеге олуг шәхеснең үлгән елы төгәл билгеле булмады, «Татар энциклопедиясе»ндә аның 1920 нче еллар ахырында вафат булуы хакында язылган, шулай ук 1924, 1934, 1942 нче елларда бакыйлыкка күчүе турында төрле версияләр бар иде. И.Бораганиның кабер ташы әлеге бәхәскә һәм каршылыкка, ниһаять, нокта куйды. Анда язылганча, ул 1938 елның 10 февралендә 86 яшендә вафат булган һәм Уфа шәһәренең мөселман зиратына җирләнгән. Милләттәшебезнең кабер ташы хәзерге көнгә хәтле чагыштырмача яхшы сакланган.

Текстының укылышы мондый:

Алгы ягы:

1) «Бу кабердә мәдфүн
2) Бакча Сарайның
3) Илйас бине Әхмәдша
4) Борагани әл-Кырыйми
5) 22 йәшендә ватанын
6) ташлаб Линиград
7) дарелфөнүнендә
8) ликтурлык, матбага-
9) -чыйлык һәм башка
10) гыйльми хезмәтләрдә».

Уң ягы: «86 йәшендә».

Сул ягы: «50 сәнә гомерен үткәргән, вафат 1938 сәнә фиврал 10».

Арткы ягы:

1) «Ильяс Ахматшивич
2) Бурагански».

Хәзерге татар теленә күчермәсе:

1) «Бу кабердә
2) Бакчасарайдан
3) Ильяс бине Әхмәдша
4) Борагани Кырыми җирләнде,
5) 22 яшендә Ватанын
6) ташлап, Ленинград [Петербург]
7) университетында
8) лекторлык, матбага-
9) -чылык һәм башка
10) гыйльми хезмәтләрдә».

Алгы ягының дәвамы сул ягында.

Уң ягы: «86 йәшендә [вафат]».

Сул ягы: «50 ел гомерен үткәргән, 1938 елның 10 февралендә вафат».

Сул ягының башы алгы ягында.

Арткы ягы:

1) «Ильяс Ахматшович
2) Бораганскі». ■

Истанбул мәктүбләре

(1912-1913)

Фатих Кәрими

Әхмәд Мидхәт әфәнденең иң соңгы фотосурәте

Дәвамы. Башы журналның 2 нче (2022) санында.

25 нче мәктүб

Әхмәд Мидхәт әфәнденең җеназасында

21 декабрьдә иртә берлән йокыдан торып төрек газеталарын караштыра башлагач та «Сабах» газетасының дүртенче битендә иң актыкта Зыягъ Газыйм сәрләүхәсе *(исеме)* илә язылган җиде-сигез юллык хәбәр күренде. Укып карасам, фазыйле шәһир *(мәшһүр галим)*, хакиме мөхтәрәм Әхмәд Мидхәт әфәнденең[1] 15 декабрьдә төнлә сәгать унбер ярымда «Дарешшәфәка» мәктәбендә удар булып кисәктән вафат иткәнлеге язылган. Күзләремә инанмадым, шашып калдым. Дәрхаль *(шундук)* башка газеталарга бактым. «Икъдам» вә «Тәсвире әфкяр»дә дә шулай ук, өченче-дүртенче битләрдә газетаның иң әһәмиятсез җирендә шулай биш-алты юллык бер төсле үк язу илә Әхмәд Мидхәт әфәнденең вафаты хакында хәбәр бирелә.

Бу кеше бит Төркия өчен безнең Русиянең Толстое, Муромцевы иде. «Бунлар үлгәндә Русия матбугаты ничек яздылар, Мидхәт әфәнде үлгәндә төрек газеталары ничек язалар!» – дип исәпләп тагын шашып калдым. Ләкин ничек кенә булса да, хәбәрнең дөреслегендә шик юк иде. Шул сәбәпле, иң беренче эшем телеграм илә буны «Вакыт»ка хәбәр бирү булды.

Мәрхүм 16 декабрьгә каршы төнлә сәгать 11 ярымда «Дарешшәфәка» мәктәбендә[2] үзенең вазыйфасы башында, гыйлем юлында шәһит булган. Иртә сәгать 3тә телеграф илә аның вафатын өенә (Бәккуз – *Бәйкозга*) хәбәр биргәннәр вә шул көн (16 декабрьдә якшәмбе көн) көндез сәгать 4ләрдә ике-өч йөз кеше ки, аның да яртысы «Дарешшәфәка»дә укучы ятим вә фокара шәкертләрдән гыйбарәттер – тыкырдатып китереп күмеп тә куйдылар. Газеталарда аның вафат хәбәре иң ахырда биш-алты юллык язу илә белдерелде. Кайчан вә кайда дәфен улыначагын һичкем белми дә калды.

Мидхәт төрек углы төрек, мөселман углы мөселман иде. Милләтенә һичтуктаусыз 50 ел хезмәт итте. Кылымы *(эшчәнлеге),* фикере, эше берлән төрекләргә нәмунә *(үрнәк)* булды. Мидхәтне Яурупалылар да таныйлар: «Төркиядә төшенүчеләр, эшләүчеләр кемнәр бар?» – дигәндә, беренче мәртәбәдә Мидхәт исме зикер ителә иде. Зур бер төрек милләтен тәҗәссем иттерә *(гәүдәләндерә)* вә анларга башкаларның хөсне тәвәҗҗеһ *(яхшы теләклелек)* вә хөрмәтләрен җәлеп иттерергә кулыннан килә торган бер кеше иде.

Миңа бервакыт мәрхүм шәех Җәмаледдин Әфгани хәзрәтләре: «Гыйлем вә мәгърифәт каршысында тез чүгеп хөрмәт күрсәтмәгән милләтнең гакыйбәте *(ахыры)* хасрандыр *(аяныч)*. Ул милләт яшәмәс, чөнки яшәргә лаек түгелдер», – дигән иде. Мидхәт әфәнденең җеназасы вакытында шул сүзләр исемә төште: төрекләрнең Рум иле кыйтгасында, Траблуста, Йәмәндә җиңелүләренең сәбәпләреннән иң мөһим берсе дә шушы, ягъни үзләренә хезмәт иткән кешеләрне тәкъдир кылмау һәм голамәләренә хөрмәт итмәүләре икән. Болай булгач, әле бунлар һәнүз *(һаман)* җиңеләчәкләр икән, дидем.

Төрек газеталары һәркөн әллә никадәр озын мәкаләләр язып үзләренә

---

[1] Әхмәд Мидхәт (1844-1913) – төрек язучысы, публицист, тарихчы, мәгърифәтче, төрек әдәбиятында кыска хикәягә һәм романга нигез салучы. Романнар, хикәяләр, пьесалар һәм шулай ук тарих, дин, философия, география мәсьәләләренә багышланган китаплар авторы.
[2] Истанбулда 1873 елда ятим мөселман балаларын укытыр өчен «Тәдрисия исламия» җәмгыяте («Ислам мәгарифе» җәмгыяте) тарафыннан ачылган мәктәп.

Әхмәд Мидхәт әфәнденең кабере

гомердә кирәкмәс нәрсәләр илә укучыларының башларын катырып бетерәләр. Төрекләрне изрәтеп торган нәрсә – төрек газеталарының шул Яурупа сәясәте хакында һичтуктаусыз язып торган имеш-мимешләредер. Шундый мәкаләләрне сереп ташлап үз хәят вә мәгыйшәтләреннән *(тормышларыннан)* яза башласалар, һәркөн вилаятьләр вә Анатулы әхвәленнән бәхәс итсәләр вә шунлар җөмләсеннән Мидхәт әфәнденең вафаты кебек үзләренең хәятенә гаид *(караган)* мөһим вакыйгаларны да язсалар, мескен төрекләр айнып китәрләр, йокыдан уянган адәмнәр кебек күзләрен ачып җибәрерләр иде.

«Дарешшәфәка» мәктәбе минем номердан бик ерак булганга вә хәбәрләшер өчен телефон-фәлән булмаганга күрә, берадәрем Гариф вә дарелфөнүн шәкерте һәмшәһримез *(якташыбыз)* Габдерахман әфәнде илә 16 декабрьдә иртүк Бәккузга, Мидхәт әфәнденең өенә киттек. Җеназа шунда була торгандыр, үз өеннән чыгаралардыр дип исәпләдек. Бәккуз – Бугаз Эчендә бер мәхәлләдер. Пароход анда Истанбулдан сәгать ярым бара. Сәгать унберләрдә Мидхәт әфәнденең өе янына җиттек. Килгән-киткән һичкем юк. Һичбер хәрәкәт күренми. Өенең диңгезгә таба ягындагы күпер өстендә берничә зур малай гына уйнап тора.

Звонок бирдек. Ишекне ачтылар. Ишектән керүемезгә бер чок хатын-кызларның кычкырып еглашкан тавышлары бөтен өйне күтәрә иде. Безгә каршы бер яшь егет һәм бер хатын килде. Бу соңгысы, үзен-үзе тыя алмаенча, кычкырып еглый иде. Тиз генә карточкамызны биреп, үземезне таныттык вә тәгъзия *(кайгы уртакла-*

шу) өчен килгәнемезне белдердек. Безне бер бүлмәгә керттеләр. Стенада Мидхәт әфәнденең зур портреты тора. Хатын, шуңа карап: «Бакыңыз, әфәндем, югалттык бит аны, мәңгелеккә югалттык инде...» – ди вә үзе еглый. Без гыйлеме, фазыйле вә язган әсәрләре илә Мидхәт әфәнденең Русия мөселманнарына бик мәгълүм бер зат булганлыгын, вә бик күпләремез аны үзенә остаз вә мәгънәви ата дип таныганлыкларын, вә шул сәбәпле аның вафатына чын күңелдән кайгырып, гаиләсенең кәдәр *(кайгы)* вә хәсрәтләренә иштирак иткәнемезне *(уртаклашканыбызны)* сөйләдек. Калганнарга сабыры җәмил *(зур сабырлык)* теләп тәгъзия бәян иттек. Хатын: «Бильюрум *(беләм)*, әфәндем, бильюрум, әҗнәбиләр аны безнекеләрдән дәхи *(тагы)* дә яхшырак таныйлар вә аның кадерене безнекеләрдән дәхи дә артыграк беләләр иде. Кайгыларымызга иштирак өчен килүеңезгә бик рәхмәт», – диде вә еглый-еглый янымыздан чыгып китте. Бу Мидхәт әфәнденең хатыны вә янымызда калган яшь егет тә Мидхәт әфәнденең әкърабасыннан *(туганнарыннан)* бер кеше икәнлегене аңладык вә ничек вафат иткәнлеген сораштык.

– Аңарга моннан элек ике мәртәбә удар булган иде, ул вакыт докторлар тиздән ярдәменә җитешәрәк тәненә дару җибәреп айнытканнар иде. Менә кичә «Дарешшәфәка»дә «Тәдрисия исламия»нең заседаниесеннән соң дәхи дә удар булган, һәрникадәр табиблар тырышып карасалар да, бу дәфгасында коткара алмаганнар, иртә сәгать 3тә безгә монда телеграм илә вафат хәбәрен җибәрделәр, – диде.

Кайчан вә кайда дәфен улыначагын *(җирләнәчәген)* сорадык.

– Җеназасы хәзер «Дарешшәфәка» мәктәбендә. Монда китерелмәде әле. Кайчан вә кайда дәфен улыначагын белмимез – анда ничек карар бирерләр, зан итәмез *(уйлыйбыз)* ки, Солтан Фатих җәмигы төрбәсенә дәфен улыныр, чөнки голамәдәндер *(галимнәрдәндер)*, – диде.

Утырганнар (уңнан сулга): дарелмөгаллиминнән Фәһми бәк, Шәүкәт бәк, Сафвәт бәк, Ришат бәк, Гакыйф бәк, Наим бәк, Әхмәд Мидхәт әфәнде, дарелфөнүннең әдәбият бүлеге мөдире Исмәгыйль Хаккы бәк, Әхмәт Хикмәт бәк, Камал Бәкзадә Гали Әкрәм бәк, Хөсәен Даныш бәк, Шәһбәндәрзадә Хилми бәк

Мондый кайгылы вакытта хафалау булмасын, дия, озак тормаенча, Мидхәт әфәнденең өеннән чыктык. Җеназасының ни вакыт күтәреләчәген телефон илә Истанбулдан берәр җирдән сорап булмасмы икән, дип, Бәккуздагы полицә мәркәзенә килдек. Чөнки полицәләрдә телефон бардыр. «Телефонымыз бозыктыр, әфәндем, сөйләшеп булмый», – диделәр. Ул хәлдә телеграм җибәреп сорап карыйк, дидек. Телеграфханәгә килдек. «Җавабыны кичсез ала алмассыз, чөнки «Дарешшәфәка» Истанбул телеграфханәсеннән ерактыр», – диделәр.

Ул хәлдә, ихтимал ки, аның җеназасы бүген өйләдән соң күтәрелер дия, тизрәк үземез Истанбулга кайтуны муафыйк күреп, пристаньга килдек. Пароход юк. Берәр сәгать көткәч, килде. Утырып киттек. Сәгать икенче яртыда Истанбулга кайттык. Аннан, извозчикка утырып «Дарешшәфәка»гә чаптык. Сәгать дүртенче яртыларда анда барып керсәк: «Җеназаны Фатих җәмигына алып киттеләр. Хәзер күмеп бетерә торганнардыр инде», – диделәр. Йөгердек Фатих җәмигына. Җәмигъ янындагы каберлеккә керсәк, бер каберне күмеп торалар. Тар гына бер урында 20-30 данә мәдрәсә шәкертләре вә берәр йөз кадәр төрле кешеләр бар. Иң беренче очрадыгымыз шәкерттән: «Кемне күмәләр?» – дип сорадык. «Валлаһи, белмим, әфәндем», – диде. Ул да булмады, күмелә торган кабернең янындарак үземезнең һәмшәһриләрдән дарелфөнүн *(университет)* шәкерте Сибгатуллаһ, мәктәбе Солтани шәкерте Бәдреддин, дарелмөгаллимин *(укытучылар әзерли торган уку йорты)* шәкерте Нуруллаһ әфәнделәр күренделәр. Күмелә торган кабернең Мидхәт әфәнде зираты икәнлеген алардан аңладык. Соңра кабергә мөмкин мәртәбә якын барып, мәрхүмгә соң тәгъзыймемезне гарыз иттек *(белдердек)*.

Бер яктан каберне күмәләр, икенче яктан сукыр суфилар бер читтә кычкырып Коръән укып торалар. Кабер күмелеп беткәч, аяк өстендә кыскача бер дога кылынды. Соңра һәркем таралып китте. Нотык-фәлән шикелле нәрсәләр булмады.

Кешеләр тарала башлагач, һәмшәһриләремез мине шунда булган бәгъзе бөек затлар илә таныштырдылар. Бунлар арасында Дәфтәре хакани[3] назыйре Мәхмүд Әсгадь әфәнде, дарелфөнүн мөдире Сами бәк, дарелмөгаллимәт мөдире Халусый бәк, мәгариф әгъзасыннан Нәгыйм бәк, Бабанзадә җәнаплары бар иде. Сами бәк исә, үз тарафыннан мине шундагы ике яшь егет берлән күрештереп: «Бунлар мәрхүм Мидхәт әфәнденең угылларыдыр», – диде. Анларга тәгъзия бәян иттем.

Мәхмүд Әсгадь әфәнде илә күрешкәч, аннан:

– Букадәр зур бер галимнең җеназасын ни өчен букадәр ашыгычлык илә вә лөзүме кадәр хөрмәт күрсәтмәенчә дәфен ителде? Монда бит күп кеше вә бик күп мөәссәсәләрдән *(оешмалардан)* вәкилләр килергә вә мәктәп шәкертләре, мөхәррирләр, әдипләр, китапчылар вә газетачылар тарафыннан вәкилләр булырга кирәк иде, – дидем.

– Юк инде, бу яхшы хөрмәт белән дәфен ителде, җеназада булынмак өчен сарай тарафыннан, садыйр әгъзам *(бөек вәзир)* вә мәгариф нәзарәте тарафларыннан адәмнәр килде, җеназасын «Дарешшәфәка» шәкертләре озаттылар, – диде.

Анлардан аерылганнан соң, үземезнең һәмшәһри *(якташ)* шәкертләр илә сөйләшеп кайттык. Алар исә дәфеннең Мидхәт әфәнде шанына муафыйк рәвештә булмавын бәян итеп ачыналар, хурланалар: «Кеше кадерен белмиләр!» – дип, төрекләрнең хәятенә тәәссеф итәләр *(үкенәләр)*. Бунлардан икесе «Дарешшәфәка» мәктәбендә җеназаның юылган вакытында хазир булынып торганнар:

---

[3] Госманлы империаторлыгында күчемсез милеккә бәйле дәфтәрләр саклана торган дәүләт органы.

– Ике мулла илә ике сторож юдылар. Юып бетергәч тә «Фатих» җәмигына китерделәр, мәсҗеднең тышкы ягына башка җеназалар илә берлектә барсы сигез мәетне беррәттән тезеп куйдылар да, җеназа намазы вакытында: «Ир-кеше – исеме Лотфи, бала кеше – исеме Габде, – диләр, вә шунлар илә беррәттән: – ир-кеше – исеме Әхмәд Мидхәт», – диделәр, соңра каберлеккә китерделәр. Улвакыт әле кабер казылырга башланмаган иде, җеназа шунда сәгать ярым кадәр көтеп торды. Мидхәт әфәнде кебек зур бер кешенең бу рәвештә дәфен ителүенә без бик ачындык, – диләр.

Менә шулай итеп, милләт вә дин файдасына 50 елдан артык хезмәт иткән, 150 төрледән артык әсәр язган, соң нәфәсенә *(сулышына)* кадәр төрекләр файдасына тырышкан вә, ниһаять, сугыш сафында шаһид булган гаскәр шикелле, «Дарешшәфәка» мәктәбендә «Тәдрисия исламия» җәмгыятенең заседаниесендә җан биргән бөек Әхмәд Мидхәт әфәнде бер көн эчендә юк булды. Тугрысын әйткәндә: төрекләр, сәламәт вакытында аның кыймматен яхшы тәкъдир итә алмаганлыклары шикелле, җеназасын да адәм гакыллы дәфен итә алмадылар. Меңнәрчә тәәссеф *(үкенеч)*!

Мидхәт әфәнде – төрекләр арасында әдәбият, каләм вә фикер җәһәтләренчә иң күп хезмәт иткән бер кешедер. Мидхәт әфәнде төрекләрне гадәтән бер бала тәрбия иткән кебек тәрбия итеп, уку һәвәсе кертер өчен, аларга башта бик җиңел вә кыска хикәяләр язган, соңра тәдриҗән *(акрынлап)* аларны әдәбият вә фән даирәләренә тарткан, дин вә фәлсәфә бәхәсләрен изах итеп *(аңлатып)* анларның фикерләрен ачкан. Исламга тәгаррыз итүчеләргә *(басып керүчеләргә)* каршы җаваплар язып, ислам голамәсенең кулыннан килми торган әллә никадәр бөек вә мөкатдәс хезмәтләрне әда иткән *(булдырган)*. Газетачылыкта да армый-талмый тырышу хосусларында һәркемгә нәмунә *(үрнәк)* булган. «Төрекләрнең кулга алырлык мөхәррир вә мөтәфәккирләре *(фикер ияләре)* кемдер?» – дигәндә, иң беренче мәртәбә күрсәтелә торганы мәрхүм Әхмәд Мидхәт әфәнде иде.

Соң вакытларда ул бөтен куәте берлән тәгълим *(укыту)* вә тәрбия хезмәтенә керешкән икән. Дарелфөнүндә, мәдрәсәтел-вәгыйзин дә *(вәгазьчеләр мәдрәсәсендә),* дарелмөгаллиматтә әдәбият, тарихе әдьян *(диннәр тарихы),* тарихе ислам, фәлсәфә дәресләре укыткан, хәтта күбесенчә өенә кайтмаенча шушы мәктәпләрдә калып куна торган булган. Берничә җәмгыяте голамәләрдә әгъза булып, анларның тәрәккыйсенә иҗтиһад иткән. Гомумиятлә, һичтуктаусыз гыйлем вә язу юлында тырыша икән. Мәгаттәәссеф *(кызганыч),* һич көтелмәгән җирдә шундый зур фәлакәт *(кайгы)* булды.

Аңладыгымызга күрә, Мидхәт әфәнденең ике хатыны булып, бунларның берсе рум кызы икән. Дүрт углы бар. Бунларның берсе гаскәри табиб улып, хәзерендә Рум иле кыйтгасында кайдадыр бүленеп яки әсир төшеп калган. Мондагы угылларының берсе дарелфөнүндә укый, берсе бәкъкальлек (яшелчә кибете тотучы) итә, берсе матбагада мөрәттиблек *(хәреф җыючы)* хезмәтендә икән. Берничә кызы улып, бәгъзеләре *(кайберләре)* – кияүдә, бәгъзеләре әле бирелмәгәндер.

Җәнабе Хакның мәңгелек рәхмәтендә булсын бөек Мидхәт әфәнде!

Текстны һәм искәрмәләрне басмага
КФУның 3 нче курс студенты ***Азат Якупов*** *әзерләде.* ■

100 ел элек татар дөньясы

Болак елгасы. 1900 нче еллар

Балалар кичәсе

«Волга» номерларына урнашкан Татарстан Халык хуҗалыгы комиссариаты карамагындагы 500 урынлык балалар йорты уку-укыту җәһәтеннән төпле бер нигезгә куелган кебек, аң-белем тарату эшләре дә шактый яхшы юлга куелган. Мәрхәмәтсез ачлык җәзаларына чыдый алмый язмыш иркенә ташланган балалардан гына «Аң-белем» түгәрәге төзелгән. «Аң-белем» түгәрәге үз эченә төрле түгәрәкчекләрне алган кебек, кечкенә генә балалар көтепханәсен дә һәм киң, якты залга ясалган матур гына сәхнәсен дә эченә ала. Зал һәрвакыт балаларның күңел ача, төрле уеннар уйный торган урыны булып торды.

«Аң-белем» түгәрәге матди һәм мәгънәви җәһәттән төпле рәвештә тәэмин кылынган дияргә ярый. Менә шул түгәрәк тарафыннан Татарстан Җөмһүриятенең икееллык бәйрәме мөнәсәбәте белән 25 июньдә залда киң программа белән кичә ясалды. Балаларның күбесе татар балалары булганга, иң беренче татар телендә спектакль һәм концерт кыйсеме булып үтте. Соңыннан руслар үз телләрендә концерт бирделәр. Балаларның үз көчләре белән генә Г.Динмөхәммәдевнең бер пәрдәлек «Бәйрәм» дигән пьессасы куелды. Сәхнәнең һәм уйнаучыларның уйнауларында кимчелек табу мөмкин түгел иде. Концерт бүлегендә аерым, күмәк җырлар, декламацияләр, биюләр яхшы һәм уйланып хәзерләнгән иде.

«Татарстан». – 1922. – 4 июль.

Татар Җөмһүриятенең төзелүенә ике ел тулу шәрәфенә ачылган күргәзмәдә

Яхшы ясалган бу күргәзмәдә төрле күннәр, күннән эшләнгән нәрсәләр, ат сбруйлары, сүс һәм җепләр, киезләр, киез итекләр, кирпечләр, түбәгә яба торган чере-

пицалар, пыяла савытлар, сабыннар, май, глицерин, тимер савытлы кислород, азык нәрсәләреннән икмәк, күмәч, конфетлар вә башкалар бар.

Матбагачылык сәнәгате кыйсемендә – төрле хәрефләр, клишелар, дәүләт нәшрият идарәсе тарафыннан басылган китаплар. Гыйффәт туташ һәм Г.Тукай әсәрләренең русча тәрҗемәләрен күрү гаять күңелле тәэсир бирә. Гүзәл эшкә рәхмәт укып, бу бүлекне тагы да тулырак кую тиешлеген, китаплар матбагада басылып төпләнеп чыкканнан соң да, аларны яткырмау, күрсәтү кирәклеген әйтеп узабыз.

Һава флоты бүлеге дә бар. Аэропланнарның почта йөртү, урман янгыннарын сүндерү, җирнең планын алу кебек мәдәни хезмәтләргә дә яраганлыгы, 24 сәгать һавада йөри алып, сәгатенә 325 чакрым барганлыгы, 11 чакрымга кадәр менә алганлыгы күрсәтелә.

Ачлык маҗараларына урын бирелгән.

Нәҗип Шәрәф Абызов.
«Татарстан». – 1922. – 5 июль.

Мәскәүдә татар эшчеләре өчен театр

8 июльдә шимбә көн төрек-татар клубы хозурындагы драма труппасы тарафыннан «Богатырь» эшчеләре өчен бакча сәхнәсендә бушлай татарча спектакль куелды. Уен башланыр алдыннан труппа мөдире Ф.Алмай иптәш тарафыннан хәзерге әхвaль хакында доклад ясалды.

Сәхнәгә Шәриф Камал әсәрләреннән «Хаҗи бабай өйләнә» куелып, уен матур һәм тулы чыкты. Театрда халык күп иде. Алар рәхмәтләр укып, шундый кичәләрнең яңадан да ясалуларын үтенеп таралдылар.

«Эшче». – 1922. – 26 июль.

Беренче татар шифаханәсе

Казанда татарлар өчен булган беренче шифаханә тиз арада ачылачак. Мәзкүр шифаханәдә табиб һәм шәфкать туташлары татар теле белгән кешеләрдән тәгаен ителергә карар бирелгәнлектән, Татарстан халык сәламәтлеген саклау комиссариаты шул шифаханәдә хезмәт итү өчен татар теле белгән табиблар һәм шәфкать туташларыннан гариза кабул ителә башлаганлыкны белдерә.

Татар шифаханәсендә эчке гасаби (авырулар) һәм әбилек (акушерлык) бүлекләре дә ачылачак.

Адрес: Тукай урамы, 29 нчы йорт.
«Татарстан». – 1922. – 11 июль.

Татар тәгълим-тәрбия техникумы

Казанда ачыла торган тәгълим-тәрбия курслары өчен Шәһәр башкармасы Болак буендагы әүвәлге реальный училище бинасын бирергә карар кылды.

«Татарстан». – 1922. – 11 июль.

*Сәхифәне **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

«Тәтеш тауларында чабып йөри идем...»

(Бакый Урманче көндәлекләреннән)

1965 ел

Шәехзадә Бабичның[1] бюстын башладым декабрь 15тә (1964), тәмамладым гыйнварның 15ендә.

Консультацион: Мәхмүд Бөдәйли, Морад Рахманкулов, Исхак Госманов, Хәсән Туфан[2] һ.б.

[Соңрак өстәп язылган:] Апрельдә Мостай Кәрим, Разия ханым белән карап киттеләр. Алдарак Әхнәф Харисов[3] карап үткән иде.

18 гыйнвар.

Котеб Гыйззәтуллин[4] портретын башладым.

19 гыйнвар.

Башладым янарал Фатих Булатов[5] портретын.

21 гыйнвар.

Гани Сафиуллин[6] килде. Гаҗәп садәлек. Чын батыр.

[Соңрак өстәп язылган:] Сугышчыларыбызның портретлары Җиңү мәрәкәсенә тәмамлана алмады. Үкенеч.

26 февраль.

Габделхакны күрдем. Мәрьям Мөштәри[7] вафат. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун.

---

[1] *Шәехзадә Бабич* – шагыйрь, сәясәт эшлеклесе Шәехзадә Мөхәммәтзакир улы Бабич (1895-1919).

[2] *Мәхмүд Бөдәйли* – журналист, язучы, җәмәгать эшлеклесе Мәхмүд Кәшфелһади улы Бөдәйли (1895-1975). 1922 елдан Татарстан АССР Сәламәтлек саклау һәм юстиция халык комиссарлары советы рәисенең урынбасары булып эшләгән. Репрессияләнгән, соңыннан акланган. Б.Урманченың М.Бөдәйли хакында аерым хатирәсе басылган: Баки Урманче и татарская культура / сост. Ф.Ахметова-Урманче. – Казань: изд-во «Фән» АН РТ, 2005. – С.375-378 (алга таба бу китапка сылтама биргәндә «2005 елгы җыентык» дип атап, тиешле бит саны гына күрсәтелә). Көндәлек текстында «Мәхмүд» дип кенә язылганда М.Бөдәйли күздә тотылган.

Морад Рахманкулов – нәкышче, театр, кино рәссамы Әхмәтморат Шәриф улы Рахманкулов (1908-2003). Көндәлектә күбесенчә исеме белән генә – «Морад» дип теркәлгән.

Хәсән Туфан – шагыйрь Хәсән Фәхри улы Туфан (1900-1981). Репрессияләнгән, соңыннан акланган.

[3] *Мостай Кәрим* – шагыйрь, драматург, тәнкыйтьче һәм публицист Мостай Сафа улы Кәрим (Мостафа Кәримев, 1919-2005).

Әхнәф Харисов – әдип һәм филолог Әхнәф Ибраһим улы Харисов (1914-1977).

[4] *Котеб Гыйззәтуллин* – хәрби эшлекле Котеб Гайнетдин улы Гыйззәтуллин (1912-1992), Б.Урманченың сеңлесе Нәҗибәнең ире. Көндәлектә күбесенчә исеме генә язылган.

[5] *Фатих Булатов* – хәрби эшлекле, генерал-майор Фатих Гариф улы Булатов (1902-1986).

[6] *Гани Сафиуллин* – хәрби эшлекле, генерал-лейтенант, Советлар Союзы Герое Гани Биккенә улы Сафиуллин (1905-1973).

[7] *Мәрьям Мөштәри* – мәгариф хезмәткәре, педагог, табибә Мәрьям Мозаффар кызы Мөштәри (1894-1965). 1913-1920 нче елларда Тәтеш һәм Казан мәктәпләрендә укыткан.

Безнең буын, Тәтеш, Казан…
Бер вакытлар Тәтеш багларында
Яңгырак аваз берлән җырлый идем.
Тәтеш тауларында,
Тау киектәй
Йөгереп-җилеп,
Чабып йөри идем.

Апрель.

Апрельнең 20сендә Исмәгыйльдән[8] хат килә. Шундук Цигальнең[9] «Муса»[10] эскизы белән бергә фоторепродукциясе.

Шул көннәрдүк Цигаль инде Казанга килеп, үзенең эшен үткәрә башлаган. Берничә язучыны чакырганнар, сурәтчеләрдән берәү дә юк. Мине чакырмадылар карашырга. Язучыларның күбесе Ц. эшеннән разый түгел. Обком халкы шулай тавышсыз-туышсыз гына үткәреп җибәрергә уйлыйлар.

Шулай ук моннан, ягъни Татарстаннан, сурәтчеләр съездына Серовны сайларга уйлыйлар икән. Гаҗәп!

30 апрель.

Ике яшь сурәтче керде. Берсе Илдар – Суриков институтында[11] укый. Икенчесе Урицкий клубында[12] сурәтче булып эшли. Күңел күтәрерлек сүзләр. Минем хакта кайбер яшь сурәтчеләрнең әйткәннәре. Нәҗип Җиһан: «Мин Казанда аннан башка сурәтчене танымыйм», – дигән.

Апрельнең азагында консерватория өчен хәзерли торган эскизларны тәмамладым.

Шәһәр баштөзәре катындагы архитектура-сәнгать киңәшмәсе бу эшләрне карап кабул иткән һәм югары сәнгать сыйфатын билгеләгән иде.

[Соңрак өстәп язылган:] 20 декабрь, дүшәнбе. Бүген Худож[ественный] фондның сәнгать киңәшмәсе карады. Байтак сүзләрдән һәм уңай якка сөйләүчеләрдән соң Рөстәм Килдебәков, Артамонов һәм Зяблицев[13] каты тәнкыйть белән җабырылдылар.

Болар өчәве дә минем бу эшне алуыма эчләре пошып йөри иде. Инде үчләрен алдылар булса кирәк.

Бик пошиман булдым.

Карыйк, ничек барыр.

---

[8] *Исмәгыйль* – архитектор, рәссам Исмәгыйль Гали улы Гайнетдинев (1908-1977). 1949-1977 нче елларда Мәскәү Архитектура институтында укыткан. Казандагы Опера һәм балет академия театры, Елга вокзалы, Химия-технология институты һ.б. биналарның авторы һәм коручысы. Исеме көндәлектә күпчелек очракта Исмәгыйль дип кенә теркәлгән.

[9] *Цигаль* – скульптор, педагог Владимир Ефимович Цигаль (1917-2013).

[10] *Муса* – шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Мостафа улы Җәлил (1906-1944). Бу урында М.Җәлилнең Казан Кремле каршында урнаштырылачак һәйкәле күздә тотылган.

[11] *Илдар* – нәкышче Илдар Касыйм улы Зарипов (1939-2012).

[12] *Урицкий клубы* – Казандагы 16 нчы завод (хәзерге Казан моторлар төзү берләшмәсе) каршында 1955 елда барлыкка килгән спорт клубының Урицкий исемендәге мәдәният йорты. (Урицкий исемен 1962-1991 нче елларда йөрткән.)

[13] *Рөстәм Килдебәков* – нәкышче, график, монументаль бизәү сәнгате рәссамы Рөстәм Әхмәт улы Килдебәков (1934). Зяблицев – скульптор, декоратив-гамәли сәнгать остасы Георгий Аркадьевич Зяблицев (1930-2010).

7 май.

Тукай клубында[14] фашист алманнарны җиңүгә 20 ел тулу кичәсе үткәрелде. Габдрахман Әпсәләмев, Афзал Шамов, Хатыйб Госман[15] – декорлы, бизәүле рәвештә. Садри[16] һ.б. шулар арасында. Хәсән Туфан да.

Төрле вак-төяк эпизодлар… Һичбер фикер.

Бары Афзал Шамовның нәрсәдер әйтергә теләве аңлашылды.

Июнь ае Ташкәндтә үтте. Сахиб, Фәүзия, Хәмид, Рауза.

***

1918 нче ел чехлар Казанны алгач, Казан яныннан – Салтыкка, Салтыктан – Тәтешкә, Тәтештән Галимҗан Мостафин белән Колгынага, Колгынадан – Черкенгә, аннан шәкерт абыйның ярдәме белән, Казманың Гариф угылы Хәлил юлдаш булып, Чүти[17] һәм Шихран (хәзерге Канаш) аркылы Мәскәүгә киттек.

***

1918 нче ел ак чехлардан качып Мәскәүгә барганда Бакырчы, Чирмешән, Дәүләки[18], Чүти авылларында тукталдык.

Дәүләки мулласында булса кирәк, эскрипкә бар иде. Уйнадык. Мәсҗед манарасыннан бинокль белән алгы юлны күзәттек.

25 июль.

«Кечкенә Тукай»ны һәм «Галимҗан»ны[19] тәмамлап киләм.

«Моабит дәфтәре» (Муса) дәвам итә.

[Соңрак өстәп язылган:] Муса – «Моабит дәфтәре» туктап калды.

1970 елда әле һаман туктап тора.

26 декабрь, якшәмбе.

Унсигез көн кунак булып, Борһан Бадамшин[20] Әчтерханга кайтып китте. Волгоград поезды белән озаттык. Җиһан ханым һәм Йолдыз озатырга төшкәннәр иде.

Өем бик бушап калды. Борһан белән күңелле иде.

*Текстны басмага **Раиф Мәрданов** әзерләде.* ■

[14] *Тукай* – татар халык шагыйре, татар әдәбияты классигы Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукай (Тукаев, 1886-1913). Тукай клубы – Татарстан язучылар берлегенең Г.Тукай исемендәге иҗатчылар клубы.

[15] *Габдрахман Әпсәләмев* – язучы Габдрахман Сафа улы Әпсәләмев (1911-1979). *Афзал Шамов* – язучы, җәмәгать эшлеклесе Афзал (Афзалетдин) Шиһабетдин улы Шамов (1901-1990). Хатыйб Госман – әдәбият галиме Хатыйп Госман улы Госман (1908-1992). 1951-1975 нче елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире. Көндәлек язмаларында «Хатыйб» дип, исеме белән генә теркәлгән.

[16] *Садри* – шагыйрь Мөхәммәт Садри (1913-1999).

[17] *Салтык, Колгына, Черкен, Казма, Чүти* – хәзерге Татарстанның Кама Тамагы, Апас, Буа һәм Кайбыч районнарындагы татар авыллары.

[18] *Бакырчы, Чирмешән, Дәүләки* – хәзерге Татарстанның Тәтеш һәм Апас районнарындагы татар авыллары.

[19] *Галимҗан* – язучы, галим, дәүләт эшлеклесе, репрессия корбаны Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов (1887-1938).

[20] *Борһан Бадамшин* – Б.Урманченың Соловки ткотынлыгын бергә кичергән иптәше, юрист, СССР Фәннәр академиясенең Балыкчылык институтында эшләгән ихтиолог Б.Бадамшин (1899-1979). Әстерханда яшәгән. Көндәлектә күбесенчә исеме белән генә теркәлгән.

Барабаннар кемнеке дә, балалайка кемнеке?

Айрат Чанышев

Татарның «Син сазыңны уйнадың» дип аталган сузып җырлана торган моңлы бер җыры бар. Бик матур көй, бигрәк тә Илһам абый Шакиров башкаруында. Тик бу җырны тыңлаган татарларның күбесе әлеге җырның барлыкка килүенә сәбәпче булган саз дип аталган татар музыка уен коралының нинди төстә, нинди формада булуы, аның белән чиртепме, өрепме, бәрепме уйнаулары турында берни дә белми. Гомумән, татарның үз милли музыка уен кораллары хәзер онытылып, югалып беткәннәр диярлек. Ул уен коралларын өйрәнү, тикшерү, ничек булганлыкларын торгызу, аларны эшләп чыгару буенча хәзер кемнеңдер нидер эшләргә тырышуы турында хәбәрләр бик аз. Бернинди матди ярдәмсез үз акчаларына татарның музыка мирасын торгызу өстендә эшләүче берничә фидакяр энтузиастны гына күрсәтергә була.

Ә татарның музыка уен кораллары күп һәм күптөрле булган: бәрмә музыка уен кораллары да, тынлы һәм кыллы музыка уен кораллары да… Тик алар хәзер башка халыкларның милли музыка уен кораллары булып, шул халыкларның милли мәдәният мирасы булып йөриләр, шул исәптән, күп славян халыкларында да, Европадагы һәм башка халыкларда да. Язмабызда элек татарныкы булып та, бүгенге көндә башка халыкларның милли мәдәни мирасына әйләнгән кайбер музыка уен коралларына тукталып китәрбез.

Татарның бәрмә музыка уен кораллары, чынлап та, бик күп. Алар арасында дәф (татар бубены), дөңгер (дөмбер), шөлдер, дүмбәк һ.б. булган.

Фото en.crimeantatars.club сайтыннан алынды.

Галимнәр раславынча, иң беренче бәрмә музыка уен кораллары барлыкка килгән. Төрле бәйрәмнәр үткәргәндә, йолалар башкарганда борынгы кешеләр төрле ритмнар белән такмаклар әйткәннәр, биегәннәр, шул вакытта кулларын чапылдатып, төрле таяк һәм сөяк кисәкләрен бер-берсенә, башка предметларга бәреп, әлеге ритмнарга иярә торган булганнар. Дини инанулар килеп чыккач, бәрмә уен кораллары шаманнарның төп уен коралына әйләнгән. Борынгы татар-төркиләр Мәңгелек Зәңгәр Күккә табынганнар, дини йолаларын башкаручылар аларда камнар дип аталган. Ә камның инде төп инструменты, язып үткәнемчә, бәрмә уен коралы булган. Татар-төркиләрнең бәрмә уен кораллары күптөрле дигән идем: дөмбәк (дүмбәләк, кырым татарларында – дарбука), дәф (татар бубены), барабан, дөңгер (дөмбер), шөлдер, төрле кыңгыраулар, шакылдыклар һ.б. Ул бәрмә уен коралларының, татарныкы булып та, башка халыкларның мәдәни мирасына әйләнгән кайберләренә тукталып китик.

Әлбәттә инде, бүгенге көндә иң күп кулланыла торган бәрмә музыка уен коралы – **барабан.** Барабан – саф татар уен коралы, моны бу сүзнең барлыкка килүе үк 100 процентка дәлилли. Радлов, мәсәлән, бернинди дә шиксез, барабан, Казан татарларының «бәрә+баң» сүзтезмәсеннән барлыкка килгән дип яза (баң – барабан чыгарган тавыш, бәргәч – баң), башка белгечләрнең фикерләре дә шуңа охшаш, тик аларның күбесе «бәрә баң» гыйбарәсенең татар-төркиләрнең башка төркемнәрендәге әйтелешләрен кулланалар.

Сугыш вакытында татарлар зур барабан – **толымбас** та кулланганнар, ул казан рәвешле киергегә зур тирене тарттырып эшләнгән. Толымбасларның уртача зурлыктагыларыннан алып бик зурларына кадәр булган. Үгез тиресе тарттырылып эшләнгән толымбасларны татарлар походлар вакытында ат арбаларына салып йөрткәннәр. Толымбасның көчле тавышы яугирләргә дәрт өстәгән, каршы як сугышчыларны исә куркуга салган. Исеменнән үк татарныкы икәнлеге кычкырып торган бу музыка уен коралын хәзер руслар да, украиннар да, башка халыклар да үзләренеке дип игълан итәләр, ә татарда исә аны белгән өйрәнгән, кеше дә юк, татар толымбасларын торгызырга тырышкан шәхесләр турында әйтәсе дә юк инде. Рус чыганакларында толымбаслар казакларда кулланылган дип язалар, ә казаклар исә – шул ук татарлар, хәрби йөкләмә үтәгән руслашкан татарлар. Казаклар аларны полк барабаннары, хәрби сигнал коралы буларак кулланганнар.

Зур толымбаслар татар авыл-шәһәрләрендә чаң ролен дә үтәгәннәр. Берәр көтелмәгән вакыйга булып, халыкны тиз арада мәйданга җыярга кирәк булганда, татарлар каланча башларына махсус урнаштырылган шул металл толымбасларга суга торган булганнар, аның яңгырашы берничә чакрымга кадәр таралган. Татар шәһәрләрендә урнаштырылган каланча толымбаслары шулкадәр зур булганнар ки, аларга сугар өчен берьюлы сигез кеше кирәк булган.

Татарлар каланчаларга урнаштырылган андый зур толымбасларны нәүбәт дип атаганнар. Нәүбәт татарча «чират» дигәнне аңлата. Татарлар яу килгәнне күзәтеп тору өчен яисә янгын кебек хәвеф-хәтәр чыкмасын дип, каланча башында чиратлап кизү торганнар, бу чират-нәүбәт вакытлар үтү белән каланчага урнаштырылган шул зур чаңны да, халыкны мәйданга чакыру оранын да аңлата башлаган. Шулай итеп, татарның сак хезмәте, сак хезмәте чаңы, халыкны дәррәү күтәрү ораны русларга һәм башка күп халыкларга набат сүзе булып кереп калган да инде (Аверкиев: «Слово, означающее смену, перемену» (монда каланча башындагы кизү-каравылның (татарның кара+авыл сүзеннән) чиратлап алмашынып торуы күз алдында тотыла); Шипова; Фасмер һ.б.).

Татар яугирләре иярләренә кечкенә калай-металл кисәкчекләре бәйләп куя торган булганнар. Бу җайланмалар яугирләрнең рухын күтәрү, дошманнарны куркыту өчен кулланылган. Инде алдан әйтеп кителгәнчә, татарлар сугыш вакытында психологик атака өчен музыка уен коралларын киң кулланганнар. Сугышка керер алдыннан дошманнарның котын алу максатында татар гаскәрләрендә зур толымбаслар, сорнайлар, торба-быргылардан торган тулы бер оркестрлар кулланылган. Шул оркестрларның яуга өндәп чакырулары вакытында татар яугирләре иярләрендәге металл-калай кисәкчекләренә бер тактта даң-даң итеп камчы сабы белән суга торган булганнар. Әлеге хәрәкәтләр яугирләрне психологик яктан әзерләгән, артык стресслардан арындырган. Ияргә бәйләп куелган шундый җайланмаларга татарлар нәкарә дигәннәр, ул – татардагы гарәп алынмасы, даң-даң сугарга дигәнне аңлата. Татарның физик һәм психологик тренинг буларак яу алдыннан кулланылган шул хәрби тактика җайланмасы соңыннан аерым бер музыка уен коралы – нагара, накра булып күп халыкларның милли музыка коралына әйләнгән. Русларның накрасы, мәсәлән, гади керамик чүлмәккә тарттырылган тире формасында. Аверкиев язуынча, татар атлылары нәкарәне халык күп булган урыннардан үткән вакытта сигнал бирү өчен дә файдаланганнар, ияргә (кузлага) беркетелгән металл кисәкләренә камчы, чыбыркы сабы белән сугып, шулай хәбәр җиткерә торган булганнар. Шулай итеп, татарлар, юл хәрәкәтләрендә хәвеф-хәтәр булдырмау өчен, иң беренче сигнал җайланмалары – клаксон куллана башлаган халык та әле.

Татарның башка бик күп халыкларга бүләк иткән тагын бер бәрмә уен коралы – **цимбаллар**. Бу уен коралы – татарның чәмбалы. Әлеге инструмент Алтын Урдада бик популяр булган. (Алтын Урда дәүләте барлыкка килүнең беренче чорларында, XIII гасырда ук.) Ә русларда бу музыка уен коралы цимбал термины астында беренче тапкыр фәкать XVI гасырда гына искә алына, Европа илләрендә исә аннан да соңрак. Шулай итеп, татарның чәмбалы XVI гасырда русларга күчкән, ә аннары, шул татар аталышында, рус, белорус, украин, поляк, молдаван, румын, герман, француз һ.б. халыкларга таралган. Әлбәттә, европа халыкларында татарның чәмбалына охшаш уен кораллары элек тә булган, тик алар башка исемнәр белән аталып йөртелгәннәр, татар аталышлы цинбал-цынбал һ.б. Европада XVI гасырдан соң гына барлыкка килгәннәр.

Европа халыкларының һәм русларның литавралары да татардан, шәрыктан. Татарлар аны элек табл дип атаганнар (Кятиб: «Меңе табл орар ирди ...»). Литавра сүзе гарәп алынмасы – «әл-табл», ә ул исә «зур барабан» дигәнне аңлата.

Хәзер инде татарныкы булган һәм соңрак башка халыкларның мәдәни мирасына әйләнгән кайбер кыллы музыка уен коралларына тукталып китик.

Кыллы музыка уен кораллары дала, елкы күп булган халыкларда килеп чыккан. Музыка уен коралы өчен ныклы, озын кыл кирәк булган, ә андый кыл – елкыны күп тоткан халыкларда. Игенчелек белән көн күргән халыкларда исә ниндидер кыллы, кыллы-чиртмә музыка уен коралы килеп чыгу мөмкин түгел. Музыка уен коралы өчен кылны, гадәттә, елкы койрыгыннан кисеп алганнар, аннары аны пычак белән тигезләгәннәр. Шуңа да дала халыкларында, татар-төркиләрдә кыллы, кыллы-чиртмә, кыллы-сызгычлы музыка уен кораллары аеруча киң таралган булган, себер татарларында алар бигрәк тә күп. Тик бу мәкаләбездә аларны санап чыгу, тасвирлау белән мавыкмыйча, элек татарныкы булып, хәзер исә башка халыкларның милли мәдәни мирасына әйләнгән кайберләре турында гына язып үтәрбез.

Русларның домрасы **татарның думбырасы** булуы турында аның исеме үк әйтеп тора. Татарның бу милли мирасы шулай ук украиннарның, белорусларның милли

музыка уен коралы да булып киткән. Күп халыкларның милли уен коралы булып исәпләнүче танбур/тамбур/тамбурин – шул ук татар думбырасы, татар думбыры, татар тамбыр-танбуры.

Хәзер инде рус халкының гусли дип аталучы музыка уен коралын карап китик. Рус чыганаклары бу сүзнең барлыкка килүен, гадәттә, иске славян телендәге гнудеть, гудеть яки җәя керешен аңлатучы гусла сүзләре белән аңлатырга тырышалар. Әлбәттә, әлеге аңлатулар бернинди тәнкыйтьне дә күтәрә алмый. Беренче варианттагы ул гнуди/гуди сүзләренең яңгырашын гусли яңгырашына берничек тә якын китереп булмый. Ә икенче версия буенча, монда җәянең һәм җәя керешенең ни катнашы бар? Ул сызгычлы музыка уен коралы түгел бит. Ә кайбер ура-патриотларның: «Рус гөсләсенә мең ел ярым!» – дип шапырынулары, гомумән, көлке. Алар бу вакытта Византия елъязмаларында ике славянның Авар каһанлыгыннан качып килүе, аларның кифарада уйнаганнары турындагы истәлекләрне дәлил итеп китерәләр. Монда *гөслә* дигән сүз, гомумән, телгә алынмый, ә грек милли музыка уен коралы – кифара, аннары, бернинди дә руслар түгел, ә славяннар.

Гусли татарча *гөслә* була. Бу уен коралының атамасын гөслә, гөс сүзеннән, гөс-гөс сүзеннән, гөс-гөс итеп уйна сүзләреннән барлыкка килгән дип исәпләгән вакытта барысы да үз урынына утыра. Монда инде гөсне бу музыка уен коралы чыгарган аваз дип уйларга кирәк. Ни өчен гөс-гөс, ә зың-зың да, чың-чың да, даң-даң да түгел? Хикмәт шунда: элекке гөсләләр кылдан түгел, ә мал эчәгесеннән эшләнә торган булган. Татарлар яңа суелган малның нечкә эчәген буй-буй кисеп, тарттырып бәйләп, күләгәдә киптергәннәр, шуннан тагын тарттырганнар, аннары инде гөсләдә уйнар өчен эчәк-кыл барлыкка килгән. Кайвакыт гөслә кылы өчен мал сеңерләре дә файдаланылган. Төрле калынлыктагы, төрле киңлектәге, төрле озынлыктагы бу эчәк-кыллар төрле ноталар бирә алганнар. Һәм дә инде бу эчәк-кыллар бернинди зың-зың да, чың-чың да түгел, ә гөс-гөс дигән аваз чыгарганнар. Татарлар, гадәттә, 12 кыллы гөслә ясый торган булганнар, 24 кыллы гөсләләр дә булган. Менә шуннан килеп чыккан да инде татарның гөсләсе, татарның гөс-гөс тавыш бирүче музыка уен коралы. Гусляр исә татарның гөсләре, ягъни гөс-гөс итүчесе, гөс-гөс итеп уйнаучы мәгънәсендә.

Гөслә – татар фольклорында, җыр-бәетләрендә («Уңган кызлар гөслә чиртсә/ җырлар сибелә генә...»), әкият-дастаннарында киң урын алган борынгы музыка уен коралы. Мисал өчен «Гөлчәчәк» исемле борынгы татар халык әкиятен алыйк. Анда Гөлчәчәк атлы бер яшь килен, усал каенанасыннан качып, әтисе йортына кайтканда, каенанасы, бүрегә әверелеп, аның артыннан куа төшә, ә шулчакта Гөлчәчәкнең абыйсы үз өендә гөслә чиртә башлый, һәм гөслә кеше телендә: «Чиртмә, чиртмә, абыем, башыкаем авырта!» – дип җырлап, кызны коткаруны сорый...

Югарыда китерелгәннәрне искә алып, гөслә – борынгы татар музыка уен коралы, русларга һәм башка халыкларга бу инструмент татарлардан күчкән дип ныклап әйтә алабыз.

Руслар үзләренең милли үзенчәлекләре, милли символлары дигән вакытта, гадәттә, аракы (водка), колакчын бүрек (шапка-ушанка), гармонь, мунча һәм бала-

лайканы искә алалар. Темабыздан бераз гына читкә китеп, боларның барысының да татарныкы, татар-төркинеке булуын, аларның татардан алынганын әйтеп китик. Мунчаны Европага татарларның ерак бабалары скифлар алып килгән, шул исәптән, русларның бабаларына да. Спиртны исә гарәпләр уйлап тапкан, берничә гасыр буена спирт, алкоголь белән сәүдә итү гарәпләр кулында, гарәпләр монополиясендә булган. Әлбәттә, мөселман гарәпләр бу сыеклыкны медицинада, хушбуй эшләү һ.б. максатларда гына кулланганнар. Тик гарәпләрдән сатып алынган спирт башка халыкларда исерткеч эчемлек буларак та кулланыла башлаган. Шул ук вакытта Алтын Урдада да. Һәрхәлдә, Үзбәк ханга, ул ислам динен кабул иткәнгә кадәр. Спирт ул заманнарда бик кыйммәт булган, аны эчемлек итеп аксөякләр генә куллана алган, кулланганда да су белән катнаштырганнар. Алтын Урданың бер олысы булган Московиянең югары даирә вәкилләре дә бу эчемлекне кулланмый калмаган. Элек әлеге эчемлек Московиядә саф татарча: арак, араки яки раки дип аталган (Аверкиев). Гармонь дигәненә исә без әле тукталып китәрбез. Ә колакчын бүрек, малахай бүрек – саф татар баш киеме. XIII гасыр Европа рәсемнәрендә бар татарлар да колакчын бүректә күрсәтелгәннәр, ә Московия турындагы урта гасыр рәсемнәрендә бернинди дә шапка-ушанка да, малахай да юк, колакчын бүрекне Европага, шул исәптән, русларның бабаларына да татарлар алып килгән. Чөнки колакчын бүрек атта барганда уңайлы булган, ул колакларны һәм битне җил-бураннан яхшы саклаган.

Балалайкага әйләнеп кайтыйк. Бу сүзнең, шул җөмләдән музыка уен коралының да татарныкы булуы күп белгечләрдә (Радлов, Горяев, Шипова һ.б.) бернинди дә шик уятмый. «Название «балалайка», по Рейфу и Горяйнову, позаимствовано у татар. Фаминцын видел в балалайке видоизмененную домбру казаков (казахов), отличающуюся от балалайки тем, что нижний край ее треугольной деки короче балалаечного, и она имеет только две струны» (Аверкиев). Галимнәр балалайканы, күп кенә башка сүзләр кебек үк, татарның «бала» сүзеннән барлыкка килгән дип язалар. Кайбер белгечләр генә балаболить, балагурить, балакать кебек фигыльләр белән бәйләргә тырышалар. Тик авторлар китергән бар фигыльләр дә – татар алынмалары, татарның бала сүзеннән барлыкка килүен әйтергә генә онытала́р. Шипова сүзлеген карагыз: балабол (бала+бул), балаболить (бала-чага кебек кылану); балагурить (бала+говорить, бала кебек сөйләү, кылану); балакать (бала-калядан, бала кебек сөйләшүдән.) Ә Фасмер бу сүз русларга полякларның bałakać (балакач) сүзеннән кергән, ди, анысы исә, үз чиратында, татарның бәләкәч сүзе.

Шулай итеп, балалайканың татардагы «бала» сүзеннән барлыкка килүен бар этимологлар да таный. Ә «лайка» кушымчасы каян килеп чыккан соң? Монысына инде Фасмер һәм Даль сүзлекләре ачыклык кертә: Фасмер: «Балала́йка также балаба́йка, бала́бойка, южн., зап. (Даль), укр. балаба́йка ...». Бу этимологик сүзлекләрдән күренгәнчә, балалайка белән балабайка – икесе бер үк сүз (Шиповада һ.б. чыганакларда да шул ук), ә украиннар исә бу уен коралын элек гел балабайка дип кенә йөрткәннәр. Монда инде үзеннән-үзе шундый сүзкорылма күз алдына килеп баса: бала+бай, бала+бай-бай. Ягъни саф татарча бала+бәй-бәй. Баланы бәй-бәй итеп бишектә йоклаткан вакытта уйный торган музыка уен коралы, кушымтасын русчалап әйткәндә бала+бай-байка.

Ахыры киләсе санда ■

Җуелмас хәзинә

«Бала уйнатканда» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Тәртип радиосы

Бала уйнатканда

(Татар халык җыры)

Әлли-бәлли итәргә тал бишеге бар аның,
Иркәләргә, сөяргә үз әнкәсе бар аның,
Әй-әй-йәй...
Әтисенә ай кебек, әнисенә көн кебек,
Апасына гөл кебек лә, әбисенә туп кебек,
Килеп киткән кешеләргә чүп кадәр дә юк кебек,
Килеп киткән кешеләргә чүп кадәр дә юк кебек.

Тыпыр-тыпыр биидер, аягы җиргә тимидер,
Очкан коштай талпынып, канатларын кагынып,
Һап-һап-һап...
Чәбәк-чәбәк әткәсе, биетеп тора әнкәсе,
Такмак әйтә апасы ла: әттә-түдел-түдәсе...
Авызын-күзен мимылдатып, карап тора әбкәсе,
Авызын-күзен мимылдатып, карап тора әбкәсе.

Үсеп буйга җитәр бу, галим булып китәр бу,
Туып-үскән иленә тырышып хезмәт итәр бу,
Әй-әй-йәй...
Минем кызым бик иркә, башларында кәсинкә,
Аягында бәтинкә дә, күлмәге дә сәрпинкә,
Алтын чәчле, зәңгәр күзле – коеп куйган кәртинкә,
Алтын чәчле, зәңгәр күзле – коеп куйган кәртинкә.
Әй!

Җырчы, ТАССРның атказанган артисткасы, Тукай районының Борды авылы тумасы Раиса Григорий кызы Тимофеева

«Бала уйнатканда» – сугыш елларында иҗат ителгән күңелле, шаян җыр. Бу җырны Мәрьям Рахманкулова башкарганда бөтен зал гөр килеп кул чаба торган булган.

Мәрьям Рахманкуловага аны баянчы Рокыя Ибраһимова өйрәткән. Рокыя Ибраһимова исә аны артистка Гөлчәһрә Байкинадан отып алган.

– Бу җырны кемнән ишеттең? – дигән сорауга Гөлчәһрә Байкина:

– Сугыш елларында халыкның күңелен күтәрергә кирәк иде. Күңелле репертуар аз булганлыктан, җырларны үзебез уйлап чыгара торган идек. Бу җырның сүзләре дә, көе дә, ничектер, үзеннән-үзе килеп чыкты, – дип җавап биргән.

Әлеге хәл 1944 елда Мамадышта булган.

Бу җыр җырчы, Татарстанның атказанган артисткасы, Тукай районының Борды авылы тумасы Раиса Тимофеева (1929-2013) репертуарында да бар.

*Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзгә» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – **Гөлфия Мөхәммәтгәрәева)** материалларына нигезләнеп, **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Нәҗип Нәккаш: «Әбидән калган Коръән кисәкләре җәлеп итте»

(Рәссам-каллиграф Нәҗип Нәккаш белән Ленар Гобәйдуллин әңгәмәсе)

Мамадыш районының Үсәли авылы тумасы Нәҗип Фәйзрахман улы Исмәгыйлев (Нәҗип Нәккаш) – әдәбият галиме-текстолог, нәкышчы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе (1998), Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе (2016), ТРның рәссамнар берлеге, РФнең каллиграфлар милли берлеге әгъзасы.

«Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Ленар Гобәйдуллин һәм Ләйләгөл Сафина каллиграф Нәҗип Нәккаш янында

«Партия, профсоюз плакатларын язу белән шөгыльләндем»

– Каллиграфия сәнгатенә кереп китүегез ничек булды?

– Рәсем ясуга һәвәслегем балачактан ук килә. Без мәктәптә укыганда ук корыч каләм белән карага манып язган кешеләр. Элек мәктәптә матур язу аерым предмет буларак укытыла иде. Аның каллиграфлар тарафыннан эшләнгән махсус дәфтәре, хәтта парта өстендә каләмне ничек дөрес итеп тотарга икәнен күрсәткән плакаты

да хәтеремдә калган. Минем язу башка балаларныкына караганда матуррак килеп чыга иде. Шунда үземнең матур язуга, элекке мәдрәсәләр теле белән әйтсәк, «хөсне хат»ка сәләтемне сиздем. Укытучы апамның да, үрнәк итеп башкаларга күрсәтү өчен, эшләремне аерып алып җыеп барганын яхшы хәтерлим. Соңрак мәктәптә чыга торган стена газетасына мине рәссам итеп сайлап куйдылар. 11 сыйныфны тәмамлаганчы бу вазыйфа минем өстә калды. Матур язуга сәләтемне белеп алып, китапханә һәм клуб хезмәткәрләре дә, үзләренең плакатларын, игъланнарын бизәр өчен, мине чакырдылар.

– Сез, хаттат булып, матур язу өчен дөньяга килгәнсез кебек... Бу юнәлештә махсус белем алдыгызмы?

– Махсус белем алырга омтылып карадым, әмма, сәнгать мәктәбен узмау сәбәпле, мине укырга алмадылар. Мәктәптә балалар укыта башладым. Үзегезгә мәгълүм: партия, төрле лозунглар вакыты. Плакат язу шул чорның үтемле коралы иде. Мәктәптә мин, рәсем дәресләрен укытудан кала, бер үк вакытта рәссам-бизәүче дә булып эшләдем. Мәскәүдәге Крупская исемендәге Сәнгать институтына читтән торып укырга кердем, рәсем сәнгате буенча югары белем алдым. Әмма сынлы сәнгать, портретлар ясау буенча эшем барып чыкмый, шулай да натюрморт, пейзаж ярыйсы гына килеп чыга. Ә язу, каллиграфиям бик яхшы. Партия, профсоюз плакатларын язу белән шөгыльләнүне дәвам иттем.

«Безнең мирас» туграсы: «Мирасы барның киләчәге бар». ***Нәҗип Нәккаш эше***

«Бакый Урманчедан дәресләр алдым»

– Ә гарәп язуы игътибарыгызны ничек җәлеп итте? Югыйсә совет плакатлары белән гарәби-мөселман язуы – икесе ике дөнья...

– Әти ясаган шкафның эчендә әбидән калган Коръән кисәкләре бар иде. Аять араларындагы буш урынга ясалган бизәкләр игътибарымны аеруча җәлеп итте. Аларның алма, кыңгырау чәчәгенә охшаганнары да бар иде. Мәктәптә эшләгәндә үк гарәп язуын өйрәнәсем килде. Ул телне «Гарәпчә-русча-татарча» алынмалар сүзлеге ярдәмендә үзләштерергә тырышып карадым – барып чыкмады. Моның өчен остаз кирәген аңладым. Мин мәктәптә укыганда иншаларны да эчтәлекле итеп яза идем. Әдәбият укытучым Мәрьям Мозаффаровна, сәләтемне күреп алып: «Нәҗип, Казанга бар, гыйлем ал!» – дип, мине үгетли килде. 1974 елны мин Казанга китәргә, университетның тарих-филология факультетына укырга керергә тәвәккәлләдем. Бәхетемә, биредә 1 нче курстан ук иске татар язуын һәм гарәп телен укыталар икән. Гарәп телен безгә Ленинград университетының Көнчыгыш телләр факультетын тәмамлап кайткан яшь белгеч Лена Таҗиева укытты. Курсташларым немец яки инглиз телен өйрәнсә, мин гарәп телен сайладым. Сәбәбе нидәндер – белмим, гарәп телен өйрәнергә омтылышым көчле иде. Студент вакытта ук гарәби текстларны матур итеп язарга да өйрәнә башладым. Рәсем ясау сәләтем булу, плакатлар язып тәҗрибә туплавым сәбәпле, гарәп язуым да матур гына килеп чыкты һәм укытучыларымның игътибарын җәлеп итте.

Әдәбият галиме Хатыйп Миңнегуловтан курс эше язып, «Хөсрәү вә Ширин»дәге афоримнарны өйрәндем, ә инде 3 нче курста профессор Хатыйп ага Госман мине «Мәҗмугыль-хикәят» дигән бик тә борынгы һәм кызыклы дөньяга кертеп җибәрде. Фотокопияләр ярдәмендә борынгы текстларны укып, диплом эше якладым. Хатыйп ага 4 нче курста укыганда ук гарәби язуның киләчәктә миңа кирәк буласын сизеп, мине каллиграфиягә өйрәтә башлады. Университеттан ике укытучыны – Фәһимә Хисамова белән Хәлил Сәлимовны, ике студентны – булачак тарихчы Искәндәр Гыйләҗев һәм мине Бакый Урманче остаханәсенә укырга җибәрде. Бу вакытта Бакый ага Кырлайдагы Тукай музее өчен агач тәпәннәрдән сын-гравюралар ясый иде. Безне: «Дусларым!» – дип гел елмаеп каршы алыр, Флора апа Урманче янына, остаханәнең икенче катына алып менеп чәй эчерер, кулга каләм алырга, камыш каләм формасында тимер каләмнәр ясарга һәм язарга өйрәтер иде. Шулай итеп, олуг остаздан да 3-4 дәрес алып калу бәхетенә ирештем. Бу безнең өчен бик файдалы булды. Бакый аганың китапханәсе дә гаять бай иде. Шундагы төрки, фарсы һәм гарәп китаплары үрнәгендә язарга өйрәнеп, тәҗрибә тупладык.

Бакый ага заманында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган. Атасы Идрис хәзрәт аны ун яшендә мәдрәсәгә китергән һәм шуннан соң ул туган авылына кунакка гына кайткалаган. Мәгълүм булганча, XX гасыр мәдрәсәләрендә матур язу аерым дәрес буларак укытылган. Бу чорда матур язу традицияләрен элекке мәдрәсәләрдән безнең буынга китереп җиткергән бердәнбер кеше Бакый Урманче иде. 70 ел дәвамындагы атеизм чорында әлеге традиция югала, онытыла барды. Хәтта Бакый Урманче үзе дә каллиграфиягә бәйле хезмәтләрен күргәзмәләрдә күрсәтә алмады.

Хаттатлар, битикчеләр һәм кятибләр

– Шамаилләргә беренче кердегезме, әллә туграларгамы?

– Әлбәттә, шамаилгә. Тугра – татарда булмаган жанр.

– Алтын Урдада булмаганмы?

– Дөрес, Алтын Урдада күпмедер дәрәҗәдә булган, әмма төрек солтаннары, Кырым татарларының ханнарындагы кебек югары үсешкә ирешмәгән. Алтын Урда ярлыкларында турыпочмак яки квадрат формасындагы мөһерләр бар. Аларда шәһадәт кәлимәсе һәм кыска аятьләр язылган. Тугра 13 нче йөз азагы-XIV гасыр башында төрек солтаннарында киң тарала. Госманлы дәүләтенең солтаннары фәрманнарына, ярлыкларына, башка дәүләтләргә язган хатларына туграны еш куя торган булганнар. Туграны аерым оста, ә каллиграфиясен башка хаттат язган. Аларны төрекчә «тугра киши» дип тә йөрткәннәр. Бу кешеләр алтын буяулар, чәчәк орнаментлары белән бик оста итеп тугра иҗат итә торган булган. Аларның үрнәкләре Мәскәүдәге Россиянең борынгы дәүләт актлары архивында саклана. Бу турыда махсус фәнни эзләнүләр дә бар. Кырым татарларында да, госманлы төрекләре йогынтысында, тугра традициясе үсеш алган.

– Идел буенда ни өчен югары дәрәҗәдә үсеш алмады икән?

– Дәүләт дәрәҗәсенә һәм тотрыклылыгына бәйледер. Тугра ясау өчен хаттатлар институтының үсеш алуы, ә аның өчен дәүләт тарафыннан тәгаенләнгән акча кирәк. Ә бездә ханнар бер-берсе белән сугышып, ил-көн иминлегенә, бәрәкәтенә зыян салган.

– Алтын Урдада битикчеләр булганын да беләбез...

– Битикче хаттатның төрки варианты инде. Бөтү, бити – язу дигән сүз. Татар халкы борынгыдан бөти тагып йөрергә ярата. Әлеге сүзнең нигезе дә шуңа барып

Нәҗип Нәккаш остаханәсендә

тоташа. Кайберәүләр аны, кытайларның «пити»ләреннән килеп чыкмадымы икән, диләр. Борынгы текстларга: «Бу хатны бетеде...» – дип язганнар.

Татарда «кятиб» дигән сүз дә бар. Ул гарәп телендәге «кәтәбә» тамырыннан алынган. Сәркатип сүзе дә шуннан килеп кергән. Мәктүб – язылган әйбер, ә «мәктәп» – яза торган урын. Барысы да бер тамырдан килеп чыккан сүзләр.

«Гарәп графикасы – дөньядагы иң матур язу»

– Гарәп язуы ярдәмендә образлар тудырырга авырмы?

– Бик җиңел! Гарәп графикасы – дөньядагы иң матур, мөмкинлекләре зур булган сәнгатьле язу. Биредә һәр хәрефнең язылышы дүрт төрле. Моннан тыш, гарәп язуының алты төре бар, шуның дүртесе татарларда аеруча киң таралган. Кош, орнамент, үсемлек-чәчәк композицияләрен ясар өчен дә гарәп хәрефләре бик уңайлы. Хыялың белән фантазияң генә бай булсын. Тугра стиле белән дә кыска аять һәм хәдисләрне матур итеп язарга була.

– Гарәп язуының нинди төрләрен файдаланасыз?

– Өч-дүрт төрен иҗатымда яратып файдаланам. Шамаилләрдә – нәсех, тугралар-да – сөлес, мәчет бизәлешендәге дивари стильдә куфи язуын кулланам. Имәнлек бистәсендә яңа мәчет төзеделәр. Шуның өчен унга якын эскиз эшләп бирдем. Тышкы ягында куфи язуыннан файдалансам, эчендә сөлесне кулай дип таптым.

– Сезнең эшне тагын Татарстандагы кайсы мәчетләрдә күрергә була?

– Казандагы «Ярдәм»мәчетенең эче, тышы, миһрабы минем эскиз буенча эшләнде. Шул ук эскизларны Шәңгәлче, Афанас авылларындагы һәм Лениногорскидагы, Казандагы Борисоглебск бистәсендәге мәчетләрдә дә файдаландылар. Аларны ирле-хатынлы Мусиннар башкарды.

– Бауман урамындагы сәгать Казан шәһәре үзәге символларының берсенә әйләнде.

– Әлеге сәгать үзем өчен дә бик кадерле. Металл остасы Игорь Башмаков металлдан Тукайның өч шигыренә скульптур композиция эшләгән. «Пар ат», «Кечкенә

музыкант» һәм «Фатыйма белән сандугач»ны сайлап алган. Гарәп язуы да булсын иде дип уйлап, каллиграфик бизәлешне миңа тәкъдим итте. Сәгатькә сан (цифр) урынына хәреф белән язарга уйладым, чөнки татар саннары бер йә ике иҗектән генә тора. Шулай итеп, уникегә кадәрге сан түгәрәк композициягә кереп урнашты һәм матур гына сәгать килеп чыкты. Моннан тыш, анда Тукай шигырьләреннән өч табло да бар. Беренчесенә: «Тыныч кына утырган да безнең шагыйрь, Өй турында кемдер исә быргы уйный», – дип; икенчесенә: «Бар, яшел урманга оч. Ятим балаларың белән кавыш», – дип; ә өченчесенә: «И Казан! Дәртле Казан, нурлы Казан, моңлы Казан!» – дигән юлларны сайлап алдым. Кызганыч, күпләр, хәтта журналистлар да моны гарәпчә язу дип уйлый. Әмма ул безнең үзебезнеке – татарныкы!

«Борынгы осталар хатадан сакланган»

– Нинди каләмнәрдән файдаланасыз?

– Безнең якта каллиграфиягә яраклы камыш юк, ә каурый каләмне тиешле дәрәҗәдә эшкәртергә, чыныктырырга кирәк. Читтән китерелгән камыш, бамбук, тимер, япон каләмнәре, хәтта совет чорыннан калган плакат каләме белән дә язам. Шулар ярдәмендә ике меңгә якын тугра ясадым инде. Ә шамаилләрнең санын үзем дә белмим. Хәзерге вакытта бөек шәхесләребезгә багышланган тугралар циклын иҗат итәм. 2016 елда Тукайдан башладым. Каюм Насыйри, Ризаэддин Фәхреддин, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Исмәгыйль Гаспралыларга тугралар ясадым инде.

– Элекке, әби-бабаларыбыздан калган шамаилләрне өйрәнәсезме?

– Аларны аерым осталар ясаган. Соңгы елларда бу юнәлештә конкурслар узды, Кол Шәриф мәчетендә махсус күргәзмә дә оештырылды. Татарда элек пыялага язу традициясе булган. Гадәттә, анда «Аятел-Көрси» һәм башка догалар язылган. Мәчетләрне бала-чага рәсеме кебек кенә ясаганнар. Каллиграфия дә бик гади. Элекке осталар, стильне бик сакламасалар да, текстларны гаять төгәл һәм дөрес язганнар, хәтта хәрәкәләренә кадәр куйганнар. Алар Коръән аятьләренә изге дип карап, аны бозарга ярамаганын бик яхшы аңлаганнар, хатадан сакланганнар. Дөрес, бик яхшы эшләнгән шамаилләр дә бар. Мондыйларын исә Казан осталары ясаган. Хәзерге вакытта мин дә пыялага язу традициясен дәвам итәм. Кайда пыяла күрсәм, аны үземнең остаханәмә алырга тырышам.

– Татар каллиграфиясе тагын нинди юнәлешләрдә үсеш алган?

– Кабер ташлары ясаучылар белән элемтәдә торам. Ташчы осталар минем эскиз буенча ясалган туграларны гранит һәм мәрмәргә төшерәләр. Аларның кайберләрен Казан ханлыгы ташлары үрнәгендә дә эшлим.

Милли музейда саклана торган мөһерләрне, шамаилләрне дә өйрәнеп, текстларын укып, тасвирлап, аерым җыентык әзерләдем, ул тиздән альбом булып чыгачак. Шулай ук хатын-кыз бизәнү әйберләренә уелган гарәп язуларын да укыдым. Бигрәк тә көмеш тәңкәләрне, беләзекләрне, чәчкапларны гарәби язулы текстлар белән бизәргә яратканнар. Егет, ярәшкәннән соң, кыз янына килеп йөргән. Хәтта никахтан соң да кызны тиз генә биреп җибәрмәгәннәр. Егет, кәләше янына барган саен, балдак, беләзек йә чәчкә куела торган тәңкә алып килгән. Җирле осталар көмеш материалга кыз белән егетнең исемен, шуңа өстәп, матур теләкләрне чокып яза торган булганнар. Мондый бүләк кызның шәхси милкенә әйләнгән. Көмеш үз кыйммәтен беркайчан югалтмаган. Күрүегезчә, татар каллиграфиясе бик бай һәм күптармаклы. ■

«Папайланган сары тузганак»

(Яңа Усы керәшеннәренең җәйге бәйрәм җырлары)

....

Елизавета Митюшкина, Лариса Петрова

Мөслим районының Яңа Усы төп гомуми белем бирү мәктәбе укытучылары Елизавета Митюшкина һәм Лариса Петрова

Микула белән җәй башланды

Җәйге Микуланы, гадәттә, рус һәм керәшен авылларында язгы чәчү тәмамланганнан соң 22 майда билгеләп узганнар. Шул көннән алып җәй башланган. Ул яшьләр бәйрәме дип саналган. Кызлар, бергә җыелып, кулга-кул тотынып, төрле җырлар җырлап әйләнгәннәр, төрле уеннар уйнаганнар. Микула җитми җәй булмый, Микула җитми кыш булмый, дигәннәр.

Сынамышлар:
- Майның 22сендә төнлә йолдызлар еш күренсә, ашлыклар уңар.
- Ай киртәләнсә, тиздән яңгыр булыр.
- Кояш бик еракта булып күренсә, салкын булыр.

Җыр:
Гомеркәйләр шулай узып бара,
Минут-сәгатьләрен санамый.

Җыелышкан чакта җырлашыйк,
Микула бәйрәменә җыелгач.
Микулага кызлар килгән,
Матур кием киенеп.
Бер-ике җыр җырлыйк әле,
Сез килгәнгә сөенеп.

Тройсын бәйрәме

Тройсын бәйрәме яз көне Пасхадан соң 50 көн узгач үткәрелә. Бу көнне чиркәүләрдә зур келәү була. Тройсын бәйрәмен халыкта «Җафрак бәйрәме» яки «Каен бәйрәме» дип тә йөртәләр, чөнки бу бәйрәм агачларның җафрак ярган, матурланган чагына туры килә. Ул борынгыдан калган җәйне каршылау бәйрәме булган.

Тройсын алдыннан авылдагы бөтен капка-коймалар яшел җафраклы каен ботаклары белән бизәлә. Урамнар, ишегаллары чүп-чардан чистартып себерелә. Халык күңеле урамга тартыла. Ә Тройсын көнне яшьләр авылга каен ботаклары алып кайталар, аны урам буенча күтәреп, җырлап йөриләр, һәр өй турында туктап җырлап-биеп алалар һәм ул каенның ботакларын арыш кырына иген уңсын дип илтеп ташлыйлар яки суга салалар. Каен ботагын суга салган чакта һәркем үз теләген әйткән, яки аның тиз генә батып китү-китмәвен карап, төрлечә юрый торган булган. «Җафрак бәйрәме» көненә кадәр җирдән үлән йолкырга, агач яфрагын һәм ботагын сындырырга, шулай ук су коенырга ярамый, дигәннәр. Керәшеннәр «җир иминлеге», «су иминлеге», дип, табигатьнең бөтенлеген, тынычлыгын бик нык саклаганнар. Бары тик Тройсын бәйрәменнән соң гына җирдән үлән, чәчәк өзгәннәр, табигать байлыгыннан файдаланганнар. Бу көнне чит авыллардан күпләп кунаклар килгән.

«Уйныйк әле, көлик әле,
Җырламый тормыйк әле!
Чәчәк кебек гомерләрне
Бушка уздырмыйк әле!
Урман буйларына бардык,
Урман буе каенлык, ай каенлык.
Тройсын бәйрәмнәре җитте,
Бәйрәм итик бергәләп, ай бергәләп», –

дип җырлаганнар.

Питрау бәйрәме

Төбәгебезнең иң күркәм бәйрәме – Питрау. Ул 12 июль көнне була. Питрау бәйрәмен һәркем үзенчә билгеләп үтә. Бу көнгә барлык чәчәкләр дә үсеп чәчәк атып бетәләр. Питрау көнне печәнгә, уракка төшәләр. Барлык кошлар да шул көннән соң сайраудан туктыйлар. Питрау атнасында кыр чәчәкләре, дару үләннәре җыеп киптерәләр.

Сынамышлар һәм әйтемнәр:

- Питрау үтә – җәй үтә.
- Питраудан соң кошлар да сайрамый.

- Питраудан соң сандугачның теле, үләннең тәме бетә.
- Питрауга чаклы үләннең шифасы чәчәктә, Питраудан соң тамырда.

Борынгыдан килгән Питрау бу,
Изгелек бар аның тамырында,
Петр, Павел апостолга бәйле,
Традицион безнең авылда.
Питрауда күңел ача авыл,
Әй киләләр инде кунаклар.
Гомер буе читтә йөргәннәр дә,
Питрау җитсә, кайта бу якка.
Үзәннәрдә билдән чәчкә үлән,
Җир дымлыга шулай үсәме?
Әүвәлгедән мактап сөйләнелгән,
Җырга кергән Питрау бәйрәме.

Элҗен

Элҗен – керәшеннәрдә иң зур һәм абруйлы бәйрәмнәрнең берсе. Ул ел саен 2 августта билгеләп үтелә. Халыкта Илья пәйгамбәр усал, кырыс, изге, дош-маннарын җәзага тартучы, шул ук вакытта юмарт, үзенекен мохтаҗ адәмнәргә бүлеп бирүче итеп күз алдына китерелә. Ул табигатьнең иң куркыныч һәм мәрхәмәтле көчләре белән идарә итә, яңгырлар, яшенле күк күкрәүләр аның карамагына керә. Ул Җиргә уңыш та җибәрә. Элҗендә табигатьнең барлык хәшәрәт көчләре, утлы камчыдан куркып, куян, төлке, мәче, эт, бүре һ.б.га әверелеп бетә, имеш. Бу көнне яшен камчысы сукмасын өчен, эт һәм мәчеләрне өйгә кертергә ярамый.

Элҗен көнне кырга барып, борчактан авыз итеп карарга ярый. Беренче тапкыр яңа бәрәңге пешереп ашыйлар. Элҗен җиттеме, авыл халкы күк йөзен куркынып күзәтә башлый, чөнки бу вакытта игеннәр өлгергән була. Аны бозлы көчле яңгырлар юк итәргә мөмкин. Илья пәйгамбәрнең күңелен күрү йөзеннән һәм ул бәла-казалар китермәсен өчен, бу көнне кырда эшләмиләр, печән чапмыйлар, чабылганын җыймыйлар, кырга мал-туар чыгармыйлар.

Сынамышлар:
- Элҗен җәйне тәмамлый.
- Элҗендә көн ике сәгатькә кыскара.
- Элҗендә сары яфраклар күбрәк күренә башлый.

Бәрәңгеләр инде эшкәртелгән,
Папайланган сары тузганак.
Көзләр кергән җиргә, кыр уңышы
Келәтләргә, ларга юл тоткан.
Сулар акты, Элҗен кире кайтты,
Әмма ерак әле үткәнгә.
Якынаер, авылым исән булсын,
Кирәк бердәм гомер итәргә. ■

Безнең мирас №7 июль 2022

Керәшеннәр каян килеп чыккан?

(Төрки христианлык турында)

Рифкать Әхмәтҗанов



Вятка губернасының Грахово авылы керәшеннәре. XX гасыр башы. ***Иван Зеленов фотосы***

Тарихи мәгълүматларга караганда, төркиләрнең бер өлеше IV-V гасырларда ук христианлыкка күчкән булган. Бу түбәндәгеләрдән нәтиҗәләнә. Беренчедән, Византия кайсәрләренең (императорларының) төрле һун-болгар кәбиләләренә – утургуларга, кутургуларга, Азов буе болгарларына һ.б.га миссионер җибәргәнлеге һәм хәтта Библияне болгар теленә тәрҗемә иткәнлеге Рум (Византия) чыганакларында әйтелә! Икенчедән, V-XII гасырларда хәзерге Казакъстан һәм Кыргызстан җирләрендә шактый күпсанлы христиан каберлекләре һәм алардагы төрки телдә язылган башбаталар сакланган. Бу соңгыларын шунда яшәгән несториан мәзһәбе җәмәгасе (общинасы) язып калдырган.

Несториан христианнар бүтәннәрдән гадирәк һәм мантыйклырак фәлсәфә белән аерылып торганнар. Мәсәлән, алар Алла-Мәрьям-Гайсә өчлеге бердәй «троица» дип тасаувыр итүне берничек аңлый алмаганнар. Кайбер гарәп чыганакларында IX-X гасырларда Идел буе болгарларының бер өлеше (бер кабиләсе) христиан булуы хәбәр ителә. Алар, мөгаен, несторианнар булганнардыр. Ул вакытта кайбер төрки кабиләләр, Болгар җирләрендә җәйләп, Көньяк Казакъстан (Җидесу) өлкәсендә кышлап, күчмәчелек белән көн иткәннәр.

Тел материаллары бу тарихи чыганакларның дөреслеген дәлилли. Төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, христианлыкка караган кайбер төшенчәләр һәм сүзләрнең әүвәлдән бирле яшәп килүе хак. Чукыну сүзе үзе, Олы көн (Олысның олы көне), Пасха, кулугур, монах һәм тәре сүзләре – шундыйлардан. Бу мәкаләдә сүз шулар турында барачак.

Чукыну сүзе барлык Идел-Урал телләрендә (керәшеннәрдән тыш тагын чуашларда, мариларда һәм удмуртларда) бар. Чыгышы вә таралышы буенча ул гомумтөрки сүз. Чокунмак фигыле борынгы төрки ядкярләрендә дә очрый. Аның чыганаклары барлык кыпчак төркиләрендә һәм Урта Азия халыкларында да бар.

Чукынуның төп мәгънәсе, үзенең маңгаена, иңнәренә һәм күкрәгенә төртеп, хач символын сурәтләүдер. Киңрәк мәгънәдә бу сүз христианлыкка күчүне белдерә.

Безнең карашка чукынмак, чокынмак алтай төркиләрендәге чогын-чокын («утка табыну, утка корбан китерү») сүзе белән бер. Ә бу нигез исә Алтай-Саян төркиләрендәге чок-чог, кыпчак халыкларындагы чок-чөк, татар һәм чуашлардагы чүк – «җәйге (кайбер урыннарда көзге) корбан чалу» (баштарак «утка корбан чалу») сүзе белән тамырдаш. Чүк сүзе һәм йоласы бигрәк тә керәшеннәрдә яхшы сакланган. Себер төркиләрендә Чүк бәйрәменең төп элементларының берсе учак ягып, шул учакка сөт сибү һәм төрле биюләр башкару булган.

Этимологлар чуаш һәм марилардагы чүк сүзен татар теленнән, татар мәҗүсилегеннән алынган, диләр. Ахыр чиктә ул борынгы төрки чог (хәзер монголча цог) «ут, утлы күмер» сүзенә кайтып кала.

Утның, утка табынуның чукынуга нинди мөнәсәбәте бар соң? Хикмәт шунда – борынгы төркиләр утка табынучы Иран халкы сәгъдиләр белән бик нык аралашып яшәгәннәр (хәтта төркиләр шул сәгъдиләрдән килеп чыккан дигән фикер дә бар). Утка табыну рәвеше дә чукынуга охшаш булган. Христиан динендә дә утка табыну элементлары бик көчле: икона янына шәм кую, чиркәү шәмнәре (лампадалар), Иерусалимның Изге ут алып кайту йоласы һ.б.

Пасханы бәйрәм итү дә борынгы төрки христианлыктан калган. Пасха христиан дөньясында, Олы көн мәгънәсендәге сүзләр белән аталган кебек, төркиләрдә дә (бигрәк тә кыпчакларда) Олы көн дип атала. Бу безнең Урта

Кәрәшен гүзәлләре. Вятка губернасының Грахово авылы. XX гасыр башы. *Иван Зеленов фотосы*

Кәрәшен татары сабый баласы белән. Алабуга районының Үмәк авылы. XX гасыр башы. *Иван Зеленов фотосы*

Идел төбәгендәге барлык телләрдә дә охшаш сүзләр белән белдерелә: чуашча – мын кун, марича – кугу кеге (күгүгече), удмуртча – бадҗым нунал. Болар барысы да «зур» (олы) дигән мәгънәгә ия. Тау ягы мишәрләре эндәшмисөйләшми торган кешеләрне клугур, кулугур дип атыйлар (хәер, хәзер бу сүз бик сирәк очрый инде). Мишәрләр Казан тирәсендәге татарларны эчкерле һәм дәшмәки дип саныйлар, аларны клугур, лугур (лыгыр), нугур дип атыйлар. Бәлки, бу сүздә төрлечә сүзләрнең кушылуы-буталуы бардыр. Тик шунысы хак: Кулугур сүзе аралашмаучан, кире кеше мәгънәсендә Алтай-Саян төркиләрендә еш очрый һәм Идел буе урысларында да кулланыла. Асылда бу сүз грекча Кулагер, Гулогер («христиан монахы») сүзенә кайтып кала. Мәгълүм ки, христианлыкны уйлап чыгаручылар булмаса да, аны көчәйтеп җибәрүчеләр – греклар. Несторианнарның дини терминологиясе дә грекча булган. Һәм әгәр Кулыер сүзе Үзәк Азиягә барып җиткән икән, бу хәл тик несториан христианнар арадашчылыгы нәтиҗәсендә генә була ала.

Инде тәре сүзенә килик. Татар телендә (һәм бу телдә генә) әлеге сүз хачны да, иконаны да белдерә. Тәре баганасы дип руслар юл чатларындагы икона беркетелгән баганаларны атыйлар. Ләкин асылда бу сүз Алланың синонимы булган Тәңре бит! Мишәр диалектының каратай сөйләшендәге Тәйри һәм карачайбалкар телендәге Тәйри-Тәңре. Күк (күкрәү) Алласы гомумтөрки Тәңре сүзеннән килеп чыкканлыгы күренеп тора. Тәңре Күк һәм яшен Алласы барча төркиләргә дә, монголларга, тунгус – маньчжурларга һәм башка Себер халыкларына яхшы таныш бердәнбер Алла. Мәгълүм ки, католик руханилары XI гасырдан башлап көнбатыш төркиләр, бигрәк тә кыпчак-куманнар арасында миссионерлык эшен җәелдергәннәр. Һәм, күрәсең, христиан Алласы идеясен халыкка җиткерү өчен Алланы Тәңрегә тиңләгәннәр. Христиан миссионерлар, гарәпләрдән үзгә буларак, мәҗүсиләрнең телен-фольклорын тырышып өйрәнгәннәр һәм үз максатларында файдалана белгәннәр. Борынгы куман теле һәм авыз иҗаты турында ачык мәгълүмат бирә торган атаклы «Куман мәҗмугасы» («Кодекс куманикус») каталик миссионерларының хезмәте нәтиҗәсендә пәйда булган бит! Ул миссионерлык Алтын Урда чорында да дәвам иткән. Һәм, һичшиксез, күп кенә кыпчаклар христиан диненә күчкәннәр дип уйларга нигез бар.

Болгар һәм Казан дәүләтләре чорында Урта Иделдә төрле-төрле христианнар, мәсәлән, әрмәннәр яшәп килгән. Татар телендәге хәчтерүш сүзе, чуашларда качикруш батыр атамасы, әрмәнчә хачикруш «христиан», «тәре такмыш» сүзенә кайтып калса кирәк. (Хач сүзе үзе дә бездә әрмән теле ядкяре.)

Хәзерге көндә дини хәрәкәтләр шактый колач алды. Ләкин, Алла сакласын, ислам хәрәкәте дә, керәшенчелек тә большевистик түзгесезлек (түзеп тора алмау), тәгассып характерын алмасын иде. Мин кечкенә чакта безнең яклардагы (Уфа тирәсендәге) урыслар да, татарлар да үзара сөйләшкәндә «динебез башка булса да, Аллабыз бер» ди торганнар иде. Ягъни бер үк Аллага гыйбадәт кылабыз, безне ул гына хөкем итсен дигән сүз инде. Без дә шуны кабатлыйк. ■

Күренекле галим һәм педагог

Гөлнара Шакирова, педагогика фәннәре кандидаты, КФУ доценты

Һөнәр язмышка тиң нәрсә. Күңелеңне сихерләп, бөтен барлыгыңны биләп, гомереңне яулап алырлык һөнәр булганда гына, кеше бәхетле. Андый кешене бәхет үзе эзләп таба.

Мәхмүт Хәсәнов

Фираз Фахраз улы Харисов

Бөтен гомерен халыкка фидакярләрчә хезмәт итүгә багышлаган, милләт мәнфәгатен үзенең яшәү кыйбласы иткән татар галимнәре һәм әдипләре арасында Казан фәнни-лингвистика мәктәбе мирасын дәвам итүче, педагогика фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясе югары мәктәбенең мактаулы хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе һәм атказанган укытучысы, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты Фираз Фахраз улы Харисов үзенчәлекле урын алып тора.

Фираз Фахраз улы 1952 елның 24 маенда Башкортстанның Яңавыл районындагы Истәк авылында Фахраз абый белән Газимә апа гаиләсендә дөньяга килгән. 1969 елда ул Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреатлары Нурихан Фәттах һәм Илдар Юзеев укыган Яңавыл шәһәренең 1 нче урта мәктәбен тәмамлый һәм Истәк авылы мәктәбендә – татар теле һәм әдәбияты белән рәсем, кечкенә мәктәптә сызым дәресләрен укыта. 1971-1973 нче елларда Совет Армиясендә хезмәт итә. Фираз

Харисов, демобилизацияләнгәннән соң, Казан дәүләт педагогика институтын тәмамлый, аспирантура һәм докторантурада укый, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен уңышлы яклый.

Фираз Фахраз улы югары белем бирү өлкәсендә инде 35 елдан артык хезмәт итә. Ул 1978 елдан Казан дәүләт педагогика институтында эшли, рус мәктәпләрендә татар телен укыту кафедрасын оештыра, егерме елга якын проректор вазыйфаларын башкара. 2011 елдан Фираз Фахраз улы – Казан (Идел буе) федераль университетының Татаристика, төрки тел белеме һәм этномәдәни белем фәнни-мәгариф үзәге җитәкчесе урынбасары һәм хәзерге татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы профессоры, 2012 елдан хәзерге татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы мөдире булып эшли, бүгенге көндә – татар тел белеме кафедрасы профессоры.

Галим – фәнни-популяр, фәнни-методик хезмәтләр авторы да. Аның лингвометодика өлкәсендәге эзләнүләре күпсанлы китапларында, монографияләрендә, югары уку йортлары һәм гомуми белем бирү оешмалары өчен төзелгән программаларда, дәреслекләрдә, укыту-методик әсбапларда, дистәгә якын төрле юнәлештәге сүзлекләрдә, электрон дәреслекләр һәм кулланмаларда, мультимедиа чараларында, мәкаләләрендә урын таба. Күп кенә хезмәтләре чит илләрдә дә дөнья күрә.

Лингвометодист югары уку йортларында һәм мәктәпләрдә татар телен укытуның теориясе һәм практикасы, хәзерге полилингваль белем бирү шартларында татар телен чит тел буларак укытуга караган актуаль проблемалар белән бик актив шөгыльләнә. Аның иҗади һәм методик эшчәнлек нәтиҗәләре югары уку йортларында, гомум һәм махсус урта белем бирү оешмаларында киң кулланыла.

Мондый киңкырлы эшчәнлекнең башы узган гасырның 90 нчы елларына барып тоташа. Ф.Ф.Харисов ул чорда ук татар телен башка милләт вәкилләренә өйрәтүгә багышланган төрле дәреслекләр, кулланмалар язу эшенә алына. Бу проблемага багышланган китапларның иң беренчесе – профессор Чулпан Мөхәррәм кызы Харисова белән бергә язылган «Учимся говорить по-татарски» (1992) китабы ата-аналар, укытучылар һәм тәрбиячеләр арасында зур популярлык казанды.

Татарча сөйләшергә өйрәнүчеләр өчен төзелгән татар лексикографиясе тарихында беренче рәсемле-тематик сүзлекләр дә Чулпан Мөхәррәм кызы белән автордашлыкта язылып, «Минем беренче татарча сүзлегем» («Мәгариф»,1995) Россия мәгариф министрлыгы тарафыннан телне өйрәнү өчен кулланма буларак тәкъдим ителә. Ул 1996 елда ЮНЕСКО тарафыннан уздырылган Бөтенроссия балалар китабы конкурсында (рәисе – шагыйрь Сергей Михалков) махсус дипломга лаек була. Шул чорда татар яшьләренең «Сәләт» иҗат лабораториясе белән берлектә (танылган галим һәм шагыйрь Җәүдәт Сөләйман) мультимедиа системасында 4 төрле компакт-диск эшләнә, «Сүзләр һәм җөмләләр дөньясында» («Мәгариф», 2005) исемле татарча-русча рәсемле-ситуатив сүзлек тә басылып чыга. Аннан соң башлап өйрәнүче студентлар һәм яшьләр өчен берничә сүзлек дөнья күрә.

Фираз Фахраз улы Харисов 2000 елда ана телен укыту методикасы тарихында милли телләрне укыту юнәлешендә «Лингвистические и психолого-педагогические основы начального обучения татарскому языку в школах с русским языком обучения» дигән темага докторлык диссертациясен яклап, татар телен

укыту методикасы өлкәсендә беренче булып фәннәр докторы дәрәҗәсен ала, милли телләргә өйрәтүнең фәнни нигезләрен булдыра.

Галим үзенең хезмәтләрендә икетеллелек һәм күптеллелек проблемаларына, икетеллелек проблемасының лингвистик аспектына басым ясый, психологик-педагогик, иҗтимагый һәм лингвистик якны истә тотып өйрәнә. Ул рус һәм татар телләрен үзара бәйләп укыту шушы телләрне үзләштерүне җайга салырга мөмкинлек бирә, лингвистика, психология, педагогика өлкәсенә караган казанышларны укыту практикасына кертергә ярдәм итә, транспозицияне исәпкә алып, интерференциянең тискәре йогынтысын кисәтергә һәм материалны үзләштерүдә килеп туарга мөмкин булган кыенлыкларны алдан күрергә ярдәм итә дип саный. Фираз Фахраз улы «Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре» («Мәгариф», 2002, 2015), «Татар теленең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге: лингводидактик аспект» (2017), «Татар теле: укыту теориясе һәм практикасы» (Татар.кит.нәшр., 2018) дигән монографияләрендә татар телен чит тел буларак укытуның лингвометодик нигезләрен бәян итә. Галим башка милләт вәкилләрен татар теленә аралашу принцибына таянып өйрәтергә кирәклеген ассызыклый. Ул «Сөйләм материалын ситуатив тәкъдим итү, материалны ныклап үзләштерү максатыннан күп тапкыр кабатлау, актив аралашуга кагылышлы күнегүләрне киң файдалану»ны әлеге принципны тормышка ашыруның төп шартлары дип билгели. Лингвометодист «Татар телен чит тел буларак өйрәтү. Заманча технологияләр» (2012), «Татар теле: яңача укыту юнәлешләре» (2015) дип аталган кулланмаларында телгә өйрәтүне яңача оештыру, укучыларның тел белән кызыксынуын көчәйтү һәм укытуның сыйфатына уңай йогынты ясау максатында кулланырга мөмкин булган заманча укыту юнәлешләренә, технологияләренә аңлатма бирә.

Фираз Фахраз улы беренче тапкыр рус телендә белем бирүче гомуми белем бирү оешмаларында татар телен укыта башлауның тулы бер концепциясен эшли һәм телгә өйрәтү теориясендә һәм методикасында яңа юнәлешкә нигез сала. Шуңа күрә галим иҗат иткән фәнни-методик тикшеренүләрнең теоретик һәм гамәли әһәмияте Татарстаннан да читкә чыга, чөнки шушы үрнәк буенча илнең башка субъектларында да рус телле укучыларны милли телләргә өйрәтү буенча фәнни-методик эшчәнлек уңышлы итеп оештырыла һәм төрле дәрәҗәдәге диссертацияләр яклана.

Фираз Харисовның күпсанлы китаплары «Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителә» дигән гриф белән басылып чыга. Тел күренешләренә системалы якын килеп, тел белеме өлкәсендәге яңалыкларны исәпкә алып иҗат ителгән программалар, дәреслекләр һәм кулланмаларны республикадагы балалар гына түгел, Россиядә һәм чит илләрдә яшәүче өлкәннәр дә файдалана («Программа по татарскому языку для учащихся-татар, проживающих в регионах Российской Федерации. 1-4 кл». – Казань: Школа, 2007. – Сост. – Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова).

Соңгы елларда аның фәнни-методик кызыксыну-эзләнү даирәсе тагын да киңәйде. Аерым алганда, галим, француз теле белгечләре белән автордашлыкта (В.Н.Васильева, Л.Р.Низамиева), 5-11 нче сыйныфлар өчен француз теле дәреслекләрен төзеп бастыра. Алар француз теленә татар һәм рус телләре аша өйрәтүне максат итеп куйган оригиналь дәреслекләр буларак танылa.

Галимнең унбишләп мәкаләсе SKOPUS һәм Web of Science кебек абруйлы халыкара мәгълүмат базаларына кертелгән журналларда дөнья күрә, шу-

Фираз Харисов хатыны Чулпан ханым белән. ***Юлия Калинкина фотосы***

лар һәм башка чит ил җыентыкларында басылып чыккан хезмәтләре аша фән дөньясында киң танылa.

Фираз Фахраз улы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән күп еллар дәвамында тыгыз хезмәттәшлек итә: 30 елдан артык татар теленнән республика һәм берничә ел Халыкара олимпиадаларның жюри рәисе,

«Ел укытучысы» һәм башка төрле конкурсларда жюри әгъзасы була, татар теле һәм әдәбияты укытучыларының белемен камилләштерү курсларында даими рәвештә лекцияләр укый.

Әйтергә кирәк, Фираз Фахраз улы – гаиләдә дә бәхетле шәхес. Галимнең гаиләсе – аның ныклы терәге, илһамчысы. Тормыш иптәше – Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның атказанган укытучысы, Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты, педагогика фәннәре докторы, профессор Чулпан Мөхәррәм кызы Харисова – күп еллар дәвамында югары уку йортларында һәм мәктәпләрдә татар телен укытуның теориясе һәм практикасы, хәзерге татар әдәби теленең сүз ясалышы һәм морфологиясенә караган актуаль проблемалар белән бик актив шөгыльләнүче галимә, шушы өлкәләргә караган 400дән артык хезмәт авторы. Аларның йөздән артыгы – монография, программа, сүзлек, мультимедиа чаралары, дәреслек һәм кулланмалар. Аның хезмәтләреннән республикабыздагы төрле уку йортларында укучы һәм эшләүчеләр генә түгел, илебезнең башка төбәкләрендә яшәүче һәм эшләүчеләр дә уңышлы файдалана.

Уллары Илшат 2006 елда Казан дәүләт университетының икътисад һәм филология факультетларын кызыл дипломга тәмамлый. Студент елларында ук яшь икътисадчылар, сәясәтчеләр, социологлар өчен Мәскәү һәм Санкт-Петербург дәүләт университетлары оештырган Җәйге мәктәпләрдә Россия һәм БДБ илләреннән килгән аспирантлар һәм яшь галимнәр арасындагы бәйгеләрдә дүрт тапкыр җиңүче була. Ул, Михаил Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының аспирантурасын тәмамлап, 2010 елда икътисад фәннәре кандидаты гыйльми дәрәҗәсен ала. Хәзер Америка Кушма Штатларында эшли, хатыны Венера белән Мәрьям, Әмир һәм Кәримне үстерә.

Кызлары Гөлшат ТДГПУның психология факультетында укыды, шул елларда университет ректоры, Татарстан Фәннәр Академиясе, Россия Федерациясе хөкүмәте стипендиаты һәм шулай ук Россия Президентының сәләтле яшьләргә ярдәм итү премиясе лауреаты булды. Гөлшат Фираз кызы хәзер – психология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының педагогика һәм психология институты доценты, күпсанлы фәнни хезмәтләр авторы. Бүгенге көндә ул – КФУда «Инновацияле белем бирү һәм сәләтле балаларны үстерү» дигән магистр программасының җитәкчесе, Европаның (EFPA) сертификацияләнгән психологы, Россия психология оешмасы әгъзасы, Россия Дәүләт Думасындагы мәгариф һәм фән комитетының эксперт советы әгъзасы, Россия Мәгариф академиясенең гомуми урта белем бирү бүлегендәге Фәнни совет әгъзасы. Гөлшат тормыш иптәше белән кызлары Гайшә һәм уллары Йосыфны үстерә.

Фираз Фахраз улы Харисов – күренекле галим, фән эшлеклесе, күпләгән укытучылар һәм яшь галимнәрнең остазы, киңәшчесе, студентлар өчен таләпчән һәм киң күңелле мөгаллим – бай педагогик һәм методик тәҗрибәгә, зур фәнни мөмкинлекләргә ия булып, хезмәттәшләренә даими ярдәм күрсәтә, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе мәктәпләре һәм мәгариф органнары белән тыгыз элемтәдә эшли, югары һәм урта мәктәп проблемалары, татар телен укыту методикасының актуаль мәсьәләләренә караган докладлар һәм лекцияләр белән даими рәвештә чыгышлар ясый. Гомумән, галим һәм педагог киңкырлы фәнни-педагогик һәм методик эшчәнлек алып бара, аның нәтиҗәләре дә бай һәм куанычлы. ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, әдипләр, журналистлар һәм сәнгать әһелләре июль аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә.

1 июль – рәссам-график **Гөлзирә Солтан кызы Бекташева**га 75 яшь (1947);

10 июль – Санкт-Петербургта яшәүче шагыйрә **Халидә Нуриман кызы Ганиева-Гыйләҗева**га 70 яшь (1952);



16 июль – баянчы, композитор, җырчы, Татарстанның халык артисты, Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районындагы Кучкай Пожары авылы тумасы **Рамил Сөләйман улы Курамшин**га 75 яшь (1947);

17 июль – шагыйрь, прозаик һәм драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Ф.Хөсни, Д.Сираҗиев (2012) һәм Т.Миңнуллин (2017) исемендәге премияләр лауреаты **Рәдиф Сәгъди**гә (Рәдиф Нәҗип улы Сәгъдиевкә) 65 яшь (1957);

20 июль – балалар язучысы, А.Алиш исемендәге әдәби бүләк иясе **Алмаз Марс улы Гыймадиев**ка 50 яшь (1972);

28 июль – педагог, педагогия фәннәре докторы, профессор, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган мәктәп укытучысы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе **Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтов**ка 70 яшь (1952).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов



Шанхай. XX гасыр башы

Шанхай

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Бу шәһәр Кытайның иң зур сәүдә порты булуы белән бергә, дөньяның да иң зур портларының берсе булып санала.

Шанхай – Кытай иленең иң төзек шәһәре, Аурупаның атаклы шәһәрләренә бик охшаган. Мин биредә башта Лухало мәхәлләсендәге мәчеткә килдем. Бу мәчет, кечкенә генә булса да, бик төзек, матур иде. Мәчетнең эче электр белән яктыртыла, бизәлеше дә солтан мәчетләрен хәтерләтә. Мәчет янында, юлаучы мөселманнар өчен, иң затлы кунакханәләр кадәр бизәлгән биш бүлмә бар. Болар да электр белән яктыртыла.

Мине шул бүлмәләрнең берсенә урнаштырдылар. Мәчетнең имамы бик мөлаем кеше иде, миңа зур хөрмәт күрсәтте. Гарәп телендә сөйләшүе дә шактый аңлаешлы иде. Бу ачык фикерле мөхтәрәм шәхес белән бераз сөйләшеп утырдык. Беренче көнне арабыздагы сөйләшү болай булды:

– Лухало мәчетенең тышкы ягында, ягъни өстендә башка мәчетләрдәге кебек җанвар сурәтләре юк, моның сәбәбе нәрсәдә?

– Әйе, – диде, – элекке бинада, нәкъ башка мәчетләрдәге кебек, җанвар сурәтләре

бар иде. Моннан ун еллап элек, бинаны яңартканда, мин ул сурәтләрне бетертер өчен бик тырыштым һәм бу теләгемә ирештем дә. Шуның өчен мине бөтен голамәбез бик нык гаепләде, тик мин бирешергә теләмәдем. Зур низаглар чыкты. Мәчетне яңарту эшләре тәмам булганнан соң, әле өч айлап, сакчы куеп саклаттым. Дәгъвамда нык тордым, һәм, ниһаять, Аллаһка хәмд булсын, барлык Кытай голамәсеннән өстен чыктым. Бөтен Кытай илендә шәригать кушканча салынган бердәнбер мәчет бар, ул да булса – безнең мәчетебез.

– Бу якларда, голамә арасында, чәчсез кеше дә Сездән башка берәү дә юктыр дип уйлыйм. Шулаймы?

– Бар, ләкин аз. Нанкин голамәсенең күбесе чәчен кистерде. Тик андыйларның саны чагыштырмача бик аз. Безнең бу яклардагы голамә тиздән чәчләрен кистерәчәк, әмма...

– Сезнең йөз чалымнарыгызны да кытайларга бик охшата алмыйм.

– Мин – кытай кешесе, ләкин ата-бабаларым чыгышлары буенча Йонанси дигән җирдән. Шуңадыр, безнекеләрдә төрки чалымнар сакланган. Тамырыбызның төрки булуы мөмкин, ләкин бөтен яктан кытайлашкан төркиләрдән булуыбыз да шөбһәсез. Кытайда, гомумән, ул төркиләрнең барысы да диярлек, бигрәк тә көньяк-көнчыгыш төркиләре, тулысынча кытайлашкан, төркиләрнең исеме дә калмаган. Сез килгән юл өстендә, Ханькоудан бирегә кадәр, саф төрки кавемнән килгән авыллар һәм шәһәрләр бар, ләкин төркилеккә дәлил булырлык берни дә юк. Үзегез дә күргәнсездер һәм фикерегез бардыр дип уйлыйм. Төрки эзләр сакланганмы, ниләр бар?

– Әйе, мин күрмәдем, ләкин кайбер җир атамаларының төрки телдә икәнен аңладым, кайбер елга исемнәре дә төркичә кебек тоелды.

– Кайбер генә түгел, бик күп. Борынгырак чорда, моннан 3-4 гасырлар элек, гомумән, бу җирләрдә төрки телдә сөйләшүчеләр бик күп булган. Бүгенге көндә кытай теле бик күп сөйләшләргә аерылган. Кайбер тел белгечләре, 24 сөйләш булуын әйткәннән соң: «Телдәге мондый аермалар төрки тел катышу белән бәйле», – диләр. Бу җирләрдә кытай теле үзәктә кулланыла торган тел белән чагыштырмаслык дәрәҗәдә нык үзгәргән. Көньякка киткән саен, тагын да ныграк үзгәрә барган. Мин Сезгә менә шундый мисал китерәм: Харбин һәм аның әйләнә-тирәсендә кулланыла торган тел Мукденга кадәр шул ук. Аннары Шанхай, Куан, Тензин һәм Кансуда тел үзгәрә, тик халык бер-берсен җиңел аңлый. Пекин тарафына, тагын да көньяккарак китсәгез, монда Харбин, Маньчжуриядә кулланылган тел бераз авырлык белән аңлашыла. Ханькоу, Нанкин халкы һәм без Харбин сөйләшен теләгәнебезне әйтерлек тә аңлый алмыйбыз. Тик Пекин сөйләшен тулысынча дип әйтерлек дәрәҗәдә аңлый алабыз. Моннан Кантон, Ханькоу якларына китсәк, алар билгеле бер дәрәҗәдә безнең белән сөйләшеп аңлаша алалар, ләкин Пекин сөйләшен белмиләр. Тагын да югарырак, Сычуань, Йоунань (Юньнань), Тонкин яклары халкы безнең сөйләшебезне бөтенләй аңламый. Пекинда, Харбинда кулланыла торган тел бу сөйләшләргә караганда бөтенләй башка. Кыскасы, Көньякның телен Төньяк белми, үзәктәгеләр ике якны да бераз аңлый, барысы – 24 тел. Мин үзем барысын да аңлыйм, чөнки нигезләре уртак.

Шанхай – гаять зур һәм бик мәшһүр шәһәр. Биредә дөньяның төрле-төрле җирләреннән килгән кешеләр очрый. Гарәпләр бар, һиндлар бар, иранлылар бик күп, инглизләр күпчелекне тәшкил итә, французлар бар, американнар бар, алманнар (немецлар) бар, японнар аерым мәхәлләләр булып яши. Бары тик госманлы төрекләрен генә очратмадым.

Шәһәрнең төзеклеге турында әйтсәк, Аурупа шәһәрләреннән бер ягы белән дә аерылмый. Электр белән йөртелә торган трамвайларның күплеге, автомобильләрнең күплеге, тагын әллә ниләр, телефоннар – үрмәкүч пәрәвезен хәтерләтә.

Шөбһәсез, бу – Кытай иле, ләкин Шанхай – бәйнәлмиләл шәһәр һәм хакимият тулысынча инглиз идарәчеләр кулында. Күренештә нәкъ инглизләр шәһәре. Полиция идарәсе һәм хезмәткәрләр – бар да инглиз кешеләре. Полиция кешеләре арасында, ара-тирә озын чәчле кытайлар да очрый, ләкин болар шәһәр мәркәзеннән читтәге мәхәлләләрдә генә күренә. Шәһәр үзәгендәге полиция хезмәткәрләре күбесенчә һинд кешеләре, җитәкчеләре – инглизләр. Кайсы гына урамга барып чыксаң да, мотлак, зур чалмалы, мәҗүси һинд кешеләренең зәбаный[1] кебек утлы ядрә яудырганын күрәсең. Боларның кытайларга күрсәткән золымнарыннан чәчләрең үрә торырлык. Шанхай, Тензин (Тяньцзинь), Ханкан (Гонконг) шәһәрләренең идарәсен күз алдында тотсаң, инглизләр Кытайны тәмам басып алганнар, үз идарәләрен урнаштырганнар дип уйларга мөмкин.

Шанхайда чит ил кешеләре

Чит ил кешеләре монда бик иркенләп сәүдә итәләр. Инглизләр башка милләтләрдән дә алдарак тора, бөтен сәүдәне үз кулларына алып бетергәннәр. Бик аз гына булса да, безнең Сүрия кешеләре дә бар. Бәйруттан килгән Салих Табба исемле бер яшь кеше бар, сәүдәгәрләр арасында моның дәрәҗәсе бик зур. Иранлылардан берничә зур сәүдәгәр бар. Һинд кешеләреннән дә бар, тик боларның күбесе шигый, әһеле-сөннәттән бары тик Әмин Бахш исемле бер хөрмәтле шәхесне генә очраттым. Әмин Бахш – бик яхшы мөселман кешесе, миңа олы ихтирам күрсәтте, хәтта Токиода төзелергә тиешле мәчет эшенә зур күләмдә ярдәм күрсәтергә дә вәгъдә бирде.

Иса, Баһаи кардәшләр дә бик хөрмәт күрсәттеләр. Бу җирләрдә безнең мөселманнардан мондый бөек, могтабәр сәүдәгәрләрнең булуы бик мөһим, шөкер итәрлек һәм горурланырлык хәл. Ләкин, кызганыч ки, болар бик аз. Тагын да күбрәк булсыннар иде, безнең Кытайдагы мәнфәгатебезгә яхшы хезмәт итәрләр иде.

Шанхайда җирле мөселман кешеләре

Шанхайда җирле мөселманнар бик аз: нибары өч мәхәллә һәм өч мәчет бар. Җирле мөселманнар арасында да зур, могтабәр сәүдәгәрләр очрый. Боларның үз газеталары да бар икән, тик газета алучыларның күбесе мәҗүсиләр, ди.

Газетаның хуҗасы Шәмси – Җин-җан-лу – искиткеч яхшы кеше, гарәпчәне белүе дә шактый яхшы, инглиз һәм япон телләрен дә белә. Бу шәхес белән берничә тапкыр күрешеп сөйләштем, инглиз сәясәтен күзәтеп бара икән.

Шанхайның әйләнә-тирәсендә мөселман авыллары бик күп икәнен белдем. Кызганыч ки, мин бик күп йөри алмадым, чөнки, бер яктан, мөбарәк кесә мөмкинлек бирми иде, икенче яктан, бик арган-таушалган хәлдә идем. Шулар сәбәпле, бик аз йөри, бу җирләрне бик аз күрә алдым.

[1] Зәбаный – җәһәннәмгә эләккәннәрне җәзалаучы җәһәннәм фәрештәсе *(тәрҗ.иск.)*.

Ахун җәнаплары белән кабат күрешү

Ахун Ван-тийан-фу җәнаплары кытай голамәсе арасында шактый киң фикерле кеше булуы белән аерылып тора, һәр җәһәтне әтрафлы итеп уйлый алырлык көчкә дә ия иде. Мин, бу шәхес белән бераз танышып сөйләшкәч, кытай мөселманнарының киләчәге турында фикерләрен сораган идем. Ул миңа шул рәвешле җавап бирде:

– Кытай мөселманнарының киләчәге, гомумән, кытай халкының киләчәге белән бәйле. Кытайлар үз хакимиятләрен, идарәләрен саклап кала алсалар, безнең мөселманнар да мөселманлыкларын саклап кала алырлар. Кытай хөкүмәте әлегә җаһил. Халык үзен кулга алып, ил күләмендә, дин мәсьәләсенә җитди итеп карар хәлгә килгәндә, мөселманнар да күзләрен ачарлар, дини хокукларын сакларлык көчкә ия булырлар дип уйлыйм. Бәлки, әле шундый вакытлар да җитәр: кытайлар мөселман булырлар, әмма мөселманнар диннәрен югалтмаслар. Тик шунысы да бар: инглизләр бу мәмләкәтне үз кулларына ала калсалар, әлеге хәл безнең бичара мөселманнар өчен үлем белән бер булачак. Ник дигәндә, инглизләрнең бөтен сәяси гамәлләре – исламиятне төбе-тамыры белән йолкып ату.

Гонконг. XX гасыр башы

Бүгенге көндә дә, бернинди хаклары булмаса да, безнең мәчет һәм мәдрәсәләребезнең эшләренә тыкшыналар. Минем мәдрәсәмә дә кулларын сузып маташтылар. Әле күптән түгел генә ике-өч мөселман һинд полиция кешесен җибәргәннәр, миңа: «Бу кешеләргә ике бүлмә бирегез, вакытлыча шунда яшәячәкләр», – дип язып, кәгазь җибәргәннәр.

Боларның максатлары билгеле: башта «вакытлыча» дигән булып урнаштырачаклар, берзаман, күр дә тор, безнең мәдрәсә бүлмәсен полиция идарәсенә әйләндереп тә куячаклар.

Мин бераз алдан күрүчәнлек белән эш иттем, кабул иттем ул кешеләрне. Аннары безгә янаулар килде, без дәшмәүне хәерлерәк булыр дидек. Әгәр бәхәскә кергән булсак, шунда ук басып керәчәкләр иде. Аллаһыга хәмд булсын, бу хәл безнең өчен хәере белән тәмамланды.

Әгәр инглизләр мәмләкәтне чын-чынлап үз хакимиятләренә буйсындырсалар, улвакыт безнең дини эшләребезгә турыдан-туры тыкшынырлар, тыкшыначакларына һич шөбһә юк.

Бер яктан, азу ярган бүре кебек, миссионерлары һөҗүм итәчәк, икенче яктан, хөкүмәтләре икътисади, сәяси басым ясый башлаячак. Бу хәлләрнең ахыры безнең өчен бик куркыныч булырга мөмкин, чөнки милләтебез җаһил. Нәрсә әйтсәләр,

шуны акрын-акрын кабул итәләр. Шулай була калса, кытай мөселманнарының берничә ел эчендә юкка чыгуы бик мөмкин.

Мин шунда, сүзгә катнашып, болай дидем:

– Инглизләрнең басып алу ихтималы бармы? Аурупалылар шулкадәр халыкны инглизләргә генә йотарга ирек бирерләрме, риза булырлармы? Бу мәсьәлә бик мөһим. Инглизләр бу мәмләкәтне йота алырлар дип уйламыйм. Дөресрәге, йотарга ирек булмас.

– Әйе, мондый фикер өстенлек итә. Тик шул ук вакытта, бүгенге көндә инглизләрнең биредәге сәясәте ничек кенә булса да буйсындыруга, мәмләкәтне коралсыз-нисез яулап алуга корылган. Әгәр читтән берәр каршылык килеп чыкмаса, ун ел эчендә инглизләр, һичшиксез, бу илне эчтән яулап алачаклар. Моңа кагылышлы бик күп дәлилем бар. Тик әлегә күп сөйләшергә ярамый. Мин биредәге полиция хезмәткәрләре белән бераз таныш, шактый мәгълүматым бар, күзаллый алам.

– Кытай дәүләт кешеләре арасында да болай уйлый торган, аз булса да фикерләү ирегенә ия кешеләр бармы? Сезнең кебек фикер йөртә алалармы? Бу хәлләрдән чыгу чарасын эзләүчеләр бармы?

– Әлбәттә, бар, ләкин аз булуы мөмкин.

Күрәсезме: кытай имамы нинди уй-фикергә ия! Мондый имамнар Кытай мәмләкәтендә бик сирәк очрый.

Мин бу шәхес белән әле тагын күп тапкырлар күрешеп сөйләштем. Мәмләкәтнең инде яртысы кулдан ычкынган, инглизләр аны сугышсыз яулап алганнар – аның фикере менә шундый.

Шанхайдан китү

Шанхайда имам җәнапларының игелеге белән юл акчасы табуга ук, һич вакыт үткәрмичә, пароход белән Ханкан шәһәренә юл тоттым. Бу ике мәмләкәт арасында пароход еш йөрми, ләкин кечерәк кораблар даими диярлек йөреп тора икән. Мин кечкенә генә корабка: «Тәвәккәлтү алӘллаһ [Аллаһка тәвәккәл иттем]», – дип, менеп утырдым. Һава, ничектер, бик яхшы булырга охшамаган иде. Имам җәнаплары да мине озатырга килгән иде, ул да корабка менде. Миңа бер дару сузды: «Әгәр диңгез чире тотса, хәлегез начарайса, бер төймә кабыгыз. ИншәАллаһ, җиңел кичерерсез», – диде.

Бер сәгать буе диңгезгә таба кердек. Аннары бик куркыныч давыл башланды. Мин болай да диңгездә үземне начар хис итәм. Бу юлы имам кардәшем биргән дару төймәсенең файдасы тиде, диңгез чире тотмады. Корабтагы юлчылар бар да озын чәчле кытайлар, тел дә белмим, берәү белән дә таныша да алмыйм. Үземнең каютамда язу язып вакыт үткәрәм. Юл әллә ни озын түгел. Әлхәмдүлилләһ, диңгез чиренә тотылмаячагыма да ышандым.

Кораб шактый чайкала, юлчыларның күбесе тәгәрәп ята. Мин дә, бераз һава алыйм, дип, кичкә кырын югарыга күтәрелдем. Йөренәм, шулвакыт яныма бер кытай кешесе килеп нәрсәләрдер әйтте, аңлый алмадым. Минем дә өстемдә кытай киеме, тик тел белмим. Бераз уйланып торды да инглизчә нидер әйтте. Бары тик all right дигәнен генә аңладым. Аннары французча да әйтәсе итте, әйтә алмады. Ниһаять, японча: «Сез кайсы як кешесе?» – дип сорады да, мин: «Русия кешесе мин, татар», – дидем. Минем Русия кешесе дигәнемне ишетүгә, шунда ук минем белән русча сөйләшә башлады: «Диңгез төнлә бик куркыныч була. Хәзер үк кереп ятсагыз, азрак таушалырсыз», – диде.

Чынлап та, төнлә бик куркыныч давыл булды. Бар да һушсыз ята иде. Аллаһка хәмд булсын, миңа әллә ни тәэсире булмады.

Мин һәрвакыт төшләремә игътибар итәм. Ул төнне генерал Вәлихан җәнапларын күрдем. Өстендә яңа кием, башында кызыл чалма, миңа кул болгый иде. Бу – шәгъбан аеның 22се, җомга төне иде.

Ханкан

Ханканга килгәч, туп-туры мәчеткә киттем. Мәчет ишегалдында шактый кеше җыелган иде. Шау-шудан ниндидер гауга, низаг барлыгын аңлап алдым. Юл йөгемне шунда койма өстенә куйдым да: «Сәламүн аләйкүм», – дидем. Ләкин бар да бик киеренке иде, берәү дә: «Вә аләйкүм сәлам», – дип җавап бирмәде.

Мәчет эченнән тагын бер тавыш ишетелә иде. Акрын гына ишеккә таба киттем. Мәчет эче кеше белән шыгрым тулган, бер кеше мөнбәрдә утыра, җәмәгатькә нидер сөйли.

Мәчетнең тышында да, эчендә дә гел һинд кешеләре. Кытайлардан ник бер кеше күренсен. Хатыйб[2] әфәнде дә һинд телендә сөйли.

Мәчет эчендә буш урын таба алмаганга, ишек төбендә басып тыңлый башладым. Телләрен аңламасам да, ара-тирә фарсыча, гарәпчә, төркичә сүзләр ишетелгәнгә, хөтбәнең мәзһәбкә кагылышлы икәнен бераз аңлый алдым.

Ул арада халык арасыннан бер кеше күтәрелде: «*Вә мән йактул мө'минән мүте'аммидән фә-җәзауһу җәһәннәму халидән фиһа әбәдән* [Кем бер мөэминне үтерәм дип үтерсә, аның җәзасы – мәңгегә җәһәннәмлек булу] (Ниса: 93)», – диде. Аннан соң урду телендә сөйли башлады. Бу да ярты сәгать дәвам итте. Бу чыгышларда шигыйлек-сөннилек бәхәсе булуы ихтималын уйласам да, мәсьәләнең асылын аңлап булмый иде. Шулай да мәсьәләнең җитди һәм әһәмиятле булуы сизелеп тора. Ара-тирә аять һәм хәдисләр дә ишетелгәнгә, сөйләүчеләр арасында голамә булу ихтималын да уйлыйм. Араларында чалмалылар бик күп һәм араларында алтын җепләр белән чигүле чалмалар да бар. Барысын бергә җыеп, бет базарында аннан-моннан гына сатарга уйласак та, бер 100 лира эшләрлек чалма бар монда. Чалма бар, әмма мөнбәрдә утырган хатыйб әфәнденең килеш-кыяфәтенә карасаң, бик гади кешегә охшаганы аңлашыла иде.

Шулай итеп, чыгышларның бары тик дин мәсьәләсенә багышланган булуы бераз аңлашылса да, нәтиҗә бик аңлашылмый. Җыелыш ике сәгатьтән артык дәвам итте.

Ниһаять, шау-гөр килеп аякка торып бастылар, өч-дүрт кеше бергәләшеп чыга-чыга чыгып беттеләр, таралдылар. Шул арада икенде намазына азан ишетелде. Мин бик ашыгып кына тәһарәтләндем дә җәмәгать белән намаз кылдым. Имамнан башка тагын дүрт кеше бар. Боларның берсе – әле генә мөнбәрдә чыгыш ясаган хатыйб әфәнде иде.

Намаз кылганнан соң, әлеге хатыйб әфәнде, килеп, минем белән күреште, гарәпчә: «Кәйфә халүк [Хәлең ничек?]» – дигәч, мин аны гарәпчә белә дип уйлап, бу җыелышның нәрсә икәнен сорадым, тик кызганыч ки, аннан: «Йиһи», – дигән җавап алдым. Бик кәефсезләнеп мәчеттән чыктым, ишегалдында берничә кеше көтеп тора иде. Боларның берсе гарәпчә белә икән. Минем сөенечемнең чиге юк...

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

[2] Хатыйб – мәчеттә мәгънәле һәм үтемле итеп вәгазь сөйләүче кеше *(тәрҗ.иск.)*.

Ислам. Дини сүзлек

Корбан бәйрәме

Ислам динендә иң зур бәйрәмнәрнең берсе – Корбан бәйрәме (Ид әл-Әдха).

Хаҗ гамәле Корбан бәйрәме белән тәгәлләнә. Бәйрәмне Мәккәдән ерак түгел Мина үзәнендә билгелиләр, ул өч көн дәвам итә.

Бәйрәмнең килеп чыгуы Ибраһим пәйгамбәрнең (г.с.) тормышы һәм аның эшгамәлләре белән бәйле.

Пәйгамбәрнең (г.с.) 86 яшенә кадәр балалары булмаган, шуннан Исмәгыйль туган. Көннәрдән бер көнне Ибраһим төшендә бердәнбер улын корбанга китерергә тиешлеген күрә. Аллаһ ихтыярына каршы килергә базмыйча, ул Мина үзәненә килә һәм Исмәгыйльне корбанга китерергә әзерләнә башлый. Исмәгыйль дә әтисенә каршы килми, Аллаһ ихтыярына буйсына. Соңгы мизгелдә Ибраһим, сынауны үттең, тугрылыгыңны расладың, дигән сүзләр ишетә. Корбан тәкәгә алыштырыла. Шулай итеп, ислам динендә корбан китерү традициясе башланып китә.

Бәйрәмнең мәгънәсе – Аллаһка якынаю, аңа иман китерү. «Корбан» сүзе мөселман традицияләрендә «якынаю» дигәнне аңлата. Корбанга китерелә торган хайванның өчтән бер өлеше (тулысынча да ярый) сәдака рәвешендә мохтаҗларга өләшенергә тиеш. Икенче өлеше белән Корбан ашы уздырырга, өченче өлешен гаиләңә калдырырга мөмкин.

Корбан бәйрәме көне алдындагы төнне (Гарәфә киче) догаларда үткәрергә, Коръән укырга, тәхәҗҗуд намазын үтәргә, Аллаһтан гафу сорарга кирәк. Бәйрәм алдыннан (Гарәфә кичендә) укылган догалар кабул була дип санала. Корбан гаете көнне ураза тоту тыела.

Бәйрәм алдыннан мөселманнар госел коенып, госелле булган очракта тәһарәт кенә алып, чиста киемнәр кия. Ирләр мәчеткә гает намазына бара. Намаздан соң хөтбә укыла. Гадәттә, ул Аллаһка һәм Мөхәммәдкә (с.г.в.) зикер әйтүдән башлана, хаҗ гамәленең һәм корбан китерүнең мәгънәсе, әһәмияте аңлатыла.

Балигълык яшенә җиткән, сәфәрдә булмаган, кулыннан килгән һәр мөселман корбан китерә ала.

Корбанга тәкә, сарык сыер яки дөя китерелә (бәйрәм көннәрендә, ягъни өч көн дәвамында). Корбанга ярты елдан да (кайбер чыганакларда бер ел диелә) ким булмаска, ул сәламәт, күзгә күренеп торган җитешсезлекләрсез хайван булырга тиеш.

Сыер яки дөяне җиде кеше исеменнән чалырга була. Сарык яки тәкә бер кеше яисә гаилә исеменнән корбан ителә.

Язма төрле чыганакларга нигезләнеп әзерләнде. ■

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре[1]

Әхмәдвәли Рәхими

43

Әбү һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Җомгадан җомгага, Рамазаннан икенче Рамазанга хәтле зур гөнаһлардан саклану булса, биш вакыт намаз – шуларның араларында булган гөнаһларга кәффарәт[2]».

Укы һәм исеңдә калдыр!

44

Ибн Мәсгуд разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Аллаһ каршында гамәлләрнең сөеклесе – вакытында укылган намаз, аннан кала, Аллаһ юлында җиһад».

Укы һәм исеңдә калдыр!

45

Җәбир разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Гыйбадәт итүче бәндәне кяфердән аеручы гамәл – намаз уку».

Укы һәм исеңдә калдыр!

46

Әбү Өмамә разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Биш вакыт намазыгызны укыгыз, Рамазан ае уразасын тотыгыз, малыгыздан зәкят бирегез, имамыгызга итагать кылыгыз. Раббыгызның җәннәтенә керерсез».

Укы һәм исеңдә калдыр!

47

Гамру бин Шөгаиб разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Җиде яшьлек балаларыгызны намазга өйрәтегез. Ун яшьлек булсалар, мәҗбүр итеп булса да намазга кушыгыз һәм ятакларында кызлардан аерыгыз».

Укы һәм исеңдә калдыр!

48

Гобадә бине әс-Самит разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Фатиха» сүрәсен укымаган кешенең намазы камил булмас».

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

[1]Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

[2] Кәффарәт – гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш.

*Текстны басмага **Айсылу Вәлиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Унөченче дәрес

Дингә өндәү. Иң башлап иман китергән кешеләр. Мәккә мөшрикләренең пәйгамбәрләргә (г.с.) каршы төшүләре. Әбү Талибның Пәйгамбәрне (с.г.в.) химая кылуы. Мөшрикләрнең могҗиза сораулары

Мөгаллим: Хәзрәти Мөхәммәдкә (с.г.в.) нинди җирдә пәйгамбәрлек килгән дигән идек әле?

Шәкерт: Хира тавында килгән, дидек.

Мөгаллим: Дөрес. Аңа шунда пәйгамбәрлек килгән, бу вакыт пәйгамбәргә (г.с.) кырык яшь булган. Пәйгамбәрлек килү белән ул иң башлап яшерен сурәттә генә дингә өндәргә керешкән, чөнки ачык сурәттә пәйгамбәрлеген сөйләп, дингә өнди башласа, мөшрикләр каршы төшәрләр, үзенә зарар китерерләр дип курыккан. Шунлыктан ул элек дусларына, сүзе үтәрлек кешеләргә генә ачылган. Мөхәммәд (с.г.в.) әүвәлдән үк бик тугры булганга, бер дә ялган сөйләмәгәнгә, яхшы күңелле бәгъзе бер кешеләр аңа шунда ук ышанганнар. Пәйгамбәрнең (с.г.в) хатыны Хәдичәнең Вәрака исемле бер якыны булган. Ул хәзрәти Гайсә (г.с.) динендәге бер галим икән. Хира тавында үзенә фәрештә килү вакыйгасын сөйләү белән, Хәдичә Пәйгамбәрне (с.г.в.) аңа алып киткән. Вәрака моңа: «Син – чын пәйгамбәрсең. Ул фәрештә Муса (г.с.) пәйгамбәргә пәйгамбәрлек китергән Җәбраил фәрештә инде», – дигән. Шулай итеп, хәзрәти Мөхәммәднең (с.г.в.) пәйгамбәрлегенә иң беренче ышанучы кеше ошбу Вәрака булган. Ул бу вакытта инде күзләре сукрайган бер карт икән, озак тормый вафат булган. Пәйгамбәргә (с.г.в) иң башлап хатыны Хәдичә белән аның якын дусты хәзрәти Әбү Бәкер дә иман китергәннәр. Шулай ук Әбү Талибның улы Гали дә иман китергән. Бу вакыт әле ул бала гына булган. Әбү Бәкер яхшы дәүләтле бер сәүдәгәр саналып, халыкка бик сөекле, бик игътибарлы вә сүзе үтүче кеше икән. Ул да үзенә ияреرлек кешеләрне дингә өндәгән. Шулай итеп, аның аркылы да берничә кеше Пәйгамбәргә (с.г.в.) иман китергән.

Күпмедер вакыт шулай яшерен сурәттә дингә өндәгәч, бервакыт Аллаһы Тәгалә аңа халыкны дингә ачыктан-ачык өндәргә кушкан. Шунлыктан, Пәйгамбәр (с.г.в.) Мәккәдәге бер тау башына менгән дә, бик каты тавыш белән кычкырып, үз янына халыкны чакыра башлаган. Халык, агылып, тау янына җыелган. Шулай итеп, тау тирәсе халык белән тулган. Шуннан соң хәзрәти Мөхәммәд (с.г.в.) үзенең Аллаһы Тагалә тарафыннан пәйгамбәр итеп җибәрелгәнлеген, аларны хак дингә өндәргә кушылганлыгы турында сөйләгән. Халык бер дә көтелмәгән бу эшкә аптырап

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

калган. Ләкин хәзрәти Мөхәммәднең (с.г.в.) моңа кадәр бик яхшылык, тугрылык, ышанычлылык белән танылганлыгын игътибарга алып, аңа бер дә каршы сүз әйтмәгәннәр. Бары Пәйгамбәрнең (с.г.в.) атасы белән бертуган агасы Әбү Ләһәб кенә аңа бик ачуланган: «Дөмеккере нәрсә, шуның өчен безне монда чакырып китердеңме?!» – дигән. Менә шул вакыттан алып, Пәйгамбәр (с.г.в.) халыкны ачыктан-ачык дингә өнди башлаган. Мәккә мөшрикләре, бигрәк тә олуг кешеләрнең моңа бик эчләре пошкан. Үзләреннән түбән бер кешенең, хосусан ата-анадан фәкыйрь хәлдә ятим калган бер бәндәнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан пәйгамбәр итеп җибәрелдем диюеннән бик көнләшкәннәр. Алар бөтен көчләре белән аңа каршы торырга тырышканнар. Аңа бигрәк тә дошман кешеләр Әбү Ләһәб белән Әбү Җәһел исемендәге кешеләр булган. Болар аны күрә алмаганнар. Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) исә үз эшен һаман дәвам иткән. Ул, Аллаһы Тәгаләнең кушуы буенча, әледән-әле тегеләрнең потларын кимсеткән, аларның тоткан юлларын, диннәрен, гореф-гадәтләрен тәнкыйтьләгән. Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер Аллаһыга гыйбадәт итәргә, изге гамәлләр кылырга өндәгән. Акрынлап аңа иярүчеләр булып торган, ләкин күпчелек дошманлыкларын арттыра гына барган. Шулай да болар аңа күп зарар китерә алмаганнар. Мөхәммәдтән (с.г.в.) көлү, аны мәсхәрә кылудан узмаганнар, чөнки агасы Әбү Талиб гарәпләр арасында бик олуг вә хөрмәтле бер кеше булган, шуңа аннан курыкканнар. Ул үз кардәшен дошманнардан нык саклаган, аңа (с.г.в) тияргә ирек бирмәгән.

Мөшрикләр, Пәйгамбәрнең (с.г.в.) үзенә нык зарар китерә алмасалар да, аңа иярген кешеләрне бик каты җәберләгәннәр. Аларга гыйбадәт кылырга да ирек бирмәгәннәр. Шунлыктан, алар качып-посып кына гыйбадәт итә торган булганнар. Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.), Аллаһы Тәгаләнең ярдәменә ышанып, үз эшен һаман да дәвам иткән. Халыкның көлүенә, мәсхәрә кылуына, иптәшләренә җәберзолым итүенә бер дә игътибар бирмәгән, сабырлык саклаган. Мәккә мөшрикләре аның пәйгамбәрлегенә дәлил итеп могҗиза сораганнар. Ул: «Пәйгамбәрлегемә могҗизам – Коръән. Әгәр дә сез мине ялганчы дисәгез, шул Коръәндәге кебек итеп бер генә юл сөйләгез», – дигән. Тегеләр, никадәр тарышсалар да, булдыра алмаганнар, бөтенләй җиңелгәннәр. Без бит элегрәк пәйгамбәрләргә Аллаһы Тәгалә тарафыннан китаплар бирелгән дип әйткән идек, шулай түгелме?

Шәкерт: Шулай, пәйгамбәрләргә китаплар бирелгән.

Мөгаллим: Менә Мөхәммәд пәйгамбәргә (с.г.в.) Коръән исемле китап бирелгән инде. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) могҗизасы да шул булган. Мәккәдә нинди мәчет бар иде әле, Гариф?

Шәкерт: Кәгъбәтуллаһ бар.

Мөгаллим: Ул кайчан салынган иде?

Шәкерт: Ибраһим вә Исмәгыйль пәйгамбәрләр (г.с.) заманында, алар тарафыннан салынган.

Мөгаллим: Менә шул Кәгъбәтуллаһ Гарәбстандагы бөтен гарәпләр өчен изге урын санала, Гарәбстанның төрле тарафларыннан ел саен халык җыелып, анда үзләренчә гыйбадәт кыла торганнар иде. Кәгъбәтуллаһка җыелып гыйбадәт кылуга хаҗ кылу диләр. Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) әнә шул хаҗ кылу өчен килгән башка гарәпләрне дә бер дә күздән ычкындырмый, аларны да дингә өнди торган булган.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2022

Шагыйрь Сирин һәм Мөхәммәт Парсин

Әнвәр Шәрипов, филология фәннәре докторы

Журналист, театр тәнкыйтьчесе, «Сәйяр» труппасы артисты, Әтнә театрына нигез салучыларның берсе Мөхәммәт Зариф улы Парсин (1899-1963)

Шагыйрь Сирин 1930-1935 нче елларда «Татиздат» нәшриятында авыл хуҗалыгы бүлегендә редактор булып эшли. Бу – аның киң колач белән иҗат итеп яшәгән, күренекле трибун шагыйрь булып танылган чоры: ул күп санда шигырьләр, берничә поэма иҗат итә, «Тамчылар» дигән шигырьләр җыентыгын (1931), балалар өчен кечкенә-кечкенә рәсемле шигырь китапларын («Җәй», «Күз», «Кыш», «Яз», «Трамвайлар ник туктаган?», «Кеше», «Җиләк бакчасы» һ.б.) чыгара һәм авыл хуҗалыгы турында русчадан китап-брошюралар тәрҗемә итә. Сирин бу елларда әдәби тормышның үзәгендә кайный: Һ.Такташ, Х.Туфан, Г.Кутуй, Ә.Исхак, К.Нәҗми, Н.Баян һәм башкалар белән аралашып иҗат итә, үзенә яңа танышлар булдыра. Шулар арасында күренекле журналист Мөхәммәт Парсин (1899-1963) да була.

Сирин белән Мөхәммәт Парсинның тормышларында да, тоткан мәсләкләрендә дә уртак яклар, уртак мизгелләр бар: алар икесе дә ул елларда Совет хакимиятенә ихлас бирелгәннәр (гәрчә икесе ике төбәктә яшәгән булсалар да) – үзләре яшәгән авылларда комсомол ячейкалары төзүдә, спектакльләр куюны оештыруда актив катнашалар, халыкны агарту, мәгърифәт тарату өлкәсендә бик тырышып эшлиләр. М.Парсин «Кызыл яшьләр» газетасында, «Кызыл Шәрыкъ яшьләре» журналында редактор, 1925 елдан алып «Кызыл Татарстан» газетасында хәбәрче булып хезмәт куя. Сирин Мөхәммәт Парсин белән шул елларда танышкандыр, күрәсең. Шуннан соң бу ике шәхес тә репрессиягә эләгә, икесе дә биш ел Сталин лагеренда җәфа чигеп яшәргә мәҗбүр ителә.

Сөрген срогын тутырып кайткач та (Сирин – 1940 елда, Парсин – 1948 елда), алар бер-берсе белән аралашып, элемтәдә торып яшәгәннәр. Моның дәлиле – үзара алышкан хатлар.

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивы «Мирасханә»сендә Мөхәммәт Парсинның хатыны Хәятнең 1964 елда Сирингә язган ике хаты саклана. Бу хатлар аларның үзара мөнәсәбәтләренең нинди характерда булуын яктырта. Хәят ханымның үзендә дә шагыйрьлек күәсе булган икән: хатларында ул үз шигырьләрен дә китерә. Хәзер әлеге хатларның үзләренә сүз бирик. Беренче хат:

«21 / I – 64. Зеленодольск шәһәре.

Хөрмәтле Сирин ага һәм Фәһимә ханым!

Сезгә ихтирам белән, сәлам сөйләп, Зеленодольск шәһәрендә яшәүче Парсин семьясы.

Иптәш Батыршин! Сез миңа, Октябрь бәйрәме белән котлап һәм кайгыларымны уртаклашып, гаять җылы, озын бер хат язган идегез. Аның өчен Сезгә кабат рәхмәтемне белдерәм.

Ул хатыгызда Сез үзегезнең вакытлыча гына больницадан өйгә кайтуыгыз турында язган идегез. Гафу итегез! Минем Сезнең бүгенге көндәге хәлегезне беләсем килә. Сәламәтләнеп бетә алдыгызмы? Нинди авыру белән авырдыгыз? Фәһимә ханымның кәефе ничек?

Мин Сезгә чиксез гомер һәм корыч сәламәтлек телим! Иң кирәге – сәламәтлек, тынычлык. Болар – яшәүнең нигезе һәм үзәге. Үзегезнең семьяда тагын кемнәрегез бар? Уллар-кызларыгызның үз семьясы – Сезнең оныклар бармы? Алар кайда, ничек яшиләр? Сезне шатландыралармы?

Без картларның шатлыгы да, бәхете дә, өмете дә – балалар. Укытып, аларны олы юлга бастырып, онықларны коммунизм җәмгыятенә яраклы кеше итеп тәрбияләшүдә бурычыбыз бар.

Без Мөхәммәт белән ике улыбызны үстереп хезмәт юлына бастыргач та, менә карткынам үлеп китте. Оныкларны күрү – балаларның шатлыгын күрү бәхетенә ирешә алмадык. Әлбәттә, атаанага хас бөтен авырлыкларны бергә кичердек. Әле мин дә балаларның семьясын, оныкларны күрү бәхетенә ирешә алган юк.

Кече улым Альфред әтисе Мөхәммәтне, ундүрт яшендә вакыт, вокзалда очратып: «Әти таптым, өч сумга сатып алам. Әнием, ул шундый добрый!..» – дип, кулын-



Шагыйрь, Ютазы районының Кәрәкәшле авылы тумасы Сирин (Мөхәммәдсәйрин Хәниф улы Батыршин, 1896-1969)

нан тотып алып кергән иде. Бу 1946 ел иде, март ае иде. (Әлеге тарихи вакыйганы язып тормыйм.) Хәзерге көндә Польшада, армия хезмәтендә. Ул киләчәк елга хезмәтен тәмамлап кайтырга тиеш. Менә шушы улыма гашыйк булып, Мөхәммәт, без торган станциягә килеп (кечкенә малайны күреп сөйләшү өчен), аны эзләп йөргән. Аңа улым беренче күрүдә үк: «Әти!» – дип эндәшкән. Шырпы коробкасына тутырган (ул вакытта эшкә яраксыз) вак акчасын тәкъдим итеп, Мөхәммәтне «сатып алуына» ышандырган...

Кыскасы, Мөхәммәтнең минем семьям белән һәм үзем белән якынлашуына сәбәпче шушы кечкенә Альфред иде. Механический техникум бетереп, дүрт кенә ай эшләп, армиягә китте. Икенчесе – олы улым – Альберт, Мөхәммәт килгәндә мәктәпкә кергән (беренче класс тәмамлау елы) иде. Хәзер конструкторское бюрода инженер-конструктор булып эшли.

Менә шушы балаларны үстерү эшен үзебезнең башка хезмәтләребезгә бәйләп алып бару дәверендә шактый мәшакатьле һәм кызыклы гомерләр үткән бит (17 ел бергә яшәдек). Мин хәзер шушы үткән гомерләрне уйлап, Сезнең хатыгызда язылганча, үткәнгә хисап биреп:

Көрәш белән, алда бәхет көтеп,
Хезмәт йөген бергә тарттырып,
«Җиттек!»– дигәч, инде ятим калдым,
Тол хатыннар санын арттырып,

– диясем килде.

Бу Сезнең шигырьне дә һәм мин бик күптән укыган Заһид Нуркинның тәрҗемә «Бәхет» хикәясен дә кабатлый бугай. Мөхәммәтне бик сагынам һәм кызганам. «Сабый чактан ук, дөнья рәхәтенә караганда, күбрәк михнәтен-газабын күреп, соңгы гомерем шөкер итәрлек булгач, мин авырый башладым», – ди иде. Тагын хотя бы 10 ел яши алмады. Яңа елда аны искә алып:

Бәлки, әйтәсездер:
Буламы соң
Һаман сагыну, әрнү кабартып,
Хатың саен аны искә алып,
Кайгыларны кабат яңартып?..
Мең тугыз йөз алтмыш дүртенче ел!..
Тәбрик хатын яздым ялгызым.
Туганнарым, дуслар бик күп идек,
Сүнде якты – ялгыз йолдызым.
Бәйрәм таңы!..
Иң кадерле кешең
Мөмкинме соң искә алмаска?!.
Бераз гына башым иеп торсам,
Дусларымның хәтере калмас ла?..
Гафу итегез!
Кайгыларым яшерәм,
Сөртә-сөртә яшьле күзләрем;
Якыннарым тәбрик итәр өчен
Матур-матур сүзләр эзләдем.
Ялыктырган булсам,
Гафу үтенәм, –
Уртаклашып яздым барсын да.

Сәламәтлек, шатлык, озын гомер,
Уңыш теләп, Хәят Парсина.

Беренче язган озын хатымны тагын җибәрә алмыйм әле. Вакыты җиткәч, җибәрермен. Хушыгыз, гаеп итмәгез».

Менә Хәят Парсинаның икенче хатындагы «Ул бәхетле!»шигыре:

«Ул бәхетле!
Шундый көчкә ия,
Истән чыкмый изге эшләре.
Онытып булмый аны,
Бер минутка
Тыеп булмый сагыну хисләрен.
Дуслар да күп, никтер, ялгызсынам,
Аны эзлим, аны юксынам...
Инде куркам, зәгыйфьләнеп калсам,
Давылларда сынган гөл сыман...
Аерылышу хисен һәркем шулай,
Шулай авыр кичерә микән соң?..
Үзгәләнеп үтәр микән гомер?!.
Әллә азрак сүрелә микән соң?..
Ул бәхетле!
Шундый көчкә ия:
Рәс(е)мен күрсәм, аңа баш иям.
Бергә үткән гомрен сагына күңел,
Тыелып булмый үксим –
яшь түгәм.
Йөрәк түзми мондый зәгыйфьлеккә:
«Ял ит азрак, тупла көчең, – ди. –
Онытылмаслык эзләр калдыралсаң,
Табылыр сагыныр, өзелер кешең», – ди.
Ихтыярлы көчем,
Табармын да
Ихтирамга лаек эшемне!
Тик табалмам һәркөн искә алып,
Мине өзелеп сагыныр кешемне.

(Мөхәммәтнең йөрәге туктаганга нәкъ 9 ай тулгач.
7/I – 64 ел.)
Хәят Парсина».

Күренә ки, Сирин аралашкан кешеләр арасында илһам җиле кагылган шәхесләр дә булган икән. Бу, чыннан да, бөек Тукаебызның: «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул», – дигән сүзләрен тагын бер тапкыр раслап тора. ■

ПРОЗАИК, ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ДРАМАТУРГ РӘДИФ СӘГЪДИГӘ 65 ЯШЬ

Гомерләр уза икән ул...

Фирдәвес Зариф

Әнисе Гөлчирә белән әтисе Нәҗип. 1956 ел

Кечкенә Рәдиф әнисе Гөлчирә ханым белән. 17 июль, 1959 ел

Рәдиф Театр училищесының III курсында, Совет Армиясенә китәргә йөргән көннәре. 1976 ел

Рәдиф Сәгъдигә 65 яшь тула, дигәч, баштарак күңел ышанмыйча торды.

Ничек инде? Кыяфәте егетләрчә, бер-бер артлы саллы романнар иҗат итә, драматургиядә «ат уйната»... Әмма иҗат юлының озынлыгына күз салгач, ирексездән ышанырга мәҗбүр буласың.

21 пьесасы төрле театрларда куелган. Күпчелеге – балалар өчен әкиятләр. Сабыйлар өчен иҗат итәргә нинди зур осталык һәм ихласлык, күңел сафлыгы кирәклеген бөтен тулылыгы белән балалар әдәбияты өлкәсендә иҗат иткән әдипләр генә аңлый ала торгандыр... «Казан утлары», «Мәйдан», «Идел» журналларында детектив әсәрләре дөнья күрде. 30дан артык сценарий, йөзләгән мәкалә, шулай ук «Лаешым», «Кама-Тамагым», «Киләм, диден, килмәдең», «Сау бул, Казан», «Йолдыз атыла», «Кайттым, бәхетле ит әле» һәм башка җыр текстлары авторы. «Гаилә һәм мәктәп», «Көмеш

> «
> *Рәдиф Сәгъдинең үз теле, үз стиле бар.*
>
> **Туфан Миңнуллин**

кыңгырау» һ.б. басмаларда балалар өчен шигырьләре даими басылып килә.

Иҗатка гомуми күзәтүне исә драматургиядән башлау урынлырак булыр. Рәдиф Сәгъди узган гасырның 80 нче еллары башында Казан театр училищесын тәмамлап, Әлмәт дәүләт драма, Татар дәүләт күчмә театрларында уйнап, өметле актер буларак таныла башлый. Тик шуннан соң, тормышында холкына хас кискен борылыш ясап, сәхнәдән китеп бара.

Хәер, китеп барды дип әйтү бик үк урынлы булмас: театрларда ул язган пьесалар буенча бер-бер артлы спектакльләр куела башлады. Мисал өчен, «Яз галәмәте», «Сынган беләзек» әсәрләрен театр сөючеләр яратып кабул итте. Тормыш вакыйгаларыннан гыйбрәт алырга, милләт язмышы хакында уйланырга мәҗбүр итә алар.

> **«**
>
> ***Язучының балалар өчен әкиятләре булсынмы, өлкәннәр өчен пьесаларымы – барысы да көчле лирикага, йөрәк җылысына төрелгән!***
>
> **Дания Гыймранова, театр белгече**

Бер үк вакытта, иҗади мөмкинлекләрен киңәйтү максаты белән, ул 1986-1992 нче елларда Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультетында белем алды.

Рәдиф Сәгъди, драматургия белән генә чикләнеп калмыйча, прозага күчте: кыска хикәяләр, повесть һәм романнары дөнья күрде. Алар журналларда һәм аерым китап булып та басылдылар. Авырлыклар күреп, «нужа мәктәбе» сабакларын алып үскәнгә, аның әсәрләре тормышчанлыгы белән аерылып тора, зур ышандыру көченә ия.

Татарстан Язучылар берлегенең Матур әдәбиятны пропагандалау бүлегенә җитәкчелек иткәндә, Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрының Әдәби бүлек мөдире булып эшләгәндә, Рәдиф Сәгъди, яшь талантларны эзләп табып, аларны үстерүгә күп көч куйды.

Аның, «Безнең мирас» журналы редакциясендә бүлек мөхәррире вазыйфасын башкарганда, халкыбызның бай тарихи, мәдәни, әдәби, рухи мирасын кире кайтаруга зур өлеш керткәнлеген дә аерым билгеләп үтәргә кирәктер. Хәер, ул әле дә журнал редакциясе белән актив хезмәттәшлек итә.

> **«**
>
> ***Ул – кискен конфликтлар кору остасы. Әлеге сыйфат аның драматург булуыннан киләдер. Рәдиф Сәгъдинең каһарманнары туры сүзле, нык холыклы. Аның әсәрләрен иренеп-ялкауланып укымыйсың. Вакыйгалар сине бөтереп үзенә ияртә. Рәдиф Сәгъдинең үз укучысы бар. Үз укучыңны табу – язучы өчен зур уңыш.***
>
> **Ркаил Зәйдулла**

Зур күләмле әсәрләренә бәя биргәндә, сүзне озынга сузмас өчен, «Казан утлары» журналының 2021 елгы 4 нче һәм 5 нче саннарында басылып чыккан «Алло, кем әле бу?!» дигән романына гына аерым тукталып үтәм.

Гәрчә исеме үк үзенә ымсындырып торса да, ничектер, кул җитмичә торды. Моңа романның журнал варианты булуы да йогынты ясамый калмагандыр. Озын сүзнең кыскасы, коррупциягә, урлауга, гаделсезлекләргә ияләшеп бара, ис китмичәрәк, битараф карый башладык бугай.

Бүгенге укучыны тема яңалыгы белән шаккатырып булмый анысы. Кешеләр күңелендә өмет уятуы, гаделсез җәмгыятьтә дә гаделлек эзләве белән игътибарны җәлеп итте бу роман. Безгә гыйбрәт-сабак кына биреп калмыйча, тәрбияли дә ул. Башка криминаль романнардан нәкъ менә шул сыйфатыүзенчәлеге белән аерылып тора Рәдиф Сәгъдинең «Алло, кем әле бу?!» әсәре.

Роман кульминация ноктасыннан чишелешкә күчүдән башлана. СМУдан даими рәвештә тимер-томыр ватыклары – металлолом урлана, алай гына да түгел, кеше үтерелә. Нәтиҗәдә, караклык һәм кеше үтерү маддәләре бунча җинаять эше ачылып, шикләнелүчеләрдән сорау алу башлана.

> «
> ***Язучының иҗаты күңелдә икеләнүсез-нисез бер генә төрле фикер уята. Һичшиксез, таулы ил төзегән ул! Инде киң катлам укучыларга һәм театр тамашачыларына яхшы танылган нәсерче, прозаик, драматург һәм публицист, әдәбият һәм театр сөючеләрне куандырып, каләмен әсәрдән-әсәргә тагын да үткенләштерә, кыюлаштыра бара.***
>
> **Ризван Хәмид**

Язучы, мәсләгенә тугры калып, бу әсәрендә дә, вакыйганы тасвирлау белән генә чикләнмичә, тормыш чынбарлыгын ачып сала. Хокук саклау өлкәсендә эшләүчеләрне бер максат – җинаятьчене тиз арада эзләп табып, аңа канунда каралган җәзаны бирү берләштерергә тиеш булса да, бирелә дә туган-тумачалык, «әшнәлек» өстенлек итә икән. Тикшерүче майор Ярмәкәев мәлсез ярдәмчесе лейтенант Галимуллинны яңа укып кайткан Борнашевка алыштырырга теләсә дә,

«Сынган беләзек» спектакленнән бер күренеш. Зиннур ролендә – Рәдиф Сәгъди, Мифтахетдин ролендә – Татарстанның халык артисты Хәлил Мәхмүтов. К.Тинчурин театры. 2009 ел

Рәдиф Сәгъди «Безнең мирас» журналы редакциясе хезмәткәрләре белән. 2019 ел

моны эшли алмый, чөнки хатынының абыйсы министрлыкта югары урын били. Нәтиҗәдә, булдыксыз ярдәмчесенә түзеп торырга туры килә.

Автор җинаятьтә шикләнелүчеләр турында сүз барганда да кеше язмышын алгы планга чыгара. Бөтен дәлилләр Бориковка каршы булса да, тәҗрибәле тикшерүче Ярмәкәев аның кеше үтерүче икәнлегенә шикләнеп тә куя. Бориковның да бит гаиләсе, балалары бар. Төрмәгә 15-20 елга утыртып куйсалар, алар туендыручысыз кала бит.

Рәдиф Сәгъди

Гомумән, хокук саклау өлкәсен һәм аның хезмәткәрләре психологиясен белеп яза роман авторы. Башта кеше үтерүдә шикләнелгән, аннары, гаебе расланды, дип, җинаятьче буларак хөкем ителгән Юрий Бориковның төрмә камерасындагы психологик кичерешләре, әнисе Ларисаның чарасыз хәлгә төшеп өзгәләнүләре, табигатьтәге үзгәрешләрне тасвирлау да әсәрнең тәэсир итү көчен арттыра төшә. Хәтта төрмә шулпасын кат-кат татыган рецидивист Тамара да, төрмә башлыгы Крачков та бөтенләй икенче яктан – кешелекле шәхесләр буларак ачыла. Җәзаларны үтәтү системасындагы җитешсезлек һәм проблемалар, зиндан камерасындагы атмосфера һәм җинаятьчеләрнең үзара мөнәсәбәтләре дә читтә калмаган Рәдиф Сәгъдинең каләменнән, чөнки ул аларның дөньясын якыннан белә. Мондый мәгълүматларны туплау өчен эзләнүчән-күзәтүчән булу гына җитми, зур тормыш юлы да үтәргә кирәк. Әсәрнең эчке катламын ачарга ярдәм иткән аерым эпизодлар, диалоглар да ышандыра.

Әдәби әсәрне әсәр иткән тагын бернәрсәгә тукталмыйча кала алмыйм. Ул – роман авторының сюжет кору осталыгы. Һич көтмәгәндә, композиция бөтенлегенә зыян китермичә, сюжет сызыгы кискен борылыш ала. Инде суд карары чыгып, кеше үтерүдә гаепләнеп, 13 елга, СМУ малына кул сузганы өчен 3 елга, гомумән алганда, 16 елга хөкем ителгән Юрий Дмитриевич Бориковның эше, кассация шикаяте нигезендә кабат каралып, гаепсезлеге ачыклана. Ул суд залыннан ук иреккә чыгарыла. Әлбәттә, бу очраклы рәвештә генә килеп чыкмый, моңа вакыйгаларның эзлекле бәйләнеше сәбәпче була. Өстәвенә, Юрий Бориковның әнисе гомер буе яшереп саклаган сер дә ачыла.

> «
> ***Рәдиф Сәгъди – разведкага алып барып, исән-сау алып кайта торган шәхес!***
>
> **Ләбиб Лерон**

Романга шул урында нокта да куеп булыр иде. Әмма автор укучыны кабат интрига алдында калдыра: «Телефон шалтырады... Алучы булмагач, ул тынарга уйламады да. Күн диванда яткан берәү, ятагын кармалап, дивар читендә үк яткан кесә

телефонын табып алды. Йокысы ачылып җитмәгән килеш иренеп кенә:

– Алло, кем әле бу?! – дип сорады.

– Мин әле бу, братан, классташың Фәндәс! Хәлләр ничек? – дип чәрелдәде трубканың икенче башында берәү.

Бориков коры гына:

– Ярыйсы! – дип куйды.

– Беләсеңме, Юра, монда шундый файдалы эш чыгып тора! Күпләп сату базарына склад мөдире кирәк, аңлыйсыңмы? Анда ни генә килми: эшелон белән чикләвекләр, шоколад-конфетлар, уылдык-балык, тушенкалар! Өстәвенә, шәрабны шешәләргә тутыру цехы да синең кул астында булачак! Аңлыйсыңмы? Ул шәраблар мичкәләр белән килә. Шешәләргә тутырганда, шалт бер-ике чиләк суны! Коньяклар да шунда эш ителә, үз өлешеңне аласың да мичкә саен суын саласың гына! Беләсеңме, күпме акча эшләргә була! – дип тезде дә тезде генә судан коры чыга белүче классташы.

Юрий Дмитриевич аны тыңламый да иде инде. Ул, телефонын мендәре белән каплап, әйләнеп ятты. Сөйли бирсен, әйдә...»

Бу юллардан соң көндәлдә: «Бер авыз пешкәч, өреп кабарга кирәк. Иң мөһиме – якыннары, чын дуслары исән булсын. Биргәненә шөкер итеп яшәргә дә яшәргә, әгәр тыныч йоклыйсың килсә...» – дип нәтиҗә ясагандыр Бориков дигән өмет кала.

Дистәләгән детектив, криминаль әсәрләр авторы Рәдиф Сәгъди романының журнал вариантын укып чыккач, әсәр белән тулысынча танышу теләге тагын да көчәйде. Моның өчен романның тизрәк китап булып чыгуын көтәргә кала. Бирсен Ходай!

Рәдиф Сәгъдинең пьесаларында нечкә хис, көчле лиризм, күздән яшь китерерлек тирән психологизм, әби-бабайлардан килгән кешелеклелек-шәфкатьлелек өстенлек итсә, детектив роман һәм повестьларында исә кансызлык-вәхшилек күренешләре бөтен нечкәлекләре белән тасвирлана. Детектив әсәрләрендә спорт залларына йөреп тупланган кырыслыгы

«

Р.Сәгъди, вакыйгаларны тотып алу белән берраттән, детектив жанрына тугры калып, мавыктыргыч сюжетка сала. Аның әсәрләре бер сулышта укыла. Укыйсың да: «Бу адәм балаларының җан өшеткеч вәхшилекләр эшләргә ничек куллары бара икән?» – дип уйлап куясың.

Вакыйф Нуриев

«

...Әсәр яшәү дәверендә кешеләрнең бәхетле булырга омтылулары хакында. Шушы омтылышны автор үзенчәлекле сюжет, вакыйгалар агышы, образлар аша яктыртуга ирешә алган. Яугир хатын-кызларның тормыш рәвешен сурәтләве генә дә Р.Сәгъдинең татар прозасына алып килгән зур яңалыгы булып тора. Моны күрми калу мөмкин түгел. «Ирдәүкәләр» романы борынгы дастаннар рухына туры килә, үзе дә бүгенге татар мохитенә яраклаштырылган озын бер тарихи дастан.

Лилия Мөхәммәтҗанова, филология фәннәре кандидаты



чагыладыр, күрәсең. Дөрес, кешеләр белән аралашканда моның капма-каршысы – ярдәмгә әзер торучанлык, ихлас күнеллелек-самимилек, игелеккә һәрчак игелек белән җавап кайтару кебек сыйфатлар өстенлек итә. Боларның барысы да бер йөрәккә ничек сыеша, ул ничек түзә икән дип гаҗәпләнеп тә куясың…

Язмамның башында Рәдиф Сәгъдинең гомер бәйрәме икәнлеген искәрткән идем. Юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек, тигезлек белән яшәп, әдәбият сөючеләрне әле яңа әсәрләре белән озак еллар буе куандырырга насыйп булсын дигән теләктә калып, аның иҗатына кыскача күзәтүгә нокта куям. ■

Егор Уткин шигырьләре

Егор Васильевич Уткин 1932 елның 27 июлендә хәзерге Менделеевск районындагы Бөрешле авылында туган. Шигырь китаплары: «Төнге яшен» (1969), «Минем романтикам» (1971), «Офыкларда алсу болытлар» (1976), «Күңелемә коя чишмәләр» (2007).

Шагыйрь 1977 елның 23 декабрендә вафат булды.

Кайту

Кызык эзләп кайтуларым түгел,
Маҗаралар эзләп китмәдем...
Артык күреп үстем һәрнәрсәдән
Туган җирнең хәләл икмәген.

Кала коймалары бүлеп тормый
Торган җирне туган җиремнән.
Балалар күк шаулап, кайттыңмы, дип,
Каршы ала мине игеннәр.

Миңа таба әнә йөгерә-йөгерә,
Колач җәеп килә солылар.
Солыларның кочагына кереп,
Сабый балалардай сыенам.

Җилләр сөя биттән йомшак кына,
Әй нечкәрде күңел, хисләнде.
Җаным җиргә тамыр җибәргән җир –
Туган авылым кыры, исәнме!

Җилдә янган учак кебек

Кеше китә, тирләп-пешеп иген игә,
Шатлык чишмәләрен ача, йортлар сала,
Йөрәккәе җилдә янган учак кебек...
Кеше бара, юллар ярып яна-яна.

Кеше китә... Карый җиргә, карый таңга
Күреп туймас, сөеп туймас күзе белән.
Бар шатлыгын безгә биреп калдыра ул,
Кайгыларын гына ала үзе белән... ■

Сыннар мәҗмугасы турында хыял

Зәрия Хәбипова



Күренекле татар язучысы, 1973 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, диңгезче, Баулы районының Исергәп авылы тумасы Миргазиян Юныс (Миргазиян Закир улы Юнысов, 1927-2014)

Миргазиян Юныс Әлмәттә биш еллап яшәде (1997-2002) һәм аның нефтьчеләр башкаласына күченүе дә көтмәгәндә-уйламаганда килеп чыкты кебек.

Без Миргазиян абый белән авылдашлар гына түгел, ирем ягыннан да, әтием ягыннан да туганлык җепләре дә бар. Ләкин аралашып яшәмәдек. Безне Миргазиян абый белән бәйләгән нәрсәләр – аның матбугатта чыккан үткен язмалары, диңгезчеләр тормышына багышланган мавыктыргыч романнары булды.

Шулай да ниндидер сер булып күренмәсен өчен, туганлыкны бераз күрсәтеп китү кирәктер. Миргазиян абыйның әнисе Факия әби 1892 елда туган. Аның әтисе Әхмәтҗан белән безнең әтинең бабасы Миңлебай – бертуган егетләр. Факия әби озын буйлы, чая, чибәр, эшчән, укымышлы һәм бик яхшы хәтерле булган. Ике ире дә фаҗигале рәвештә үлгәч, өченчегә – Закир исемле кешегә – Миргазиян һәм Вахит абыйларның әтиләренә кияүгә чыккан ул. Факия әби

Коръәннең күп сүрәләрен яттан белгән, кич утырганда Йосыф китабын кычкырып укыган, шуңа аны авылда «мулла әби» дип йөртәләр иде. Миргазиян абыйның, әнисен сагынып: «Безнең әни: «Эшләп арыганым юк», – дип әйтә иде», – дип сөйләгәне хәтердә. Беренче иреннән туган Кәшифә апа минем ирем белән икетуган балалар булып, без аның хәлен белергә кергәли идек. Картайган көнендә Факия әби Кәшифә апада торды, абыйлар да Баулыга аның янына кайтып йөрде.

Олыгайгач, адәм баласын туган туфрагы ныграк тарта башлый. Бертуган Юнысовлар белән дә шулай булды, ахры. Миргазиян абый да, энесе Вахит абый да, эштән туктагач, авылга ешрак кайтып, Сабан туйларында күренеп китә башладылар. Бер кайтканнарында без аларны үзебезгә кунакка чакырдык. Миргазиян абый каядыр китү сәбәпле, Вахит абый үзе генә килде. Табын корып, дөнья, авыл хәлләре турында озаклап сөйләшеп утырдык. Хатирәләрдән тәмам әсәрләнгән кунагыбыз: «Яшь чагында мин бу урамның бер гүзәле артыннан йөргән идем, әйләнеп килим әле таныш сукмакларны», – дип чыгып китте. Хәтсез вакыт үткәч, моңсу гына кайтып керде ул: «Кара, аягыма да кими чыгып киткәнмен икән. Ә гүзәлемнең үзе түгел, туган йорты да юк икән инде...» – дип уфтанып куйды.

Шулай аралашып киттек. Миргазиян абый үзе яраткан берәр кешесе турында сөйләгәндә: «Искиткеч!» – дип әйтергә ярата иде. Бу сүз аның үзенә дә бик ятышлы икән бит. Ул, әнисенә охшап, искиткеч эшчән, бик яхшы хәтерле, каты холык һәм нечкә күңеллелекне бергә сыйдырган кеше иде. (Андый шәхесләр сирәк була.) Дөньяны колачларга омтылуы да искиткеч иде аның. Ни белән генә кызыксынмады ул: әдәбият, музыка, рәсем сәнгате, архитектура, скульптура, психология, фәлсәфә – һәрберсеннән хәбәрдар, сөйләшкәндә һәрвакыт җитди дәлилләр китереп, үз фикерен төгәл әйтеп сөйләшә иде.

Язудан арыган чакларында кулына өтерге һәм пычаклар алып, агачтан төрле метафорик рухтагы сыннар да ясый икән. Ул, әлеге сыннарын Баулыга алып кайтып, күргәзмә дә оештырды. Алар турында берәр альбом чыгару теләге барлыгын әйтте: «Якташлар бераз ярдәм күрсәтмәсләрме...» Уйлары шундыерак иде аның...

Миргазиян абыйның 1996 елның җәен күбрәк Баулыда үткәргәне хәтердә. Хатыны белән кызы чит илгә ял итәргә киткәннәр икән, ә ул һаман шул сыннар турында альбом чыгарып булмасмы дип йөрде. Сыннарын фотога төшерергә танылган фотограф Дамир Йосыповны да ияртеп кайткан иде. Иске фоторәсемнәр, авыл күренешләре, ата-бабалардан калган кул эшләре үрнәкләре, Миргазиян абый үзе – барысы да фотографның үткен күзеннән кичерелеп, рәсемгә төшерелделәр. Матур гына тупланма барлыкка килде. Акча мәсьәләсенә килеп терәлгәч, эш тукталды. Баулы хакимияте башта килешү төзеп, акча вәгъдә итсә дә, кризисны сылтау итеп, килешүне үти алмады. Материал җыюга, килешү төзүгә минем дә катнашым бар иде, кыен хәлдә калдык... Дамир, кулын селтәп, Казанга китеп барды.

Бәхетне Әлмәттә сынап карарга булдык. Миргазиян абый Әлмәткә килеп, унбиш көнләп бездә торды. Шул арада барлык Әлмәт язучылары белән дә танышып, аралашып чыкты. Ул бигрәк тә Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәттә язучылар бүлеген җитәкләгән шагыйрь һәм композитор Разим Вәлиуллин белән якынаеп китте. Разим ул вакытта олы бер хыял белән янып йөри – Әлмәтне Татарстанның нефть башкаласы гына итеп түгел, ә рухи башкала итеп



Миргазиян Юныс ясаган сыннар

тә күрсәтәсе килә иде. Моны тормышка ашыру өчен төзелгән «Рухият» фонды шуның нигезе булырга тиеш иде. Фондның соңыннан нефть төбәгендә киң колач белән, республика күләмендә зур яңгыраш алып эшләп китүе стратегиянең дөрес сайланганлыгы турында сөйли. Шул максатлардан чыгып, Разим Миргазиян абыйны Әлмәткә күчеп кайтырга күндергән һәм фатир сорап хакимияткә керүне дә үз өстенә алган икән.

Хәзер булса, моңа тотынып та булмас иде – хәл ителде бит торак мәсьәләсе. Миргазиян абыебыз җитмеш яшен яңа фатирда каршылады. Юбилейга багышлап тантаналы итеп олы бәйрәм үткәрелде. Мәскәүдән дуслары, хатыны белән кызы да килде. Менә шулай итеп, һич көтмәгәндә-уйламаганда ул Әлмәт кешесе булды да куйды.

Миргазиян абый табигате буенча сәяхәтче иде. Вахит абый да, үзенең йөремсәклегеннән көлеп: «Бер ай өйдә торсам, үземне үлгән дип хис итәм», –дип сөйли иде. Әниләре Факия әби дә: «Гел, поездга утырып, каядыр китәсем килә», – дип әйтә торган булган. Бик борынгыдан канга сеңгән күчмәлек хисеме бу, башка нәрсәме, әмма шунысы хак – безнең халыкның яңа җирләргә күчү дәрте һәрчак көчле булган. Шуңадыр, Әлмәткә күчеп яши башлауны Миргазиян абый шатланып кабул итте, күчеш аны илһамландырып җибәрде. Килеп урнашу белән картиналар галереясында агач сыннары күргәзмәсен оештырды. Төркемләп килгән карау-чыларга иҗаты турында сөйләргә еш кына үзе алынды ул. Хәтсез кеше танышты аның бу эшләре белән. Мифологик сыннар остасы Әхсән Фәтхетдиновның Түбән Камадан махсус килеп, күргәзмәне озаклап карап йөргәне, күргәзмәгә куелган эшләргә сокланып: «Нинди нечкәләп ясаган һәр сынын», – дип әйткәне хәтердә. Татар гимназиясендә осталык дәресләре дә алып барды Миргазиян абый. Очрашулар, аерым әсәрләренә багышланган кичәләр безнең калада гына түгел, тирә-яктагы башка шәһәр-авылларда да булды ул елларда.

Миргазиян Юныс китаплары

Ныклы дуслар табып, күп кешеләрнең ярдәмен тоеп яшәде Миргазиян абый Әлмәттә. Төрле оешмалар аңа сизелерлек матди ярдәм күрсәтте: фатирын җиһазладылар, елына бер-ике тапкыр ял йортына бушлай барды. Разимнан тыш, Шәһит Таипов, Абрек Шәйдуллин, Ирек Бәдретдинов һәм тагын берничә кеше, үз туганнарын караган кебек, аның хәлен даими белешеп, һәр йомышын йомышлап торды. Без еш кына үзебезне хурлап, таркаулыкта, битарафлыкта гаепләп сөйләргә яратабыз. Яхшылап уйласаң, беркем дә чит кешенең бөтен йөген үзенә ала алмый. Аягында йөргән һәр кеше үз көнен үзе күрергә ярал-

Әдип Миргазиян Юныйсның әнисе Факия (рәсемдә уртада) күршеләре Бадыйгылҗәннәт (сулда) һәм Сүәрә (уңда) белән

тылган. Ә Миргазиян абыйның Әлмәттәге ихтирамлы, ярдәмле тормышы ул халкыбызның олы иҗат кешесенә булган хөрмәтенең бер чагылышы иде.

Шулай яшәп, бер-ике ел үтте. Күп кенә әсәрләр язды, матбугатта еш басылды Миргазиян абый. Һәр язганына: «Языла бит!» – дип сөенә иде. Ә сыннар турындагы альбом мәсьәләсе һаман баштан чыкмый бит инде… Разим белән төрле оешмаларга кереп сөйләшеп карадылар бугай, тик акча мәсьәләсе чишелмәде. Монда, акчадан да бигрәк, сынчы буларак аны аңлаучы табылмады дип уйлыйм. Ахырда ярдәмне тагын Татнефтьнең генераль директоры, Дәүләт Советы депутаты Шәфәгать Тахаутдиновтан сорарга дигән уйга киленде. Иң башта депутатның кабул итү бүлмәсенә барып, хәлне аңлату кирәк иде. Анда абый белән икәү киттек. «Юл күрсәтерсең. Кирәкмәгәнне сөйли башласам, җиңемнән тартырсың», – дигән вазыйфа йөкләнде миңа. Җиңеннән тартырга туры килмәде. Депутат ярдәмчесе Фикүс Хәсән улы Закиров безне сабыр гына тыңлап, сорауларында әдәбиятны яхшы белгәнлеген, абыйны язучы буларак нык хөрмәт иткәнен сиздереп, күңелебезгә өмет орлыклары салып чыгарды.

Бер атна узгандырмы-юкмы, Миргазиян абыйны Татнефтьнең генераль директоры Шәфәгать Тахаутдинов кабул итте. Бик дулкынланып килеп керде ул безгә әлеге очрашудан соң. Сөйләшү бик тирән эчтәлекле булган, Шәфәгать әфәнде аңа альбом белән генә чикләнмәскә, ә «Рухият» фонды ярдәме белән бөтен язган әсәрләрен бастырып чыгарырга да тәкъдим иткән һәм 2001 елның эш планына кертергә ризалыгын сораган икән. Ризалык?! Кайсы язучы бу турыда хыялланмый!..

Җиң сызганып эшкә керешә Миргазиян абый. Китапларның тышлык бизәлеше, эчендәге фотосурәтләрне урнаштыру, рәсемнәр – барысы да үзе

күзаллаганча махсус заказ белән эшләнде. Равил Рахмани аның иҗатын фәлсәфи яктан ачкан зур кереш сүз генә язып калмады, ә әсәрләрен җыеп туплаучы һәм китапның мөхәррире дә булды. Шулай итеп, «Рухият» фонды ярдәме белән һәм уртак тырышлык нәтиҗәсендә, Миргазиян Юнысның әсәрләре биш томлык затлы, башкаларга өлге булырдай китаплар рәвешендә басылып та чыкты.

Кечкенә шәһәр тормышы тар тоелдымы, нәшрият һәм редакторларга якынрак буласы килдеме – китаплары басыла башлагач, Миргазиян абый Казанга күченеп китте. «Күп проектларым бар әле минем...» – фикере шундыерак иде аның. Озак та тормады, Әлмәткә кабат кайтып: «Юкка киткәнмен икән!» – дигән сүзләр әйтеп уфтанды. Ул, бәлки, Казанда да Әлмәттәге кебек авылча, туганнарча мөнәсәбәт табарга уйлагандыр, әмма зур шәһәр кешесе ябык яши, һәркемнең үз кайгысы... Бу фикерләр аның «Табу һәм югалту» повестенда бик ачык әйтелгән. Нәтиҗәдә, Казанда бер еллап яшәгәннән соң, яңадан Мәскәүгә кайтып китте ул.

Сыннарга килгәндә, тагын ниндидер аңлашылмаучылык килеп чыкты – алтынчы том басылмады, калды сыннар. Соңгы язган хатында: «Өемдә аунап яталар», – дип, сыннары турында ачынып искә алган иде. Шулай да агач сыннар мәҗмугасы турындагы хыялны мондый өметсез «нота»да тәмамлыйсым килми. Миргазиян Юнысның агачтан юнып ясалган сыннары гына түгел, скульптура турындагы фикерләре дә – сәнгатьне аңларга теләгән кешеләр өчен бик зарури бер язма. Милли күтәрелешкә хезмәт иткән иҗаты бу яктан да өйрәнелер дигән фикердә калам. Аның Әлмәттәге сыннар күргәзмәсен ачу тантанасын милләттәшебез Илдар Насыйбуллин үз вакытында видеога төшергән иде һәм Шәһит Таипов видеоны хәзерге форматка күчереп, «ютуб»ка куйды. «М.Юныс. Малые шедевры большого мастера» фильмында без Миргазиян абыйның һәр сыны турында аларны тудырган оста аңлатмасын ишетәбез. Сирәк кадрлар...

Миргазиян абыйның үз агач сыннары турында кешеләргә бик тә җиткерәсе, аңлатасы килә иде. Бәгъренә тигән фикерләрен ул «Сыннар белән сөйләшү» әсәре аша безгә, киләчәк укучыларына, төбәп язган: *«Сын, иҗади сәнгать әсәре буларак, адәм баласының зәвыгын тәрбияли, матур ялганны ачы хакыйкатьтән аерырга, шулар арасындагы чикне табып, үзеңнең нинди чынбарлыкта яшәвеңне тоярга ярдәм итә.*

Йөз меңләп тиражланган юлбашчы потлары, киресенчә, адәм баласының миен томаларга, аның күзенә төтен җибәрергә генә ярый.

Скульптураларны мин дүрт төркемгә бүләм. Беренче төркемгә без горурланган, рухыбызга йогынты ясаган шәхесләр керә. Икенче төркемдә тарихыбызга, язмышыбызга нисбәтле хәләтләр чагылыш тапкан. Өченче төркемдә – гомумән, тормышыбызга кагылышлы катлаулы проблемалар. Дүртенче төркемдә – безне манкортлашуга, инкыйразга этәргән кара көчләр.

Татарның бөек шагыйре һәм рухиятебезнең су башы Кол Галине укыганга кадәр күп элек мин аның «Йосыф китабы»н әниемнән ишеттем. Шәрыкта мөгез – гакыл символы. Кол Галинең маңгаеннан өскә, җиденче кат күкләргә таба юнәлтелгән билге аның чалмасын, сәҗдә кылганда сузган кулларын һәм, шәрыкча, аның зирәк акыл иясе булуын аңлата».

Фикерен ул: *«Зыялыларыбыз бу сынны аңлыйлар шикелле»,* – дип тәмамлаган.

Мин дә язмамны, килер вакыт, без аны, һичшиксез, ныклап өйрәнербез һәм аңларбыз, дип тәгәллим. ■

Сугыш кайтавазы

Дания Кәшипова

Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң 77 ел үтсә дә, сугышта катнашкан якташларыбызның язмышын барлау һаман дәвам итә. Бүгенге көндә төрле чыганаклардан мәгълүмат табып була. Ярдәмгә «Хәтер» китаплары, интернет челтәрләр килә. Төрле документларга, чыганакларга таянып, музей хезмәткәрләре Сарман районы хәрби комиссариаты 1939-1945 нче елларда хәрби хезмәткә алган, Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларыбызның язмышын ачыклады, кайберләренекен тулыландырды.

Юныс Әхмәт улы Әхмәтшин 1895 елны Яшьләр авылында туган (соңрак «Селькор» күмәк хуҗалыгы). Сарман районы хәрби комиссариаты тарафыннан Кызыл Армия сафларына алынган. 1943 елда соңгы хезмәт иткән урыны 324 нче укчы дивизиясенең 1091 нче сапер полкы. Өстәмә мәгълүмат: 1943 елның 19 июлендә Орлов өлкәсенең Жиздринский районы тирәсендә хәбәрсез югалган.

Никита Дмитриевич Воронов хакында «Хәтер» китабының 20 нче томында Могилев өлкәсендә җирләнгән дип язылган. Ул 1899 елны Петровка авылында туган, Кызыл Армия сафларына Сарман хәрби комиссариаты тарафыннан 1942 елның 20 апрелендә алынган. 324 нче укчы дивизиядә хезмәт иткән. «Хәтер» китабының 46 нчы битендә: «Воронов Никита (Николай) Дмитрий улы, 1899, Петровка ав., Сарман РХК моб., к-арм, 11.1943 һәлак булган, Могилев өлк.(?) җирл.», – дип язылган. Яңа мәгълүмат буенча ул Смоленск өлкәсенең Думинич районындагы Думинич авыл җирлегенә кергән Чернышино авылы тирәсендә 1942 елның 6 сентябрендә һәлак булган. Җирләнгән җире дә шушы авылның туганнар каберлегендә.

Хәй Гәрәй улы Гәрәев 1923 елда Сарман авылында туган, Сарман хәрби комиссариаты тарафыннан Кызыл Армия сафларына 1942 елда алынган. «Хәтер» китабының 20 нче томының 64 нче битендә аның турында мәгълүмат бик аз. Шуңа өстәп, Хәй абзыйның 41 нче гвардия укчы дивизия составында Сталинград сугышында катнашканы һәм 1942 елда һәлак булганы ачыкланды. Беренчел күмелгән җире: Сталинград өлкәсенең Клетский районындагы Перекопка авылыннан 1500 м ераклыкта.

Закир Закир улы Кәримов 1903 елны Иске Минзәләбаш авылында туган. Сарман Хәрби комиссариаты тарафыннан 1941 елда Кызыл Армия сафларына алынган. Иң беренче барып җиткән җире – 111 нче запас укчы полкы. 6167 нче команда составында 1941 елның 25 ноябреннән 238 нче укчы дивизиянең 843 укчы полкында 1653 нче хәрби частьтә хезмәт иткән. 1941 елның 14 декабрендә Тула өлкәсенең Дугнин районы тирәсендә хәбәрсез югалган.

Фотолар Сарман муниципаль районы Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәну музее фондыннан алынды.

Тагын бер якташыбыз – **Әнәс Хәсән улы Кашапов.** («Хәтер» китабы, 20 нче том, 105 нче бит.) Ул 1924 елны Сарман авылында туган. 1942 елның 12 августында хәрби хезмәткә алынган. Подольск шәһәрендә урнашкан хәрби-политик училищеда укыган. 1943 елның 4 ноябрендә Иваново шәһәрендә урнашкан хәрби җыелма пунктта 924 нче укчы полк составында булган. 1943 елдан Көнбатыш фронтның 87 нче запас кавалерия полкыннан 8 нче кавалерия дивизиясенең 49 нчы кавалерия полкына күчерелгән. Сержант дәрәҗәсендә хезмәт иткән. I Украина фронтының 6 нчы кавалерия дивизиясенең 49 нчы кавалерия полкы составында хезмәт куйганда, I Украина фронтының 1944 елның 4 августында чыккан 10 нчы Приказы нигезендә «Батырлык өчен» («За отвагу») медале белән бүләкләнгән. 1944 елның сентябрь аенда хәбәрсез югалган.

1925 елның 15 августында Петровка авылында туган **Василий Антонович Кондратьев** хакында «Алар илгә Җиңү китерде» (226 нчы бит) дип аталган китапта шактый мәгълүмат бар. Василий Антоновичның II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены белән (1985) бүләкләнүе билгеле. Өстәп шуны гына әйтәсе килә: 1945 елның 1 июнендә 8 нче Приказ белән – «Батырлык өчен» («За отвагу») медале, 1953 елны СССР Югары Советы Президиумы тарафыннан «Сугышчан казанышлары өчен» («За боевые заслуги»), «За победу над Германией в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.» «За освобождение Праги» медальләре тапшырылган.



Василий Кондратьев

1924 елда хәзерге Сарман районының Бикмәт авылында туган **Гавриил Павлович Леонтьев** хакында Алабуга районының Быковка авылында туган дип язылган. «Хәтер» китабының 20 нче томында (113 нче бит) аның турында шактый мәгълүмат бирелгән. Ул 1942 елның август аенда Сарман районы хәрби комиссариаты тарафыннан Кызыл Армия сафларына алынган. 377 нче запастагы укчы полктан 556 нчы укчы полкка күчерелгән. Аны, уң аягы яраланып, Тула өлкәсенең Калужск районындагы Калуга шәһәрендә урнашкан 3584 нче эвакогоспитальгә китергәннәр. Ул 1943 елның 19 июлендә 9 сәгать 30 минутта вафат булган. Җирләнгән җире: Тула өлкәсенең Калуга шәһәрендә урнашкан Пятницк зираты, 9 нчы участок, көнчыгыштан-көнбатышка таба урнашкан 1,2 каберлек.

1941 елда Ленинград калманышта калып, блокада башлангач, аннан байтак кешене эвакуациялиләр. Эвакуацияләнүчеләр арасында **Нина Владимировна Уткина** да була. Нина Владимировна 1922 елда Ленинград өлкәсенең Ленинград шәһәрендә туган. Сарманга эвакуацияләнүчеләр арасында Нина белән әнисе Александра Васильевна да була. Урта мәктәпне уңышлы гына тәмамлаган яшь

кыз югары белем алу өчен институтка укырга кергән, ләкин сугыш һәр кешенең язмышына үз төзәтмәләрен керткән. 1942 елның 19 июлендә ул Сарман хәрби комиссариаты тарафыннан Кызыл Армия сафларына алынган. Украина, Белоруссия җирләрендә сугышка керергә туры килгән Нина Владимировнага. Тула шәһәре өчен барган каты сугышларда 50 нче армиянең 58 нче запас укчы полкы составында катнашкан. Хәрби хезмәтен гади солдат булып башлаган 19 яшьлек кыз өлкән сержант дәрәҗәсенә кадәр барып җиткән.

Бөек Ватан сугышы елларында илебез азатлыгы өчен башын салган тагын бер якташыбыз **– Владимир Павлович Ямашев.** «Хәтер» китабының 20 нче томында аның бары исеме һәм хәрби часте генә язылган. Бу мәгълүматны тулыландырып шуны әйтергә була: 1907 елда туган Владимир Павлович Ямашев 1941 елда сугышка мобилизацияләнгән. Калуга өлкәсендә урнашкан Барятинск районы 1941 елның 5 октябрендә дошман тарафыннан бөтенләй оккупацияләнгән була. Халык өчен бик авыр чор башлана. Бары 1942 елның 7 гыйнварында гына Мамоново, Гостижье, Одринка, Камкино, Спасское, Асмолово, Новое село һәм Труфаново авыллары 326 нчы укчы дивизия сугышчылары тарафыннан азат ителә. Якташыбыз Ямашев Владимир Павлович 326 нчы укчы дивизия составында Труфаново авылы өчен барган каты сугышларда 1942 елның 11 мартында һәлак булган һәм шунда җирләнгән.

1955 елда Голосиловка, Имән, Малоросс, Муравка, Яңа Авыл, Труфаново авылларындагы ялгыз һәм зур булмаган туганнар каберлекләреннән совет сугышчыларының җәсәдләрен җирләү нәтиҗәсендә Туганнар каберлеге барлыкка килә. Якташыбыз Владимир Павлович Ямашев, 97 сугышчы белән бергә, шушы Туганнар каберлегендә җирләнгән. Бүгенге көндә меңләгән якташыбыз хәбәрсез югалган булып санала. Шулар арасындагы Владимир Павлович Ямашевның кайчан һәлак булганлыгы һәм җирләнгән урыны билгеле булды.

Тагын бер якташыбыз 1902 елда туган **Фатыйх Габдерәшит улы Габдерәшитов**. Бөек Ватан сугышына ул 1941 елда Чаллы хәрби комиссариаты тарафыннан чакырылган. Фатыйх Габдерәшитов Барятин районы өчен барган каты сугышлар вакытында Зайцева Гора («Куян Тавы») авылы янында 1942 елның 19 апрелендә һәлак булган. Җәсәде Зайцева Гора авылында урнашкан «Зайцева гора» Мемориаль комплексына җирләнгән.

Бу – Мемориаль комплекста иң зур каберлек. Ул 1943 елда Фомино I (Цветовка) һәм Фомино II (Зубровка) авыллары янындагы ялгыз һәм туганнар каберлекләреннән сугышчылар мәетләрен берләштереп җирләү нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Ике йөз утыз ел элек, Рымник елгасы янындагы сугыш тәмамланганнан соң, бөек полководец Александр Васильевич Суворовка рус гаскәрләренең җиңүе хакында хәбәр иткәч, ул: «Һәлак булучылар җирләнгәнме?» – дип сорый. «Юк», – дигән җавап ишеткәч, ул йөзләгән еллардан соң да актуальлеген югалтмаган сүзләрне әйтә: «Соңгы һәлак булган солдат җиргә бирелми торып, сугыш тәмамланмаган санала!» («Пока не будет предан земле последний погибший солдат – война не окончена!»). Бүгенге көндә рәхимсез сугышта башларын салган якташларыбыз алдындагы бурычыбыз әле үтәлмәгән. Исемнәрен илгә кайтарып һәм каберләрен ачыклап кына, без аларга тиешенчә хөрмәт күрсәтә алабыз. ■

Истә, һаман да истә!

Тел галиме Гомәр Саттаровның туууына 90 ел



Тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, ТАССРның һәм РФнең атказанган фән эшлеклесе, ТРның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Фәез улы Саттаров 1932 елның 2 июлендә Яшел Үзән районындагы Мулла Иле авылында туган.

1950-1955 нче елларда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала, аннары Тубыл дәүләт педагогия институтында өлкән укытучы булып эшли.

1959-1962 нче елларда исә Гомәр Саттаров профессор М.З.Зәкиев җитәкчелегендә аспирантура үтә, Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасында хезмәт куя.

1967 елдан – доцент, 1981 елдан – профессор. 1994-1999 нчы елларда ул – татар теле кафедрасы мөдире.

Гомәр Саттаров 2020 елның 26 августында вафат булды һәм туган авылы зиратында җирләнде.

Дәүләт эшлеклесе Мирсәет Солтангалиевнең туууына 130 ел

Сәясәт һәм дәүләт эшлеклесе, публицист, Сталин чорында мөселман халыклары арасында иң югары дәрәҗәдә торган большевик-җитәкче Мирсәет Хәйдәргали улы Солтангалиев 1892 елның 13 июлендә Уфа губернасындагы Кырмыскалы авылында туган.

1917 елның 1-11 май көннәрендә Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнарының съезды булып, Мирсәет Солтангалиев анда Бөтенроссия Мөселманнар Советының секретаре итеп сайлана. 1918 елның гыйнвар башында М.Солтангалиевне Эчке Россия һәм Себер мөселманнары эше буенча комиссариат рәисе итеп билгелиләр. Шул ук вакытта ул губерна Мөселман комиссариаты рәисе итеп тә куела. Мулланур Вахитов һәлак булгач, Мирсәет Солтангалиев Үзәк мөселман хәрби коллегиясен җитәкли.

1923 елның 9-12 сентябрь көннәрендә Мәскәүдә РКП(б)ның Дүртенче киңәшмәсе уза һәм анда, «Солтангалиев эше» каралып, М.Солтангалиевкә «Совет хакимиятенең дошманы» дигән исем тагыла.

1930 елда М.Солтангалиевне үлем җәзасына хөкем итәләр. Ярты елдан соң бу карар 10 елга төрмәдә утыруга алмаштырыла. 1934 елда аны вакытыннан элек иреккә чыгаралар. Ләкин 1937 елда Мирсәет Солтангалиевне тагын төрмәгә ябалар һәм 1940 елның 28 гыйнварында атып үтерәләр (хатыны һәм ике баласы да төрмәдә һәлак була).

Безнең мирас №7 июль 2022

Очучы Мәгубә Сыртланованың туууына 110 ел

Очучы, Советлар Союзы Герое Мәгубә Хөсәен кызы Сыртланова 1912 елның 15 июлендә Уфа губернасының (хәзерге Башкортстан Республикасы) Бәләбәй шәһәрендә туган.

Ул Тбилисида аэроклуб һәм Үзәк планер мәктәбен тәмамлый.

1941 елның июленнән М.Сыртланова, звено командиры сыйфатында, санитар авиация отрядында оча. 1942 елның декабреннән ул Бөек Ватан сугышы фронтларында – 4 нче һава армиясенә караган 325 нче төнге бомбардировщиклар авиация дивизиясенең 46 нчы гвардия полкында эскадрилья командиры урынбасары була. Очучы 2 нче Белоруссия фронты авиациясе составында Кавказ (1942-1943 нче еллар), Тамань ярымутравы (1943), Кырым (1944), Илбау-Сандомир (1944), Көнчыгыш Пруссия һәм Берлин юнәлешендәге һөҗүм сугышларында катнаша. Гвардия өлкән лейтенанты М.Сыртланова 1945 елның маена кадәр 780 сугышчан очыш ясый һәм дошманның күп кенә гаскәри көчләре белән техникасын юк итә.

М.Сыртланова Ленин, ике Кызыл Байрак, II дәрәҗә Ватан сугышы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр белән бүләкләнә. 1946 елның 15 маенда аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Сугыштан соң ул, Казан шәһәрендә яшәп, заводта эшли.

М.Сыртланова 1971 елның 1 октябрендә вафат булды.

Әдәбият галиме Галимҗан Нигъмәтинең тууына 125 ел

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче, профессор, 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Галимҗан Әмирҗан улы Нигъмәти (Нигъмәтуллин) 1897 елның 26 июлендә хәзерге Башкортстанның Болагавар (кайбер чыганакларда – Чишмә) районына кергән Өйдерәкбаш авылында туган. Галимҗанга ике яшь чагында аның әтисе, гаиләсен алып, Уфа шәһәренә күчә, улын Уфаның алдынгы «Галия» мәдрәсәсенә урнаштыра.

Галимҗан Нигъмәти 1926 елның ахырында Казанга килә һәм «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасының баш редакторы итеп билгеләнә. 1928-1930 нчы елларда Татар дәүләт нәшриятының баш мөхәррире булып эшли. 1930-1932 нче елларда ул, төп эшеннән аерылмыйча, «Яңалиф» журналының редакторы да булып тора.

Педагог буларак, Галимҗан Нигъмәти татар әдәбияты фәне буенча югары квалификацияле белгечләр хәзерләү эшенә күп көч сала.

Галимҗан Нигъмәти 1937 елның 16 сентябрендә кулга алына. 1940 елның 17 гыйнварында махсус «өчлек» аны биш елга ирегеннән мәхрүм итә – ул Устьвымлаг лагерена җибәрелә. Галимҗан Нигъмәти 1941 елның 4 ноябрендә (кайбер чыганакларда – 4 декабрьдә) вафат була (ачлыктан һәм хәлсезлектән булса кирәк) һәм Коми Республикасының Княжепогост районындагы Вожаель бистәсе зиратында җирләнә. ■

*Сахифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Фани дөньяның бөек Бакые

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Бакый Урманче

Казан шәһәрендәге Габдулла Тукай музее даими рәвештә күптөрле мәдәни-әдәби-мәгърифәти чаралар оештырып тора, халкыбызны, килгән кунакларны милли-рухи һәм инсани яктан тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә. Шундыйларның берсе бөек рәссам Бакый ага Урманченың тууына 125 ел тулу уңае белән уздырылды. Анда бу олуг затыбызның, нигездә, Тукай иҗатына мөнәсәбәтле рәсем-картиналары тамашачыларга тәкъдим ителде. 2022 елның 18 мартында үткәрелгән бу чарада күпләгән җәмәгатьчелек вәкилләре, рәссамнар, әдипләр, фән һәм сәнгать әһелләре катнашты. Күргәзмә ачылуда кызыклы чыгышлар булды. Бу вакыйга иҗтимагый-мәдәни тормышыбызда билгеле бер яңгыраш тапты. Аның хакында матбугатта, электрон чараларда да җылы сүзләр әйтелде. Хатыйп Йосыф угылына да Тукай музеендагы әлеге чарада катнашырга, тамашачылар алдында чыгыш ясарга туры килде. Ул радио-телевидениегә (җөмләдән «Татарлар» тапшыруына) интервьюлар да бирде. Хәзер Бакый ага Урманче күргәзмәсендә ясаган чыгышны укучыларга аерым өстәмә-кыскартулар белән тәкъдим итәбез.

***

Халкыбыз, илебез тарихының һәр чоры, һәр гасыры гаять катлаулы, каршылыклы, фаҗигале. Бу яктан аеруча 20 нче йөз бигрәк тә аерылып тора: инкыйлаб-

революцияләр, Беренче бөтендөнья, Илдәшләр (Ватандашлар), Бөек Ватан сугышлары, эреле-ваклы башка төрле орышлар; күмәкләшү, СССР төзелү һәм аның таркалуы, төрле репрессияләр һ.б. Гасыр яшьтәше дип әйтерлек Габделбакый Идрис угылы Урманче (10.02.1897-6.08.1990) боларның һәммәсенең үзәгендә кайнаган, янган-көйгән, куанган-кайгырган, төрмә-Соловки газапларын кичергән, әмма сынмаган-сыгылмаган, берөзлексез эшләгән, иҗат иткән, күпләр кызыгырлык яшәп, фанийлыктан бакыйлыкка күчеп киткән. Ә бит бу төр яшәеш – үзе зур батырлык, фидакярлек! Мондый тереклеге белән ул, рәсем-картиналарын исәпкә алмаганда да, мактау-хөрмәтләргә лаек.

Бакый аганың күп кенә мәшһүр әдип-галимнәрне, сәнгать әһелләрен биргән атаклы Буа якларыннан башланган гомер юлы Евразиянең шактый гына шәһәр-авыллары аша узган. Болар арасында Казан, Мәскәү, Алма-Ата, Ташкент, Сәмәрканд һәм кайбер башка калалар аеруча мөһим урынны били. Аның укыган урыннары, эшләгән тармаклары гына да берничә дистәдән артып китә. Бу мөхтәрәм зат гаҗәеп күптөрле вазыйфалар башкара, атаклы уку йортларының мөгаллиме дә була. Йөзләгән рәссамнар, сәнгать әһелләре аны үзләренең олуг остазлары дип саный. Бакый ага үз гомерендә күпләгән кешеләр белән аралашкан. Болар арасында, әдәбият, сәнгать һәм фән әһелләре белән берлектә, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре дә бар. Мәсәлән, аның озак еллар буе Казакъстанның җитәкчесе булган Динмөхәммәт Кунаев белән дустанә мөнәсәбәтләрдә торуы билгеле.

Бакый Урманче 1916-1917 нче елларда Урта Азия якларында хәрби хезмәттә була. 1941-1958 нче елларда Казакъстанда, Үзбәкстанда яши, иҗат итә, бу җөмһүриятләрнең мәдәниятләрен, милли сәнгатьләрен үстерүгә, кадрлар әзерләүгә гаять зур өлеш кертә. Әлеге төбәкләрдә аның күргәзмәләре оештырыла, рәсем-картиналары, сыннары күп кенә абруйлы залларны, музейларны бизәп тора. Казакъ халкының классик әдибе Мохтар Ауэзов (1897-1961) үз яшьтәшен бик тә хөрмәт итә. Юкка гына аның Алма-Атадагы музееның иң түрендә татар дусты ясаган күркәм портреты эленеп тормыйдыр. Бакый Урманче иҗат иткән Абай (1845-1804), Җамбул Җабаев (1846-1945), Сабит Моканов (1900-1973) кебек олуг затларның портретлары казакъ җәмәгатьчелеге тарафыннан хәзер дә югары бәяләнә.

Миңа 1983 елның көзендә Ташкент университетында өч айлап стажировка узарга туры килде. Моңа кадәр дә бу төбәкләрдә бераз яшәп алганлыктан, Үзбәкстан, Таҗикстан тарафлары миңа шактый якын-үз. Ташкентта күп кенә зыялылар белән аралаштым. Атаклы милләттәшебез, мәшһүр рәссам Чыңгыз ага Әхмәров (1912-1995) мастерскоендагы бер очрашу истә калган. Анда Бакый ага Урманче хакында да сүз чыкты. Үзбәк рәссамнары аны «бөек зат», «остазыбыз» дип атадылар. Аларга өстәп, Чыңгыз ага да Бакый Урманчены «тиңсез шәхес», «олуг художник» дип бәяләде. Мәгълүм ки, Бакый ага, Татарстан җитәкчелеге чакыруы буенча, 1958 елда кабат Казанга әйләнеп кайта һәм гомеренең ахырына кадәр биредә яши. Чыңгыз ага бу уңай белән бераз үкенечен дә белдерде. Аның: «Казанга кайтып, үз татарыма тулысы белән хезмәт күрсәтә алмадым», – дигән сүзләре хәзер дә колагымда яңгырый.

Бакый аганың рәссамлыгы, иҗат җимешләре турында шактый күп язылган. Мин рәсем сәнгате белгече түгел. Гомум планда бары шунысын гына әйтә алам: аның иҗат мирасы искиткеч бай, күпкырлы һәм үзе бер җиһан кебек. Аңа карап кына да авторның күңел дөньясы киңлеген, эрудиция-талантын, уй-кичерешләрен, рухи халәтен шактый дәрәҗәдә күзалларга мөмкин. Элеккеге чорларда елъязмалар жанры киң таралган була. Аларда мөһим вакыйга-хәлләр, күренешләр теркәлеп калган.

Бакый Урманче мирасы да, ничектер, шул елъязмаларны хәтерләтә. Аерма шунда: элеккеге авторлар күргән-ишеткәннәрен сүз ярдәмендә бәян иткәннәр. Бакый ага исә чынбарлыкны, күңел дөньясын рәсем-сурәтләр ярдәмендә гәүдәләндерә, күрер күзләр аша кабул ителә торган образлы дөнья тудыра. Бу рәсем-картиналар, сыннар аркылы, кинокадрлау кебек, без табигатьнең, тормышның, адәм балаларының, халыкларның яшәү рәвешләрен, тереклек тарихын күрәбез, аларга карап сокланабыз, кайгырабыз, уйланабыз. Күп кенә күренекле затларыбыз Бакый аганың иҗат җимешләре аша безнең күңелләргә сеңеп калган.

Ходай Тәгалә үзенең яраткан колларына иҗат-талантны кушучлап бирә дип юкка гына әйтмиләрдер. Бакый ага – моның күркәм бер мисалы. Күп кенә кешеләр аның гаҗәеп матур итеп җырлавын искә алалар. Узган гасыр ахырларында Түбән Кама шәһәрендәге «Җидегән чишмә» оешмасы аның белән очрашу кичәсе уздыра. Шунда 90 яшьлек бу мөхтәрәм зат үзенең матур һәм моңлы итеп җырлавы белән зал тулы тамашачыларны шаккатыра. Бакый ага төрле музыка коралларында да уйный. Ул дистәләгән телне, шул исәптән фарсы, гарәп, үзбәк, казакъ телләрен дә яхшы белә, дөнья, аеруча Шәрык әдәбиятыннан бик тә хәбәрдар була. Миңа шактый еллар буе татар сүз сәнгатенең гарәп, фарсы, төрки әдәбиятлары белән бәйләнешләрен өйрәнергә, хәтта шул проблема буенча докторлык диссертациясе дә язарга туры килде. Бакый ага белән сөйләшкәндә мин аның Шәрык классикасын камил белүенә соклана идем. Аның фарсы телендә Гомәр Хәйям робагыйларын, Хафиз газәлләрен көйләп укуын да хәтерлим.

Бакый Урманчены авыз тутырып шагыйрь дә дип әйтергә була. Ул мәдрәсәдә уку елларыннан алып гомеренең ахырына кадәр шигъри әсәрләр иҗат итә. Алар төрле жанрда; шактые – робагыйлар. Аның шигырьләрендә авторның күңел дөньясы, төрле вакыйга-хәлләргә мөнәсәбәте, уй-кичерешләре шактый үтемле һәм тәэсирле гәүдәләндерелгән:

«Бөтен дәрт вә теләкләремне горбәттә (читтә. – *Х.М.*)
Ташып, үзем белән караңгы гүргә
Алып китәрмен, ахры. (1942)

***

Казанда юк учак,
Мәскәүдә почмак
Гуя, телиләр күңелемә
Кадарга канлы пычак. (1949)»

«Васыять

Күзләрем бу дөньяга йомылса,
Каным җансыз, тәнем дәртсез суынса,
Барабаннар кагып,
Зинһар,
Йөрмәгез.
Тәңремнең дәргяһенә (катына, тупсасына. – *Х.М.*)
Тын гыйбадәт белән
Җирләгез.
Мөселман мин,
Тәмам исламча гүрләгез. (1958)»

***

«Яшьлектә гомер зур океан иде,
Инде калды кечкенә бер сазлык булып. (1980)»

Мондый мисалларны Бакый Урманченың әдәби мирасыннан күпләп китерергә мөмкин.

Ф.Халидинең иҗат мирасын, аның «1001 сәхәр» исемле мәшһүр китабын, шулай ук Г.Исхакый һәм кайбер башка әдипләрнең әсәрләрен гыйльми-текстологик яктан өйрәнгән Зөфәр Мөхәммәтшин соңгы елларда Бакый Урманченың әдәби мирасын, архивын барлау-тикшерү белән нәтиҗәле генә шөгыльләнә. Ул, мәсәлән, тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш мәкаләләр белән «Казан утлары» журналының 2022 елгы 2-3 нче саннарында Бакый аганың күп кенә шигырьләрен, хатирә-истәлек язмаларын киң катлам укучыларга тәкъдим итте. Аның мәкалә-публикацияләре халкыбызның бөек улы хакындагы күзаллауларын тагын да баета, тулыландыра. Галимебез бу юнәлештәге саваплы эшчәнлеген алга таба да дәвам итсен иде. [Шунысын да искәртик: хатирәләр авторының тел-стиле шактый бай, кызыклы. Арада архаик сүзләр дә күзгә ташлана. Бездә, мәсәлән, элек үлән кәлимәсе урынына ут сүзе кулланылган. Хәзер ул утлау, утау, утлык кебек сүзләр составында сакланган. Б.Урманче аны борынгы мәгънәсендә куллана: «чәнечкеле ут белән капланган дала». Татарчаны бик белмәгән кеше, аны «огненная степь» дип тә тәрҗемә итәргә мөмкин.] Бакый ага ислам тәгълиматыннан бик тә хәбәрдар иде. Аның «Коръән»не мәкам белән укуларын, дин турында эчтәлекле чыгышларын Хатыйп Йосыф угылының үзенә дә ишетергә-тыңларга туры килде.

Бакый ага, төрледән-төрле кавемнәр гомер кичергән төбәкләрдә, шәһәр-калаларда яшәсә һәм эшләсә дә, бөтен җаны-тәне, күңеле белән татар булып калды, милләтенә хезмәт итүне үзенең иң олуг вазыйфасы дип санады. Аның гаҗәеп бай иҗат мирасы, – Гаяз Исхакый әйтмешли, моның аяклы дәлиле. Ул аеруча Тукайны, аның герой-каһарманнарын, бигрәк тә Шүрәлеләрен якын-үз итте. Бөек шагыйребезнең күпләгән әсәрләре, басмалары мәшһүр рәссамның күңел җылысы белән өретелгән, аның музейларында Бакый аганың иҗат җимешләре күркәм урыннарны алып тора.

Бездә элеккеге мәдрәсәләрне тәнкыйтьләү, заманнан артта калуда гаепләү, урыс, Европа уку йортларын, университетларын күкләргә чөеп мактау тенденциясе хәзергәчә дәвам итә. Ә бит Ш.Мәрҗани, Х.Фәйзханов, Р.Фәхреддин, Г.Тукай, Г.Исхакый кебек бөек затларыбыз – шул мәдрәсә «җимешләре». «Мөхәммәдия» уку йорты – элеккеге татар мәгарифенең йөзек кашларыннан берсе. Бакый Урманченың иҗади һәм инсани үсешендә, миллилегендә бу мәдрәсәнең дә гаять зур роль уйнавын һич тә онытырга ярамый. Ни кызганыч, үзен «татар рәссамы» дип йөртүче соңгы дәвер художникларының шактые татарча юньләп укый да, яза да белми, милли-рухи мирастан хәбәрдар түгел. Хәтта арада үзенең газиз туган телен бөтенләй белмәүчеләр дә бар.

Мин шәхсән Бакый ага белән даими аралашып тордым дип әйтә алмыйм. Шулай да аз-маз очрашкаларга, әңгәмәләр корырга туры килде. Мондый аралашулар кайвакыт рәссамның җәмәгате, күренекле фольклорчы Флора ханым Әхмәтова аркылы бара иде. Аларның уллары Айдар да бездә – Казан университетының татар бүлегендә укыды. Бервакыт Флора ханым Бакый аганың безнең студентлар белән очрашасы килүен әйтте. Үзебезчә чакырырга булдык. Әмма агабыз үз янына



Бакый Урманче эш бүлмәсендә.
Вәкил Шәйхетдинов рәсеме

килүне хуп күрде. Мин, бер төркем студентларны алып, дулкынлана-дулкынлана олуг шәхебез янына киттем. Хуҗалар безне якты йөз белән каршы алды. Гаҗәеп кызыклы очрашу булды. Бакый ага дәртләнеп, илһамланып үзе ясаган рәсем-картиналарын, сыннарын күрсәтте. Музыка коралларында уйнап, җырлап-көйләп тә җибәрде. Татар һәм фарсы телләрендә шигырьләр дә укыды, кызыклы, мәзәк хәлләрне дә сөйләде. Аның юморга осталыгын да күрдек. Флора ханым тәмле-тәмле чәйләр, ризыклар белән дә сыйлады. Бакый аганың: «Бу кадәр матур кызларны ничек сайлап бетердең?» – дип соравы да хәтердә калган. Мин исә аңа: «Һич сайламадым, бездәге барлык кызлар да шулай матур», – дип җавап бирдем. Шунда Бакый ага: «Мондый гүзәлләр янында гел илһамланып кына йөрисездер, зиһеннәрегез дә тарала торгандыр», – дип куйды. Барыбыз да елмаештык. Ул Флора ханым чыккан вакыттарак кызларга мәхәббәт шигырьләрен дә укып җибәрде.

Шушы очрашудан соң Бакый ага университет студентлары белән ешрак аралаша башлады, аларга каллиграфия, рәсем сәнгате серләрен дә аңлатты. Олуг остаздан мондый сабак-дәресләр алган студентларыбызның берсе – Нәҗип Исмәгыйлев, без биргән филолог белгечлеге белән генә канәгатьләнмичә, рәссам, каллиграфист та булып китте, тугралар остасына әйләнде, Нәккаш тәхәллүс-кушаматы да алды, Тукай бүләгенә ия булу дәрәҗәсенә дә иреште.

Бакый Урманче – гәрчә күп кыенлык-газаплар, югалтулар кичерсә дә, гомумән, бәхетле зат. Ул үзенең гаҗәеп бай иҗаты белән сәнгать-мәдәниятне баетуга, үстерүгә гаять зур өлеш кертте. Үзе фанилыктан китсә дә, исеменә лаеклы мирас калдырды, күпләгән шәкертләрне тәрбияләп үстерде. Болар арасында мәдәниятнең, сәнгатьнең төрле тармакларында эз калдырган билгеле рәссам, график, улы Илдар Урманче да (1937-2001) мөһим урынны били.

Бакый ага дистәләгән мактаулы исемнәргә, дәрәҗәле премияләргә ия. Аның Татарстанның халык һәм Россиянең атказанган рәссамы, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә ия булуы үзләре генә күп нәрсә хакында сөйли. Һәйкәлләре, рәссамның исемен йөрткән урамнар, уку йортлары, музейлар бар. Бакый Урманче – халкыбызның бөек улы, горурлыгы. Аны искә төшерү, зурлау – милләтебезне дә олылау, хөрмәтләү ул. Бу юнәлештә «Буа якташлык җәмгыяте»нең (рәисе – Ирек Закиров) дә бик тә нәтиҗәле, саваплы гамәлләр кылуын искә төшерү урынлы булыр. ■

«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 100 ЕЛ

Юбилей мөнәсәбәтләре илә

Ләбиб Лерон

Гариф Ахунов (1972-1974 нче елларда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире)

Кулымда «Казан утлары» журналының 50 еллыгына нисбәтле документлар. Аларның барысы да диярлек журналның шул чактагы баш мөхәррире *(ул чакта күбрәк редактор сүзе кулланылган. – Л.Л.)* Гариф Ахунов тарафыннан имзаланган. Иң әүвәл 1972 елның 22 маенда узарга тиешле тантаналы кичәне оештыру максатыннан әзерләнгән проектка игътибарны юнәлтик әле:

«Юбилей үткәрү буенча оештыру планы.

1. 1972 елның беренче санында башлап «Казан утлары»нда журналның 50 еллык тарихын системалы рәвештә яктыртып барырга:

№1. Журналның үткән юлы турында редакция язмасы;

№3. Журнал битләрендә – әдәби тәнкыйть һәм публицистика (Гази Кашшаф);

№4. Татар совет әдәбиятында социалистик реализмны раслау өчен көрәш (Гомәр Бәширов);

№5. Татар язучыларының әсәрләрендә социализм уңышларының чагылышы (Газиз Иделле);

№5. Төп мәсьәләләр (Гариф Ахунов).

2. 1972 елның гыйнварыннан башлап 1972 елның маена кадәр китап укучылар белән конференцияләр уздыру (исемлек тәкъдим ителә).

3. Күренекле язучыларның – журналның актив авторларының һәм хезмәткәрләренең матбугатта, радиода һәм телевидениедә чыгышлары (редколлегия раслаган исемлек буенча).

4. Редколлегия әгъзаларын һәм редакциянең иң яхшы хезмәткәрләрен ТАССР Югары Советының Мактау грамотасы белән бүләкләү мәсьәләсен тиешле органнар аша хәл итү.

5. Аеруча актив авторларны һәм редакция хезмәткәрләрен бүләкләү өчен тәкъдимнәр кабул итү.

6. Авторларны һәм журнал таратуда зур булышлык күрсәткән кешеләрне бүләкләү өчен «Казан утлары»ның Мактау кәгазен, блокнотлар һәм түш билгеләрен (значоклар) әзерләү.

7. «Казан утлары» журналының 50 еллык юбилеен 1972 елның 22 маенда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында уздырырга.

а) газета һәм журналлардан кунаклар чакыру:

«Правда», «Литературная газета», «Литературная Россия», «Дружба народов», «Октябрь», «Наш современник» (Мәскәү), «Волга» (Саратов), «Агыйдел» (Башкортстан), «Ялав» (Чувашия), «Ончыко» (Мари АССР), «Мокша» (Мордва АССР), «Молот» (Удмуртия), «Аму-Дарья» (Каракалпак), «Сибирские огни» (Новосибирск), «Витчизна» (Украина ССР), «Азербайджан» (Азәрбайҗан ССР), «Жулдуз» (Казахстан ССР), «Ала-Тоо» (Кыргызстан ССР), «Совет әдәбияты» (Төрекмәнстан ССР), «Шарк юлдузи» (Үзбәкстан ССР).

б) элекке баш редакторларны һәм журнал ветераннарын чакыру.

в) китап укучыларны – эшчеләрне чакыру.

г) «50 ел эчендә «Казан утлары» журналы» дигән күргәзмә оештыру.

д) журнал хезмәткәрләренә бер айлык хезмәт хакы күләмендә премия сорау.

«Казан утлары» журналының баш редакторы (имза) Гариф Ахунов».

Инде килеп, акчага кагылышлы, «Смета» дип аталган мөһим документка күз салыйк:

1. Тантаналы җыелышны уздыру өчен бина арендалау – 600 (сум);

2. Концерт өчен түләү – 700;

3. Юбилей күргәзмәсен оештыру – 1000;

4. Мактау кәгазьләре, бланклар, чакыру билетлары өчен чыгымнар – 400;

5. Пакетлар әзерләү – 250;

6. Юбилей значоклары әзерләү (берсе 65 тиеннән 1000 данә) – 650;

7. Редакция хезмәткәрләренә премия бирү – 1350;

8. «Без Казаннан, Иделдән» китабы, Казан турында альбом, М.Җәлилнең сувенир медале – 150;

9. Үзәк, союз, өлкә газета һәм журналларының баш редакторларын, СССР һәм РСФСР Язучылар берлекләреннән язучылар чакыру:

а) Көнлек чыгым (30 x 5 = 150 көн x 2 сум 60 тиен) – 390;

б) Юл чыгымы (30 x 50, ике як өчен дә) – 1500;

в) Чакырылган кунаклар яшәгән кунакханәләр өчен түләү (30 x 4 көн = 120 x 1 сум 50 тиен) – 180;

10. Тукай-Кырлай һәм Кокушкинога бару өчен транспорт, Идел буйлап сәяхәт – 500;

11. В.И.Ленин, Г.Тукай, М.Җәлил һәйкәлләренә салу өчен чәчәк бәйләмнәре (венок, 3 данә x 50) – 150;

12. Тантаналы җыелыш президиумы һәм чакырылган кунаклар өчен «Казан утлары» журналының юбилей санын әзерләү (200 данә x 50) – 1000.

Җәмгысе – җиде мең тугыз йөз егерме сум (7920).

«Казан утлары» журналының баш редакторы (имза) Гариф Ахунов».

1972 елның 15 маенда (игътибар иткәнегезчә, кайбер документларда «22 май» дип күрсәтелгән) Татар дәүләт академия театры бинасында узарга тиешле Тантаналы җыелышның президиумына түбәндәге иптәшләр тәгаенләнә:

«М.Ф.Вәлиев (КПССның өлкә комитеты секретаре), А.Г.Кадыйрова (КПССның шәһәр комитеты секретаре), М.Х.Хәсәнов (ТАССР Министрлар Советы рәисе урынбасары), Б.М.Гыйззәтуллин (ТАССР мәдәният министры), ... (КамАЗдан вәкил, исем-фамилиясе күрсәтелмәгән), М.И.Мәхмүтов (ТАССР мәгариф министры), М.М.Мусин (КПСС өлкә комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе), И.Х.Хәбибуллина (Казан шәһәре башкарма комитеты рәисе урынбасары), В.П.Федоров (ТАССР Министрлар советы каршындагы матбугат комитеты рәисе), К.Г.Әхмәтов (Профсоюзлар оешмасы секретаре), В.П.Лушников («Оргсинтез» заводының генераль директоры), С.П.Кошечкин («Правда» газетасының әдәбият бүлеге мөдире), В.А.Кочетов («Октябрь» журналының баш редакторы), С.А.Баруздин («Дружба народов» журналының баш редакторы), Н.Е.Шундик («Волга» журналының баш редакторы), Тәхәви Ахтанов («Жулдуз» журналының баш редакторы), Хәмид Голәм («Шарк йолдызы» журналының баш редакторы), Әсгать Мирзаһитов («Агыйдел» журналының баш редакторы), Р.М.Дашкин («Кызыл Таң» газетасының баш редакторы), А.Н.Бенинсон («Советская Россия» нәшриятының бүлек мөдире), Г.Р.Кәримова («Детская литература» нәшриятының бүлек мөдире), М.Хәсәнов («За Родину» газетасының баш редакторы), Гариф Ахунов («Казан утлары» журналының баш редакторы), Гази Кашшаф (юбилей комиссиясе рәисе, язучы)».

«Казан утлары»ның 50 еллыгы уңаеннан китап сөюче укучылар белән конференцияләр түбәндәге районнарда уздырылырга тиеш була:

1. Әлмәт районы – гыйнвар, 1972; җаваплы – Р.Фәйзуллин;
2. Арча районы – февраль, 1972; җаваплы – Г.Ахунов, Я.Халитов;
3. Кукмара районы – февраль, 1972; җаваплы – Л.Ихсанова;
4. Азнакай районы – февраль, 1972; җаваплы – Мәхмүт Хәсәнов;
5. Лениногорск районы – февраль, 1972; җаваплы – Ш.Бикчурин;
6. Актаныш – март, 1972; җаваплы – Ф.Шәфигуллин;
7. Балтач районы – март, 1972; җаваплы – В.Нуруллин;
8. Яшел Үзән районы – март, 1972; җаваплы – М.Хәмитов;
9. Сарман районы – апрель, 1972; җаваплы – Хәниф Хәйруллин;
10. Алабуга районы – февраль, 1972; җаваплы – Э.Касыймов, Т.Галиуллин;
11. Казан, Үзәк китапханә – май, 1972; җаваплы – Л.Ихсанова, Н.Арсланов.

«Казан утлары» журналының баш редакторы (имза) Гариф Ахунов». ■

Безнең мирас №7 июль 2022

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

ШАБАЙ МИН (1913-1963)

Татар язучысы Мин Гариф улы Шабаев 1913 елның 28 апрелендә Башкортстанның Кушнаренко районындагы Каратәкә авылында туган.

«1941-1954 нче елларда Себер якларында һәм Себернең төньяк өлкәләрендә яшәгән» Мин Шабайның шул еллардагы чын тормышы турында танылган язучы, сталинизм дошманы Варлам Шаламов (1907-1982) язып калдырган. Аның белән ул 1946 елны Магаданда, ГУЛАГның фельдшерлык курсларында таныша. Шабайны ул контрреволюцион эшчәнлек өчен хөкем ителгән татар язучысы буларак сыйфатлый. Аның урысчаны яхшы белүен билгеләп уза. Срогын тутыргач һәм сөрген шартларына чыгарылгач, Мин Шабайның сәүдә өлкәсенә кереп китүе турында да яза. Ул ике кат хөкем ителә: 1942 һәм 1950 нче елларда. 1955 елда аклана. Мин Шабай 1963 елның 5 сентябрендә Казанда вафат булды.

ШӘМИЗАДӘ ӘШРӘФ (1908-1978)

Атаклы кырымтатар шагыйре Әшрәф Габдерахман улы Шәмизадә 1908 елның 21 июнендә Кырымның Кизләү (Евпатория) каласында туган.

1937 елда, астыртын әләк нигезендә, аны Кырымтатар язучылары берлегеннән чыгаралар. 1941 елда гаебен таба алмыйча азат итәләр. 1949 елда сәяси гаеп тагып, Әшрәф Шәмизадәне тагын кулга алалар. 1955 елда ул, акланып, иреккә чыгарыла. Әшрәф Шәмизадә калган гомерен Үзбәкстанда уздыра һәм шунда 1978 елның 11 мартында вафат була.

ШӨНАСИ ГАБДУЛЛА (1885-1938)

Химия һәм физика фәннәре мөгаллиме Габдулла Шөнаси (яки Шнаси, Шинаси; Габдулла Сабир улы Ибраһимов) Оренбург губернасындагы Җаек (Троицк) каласында туган.

1938 елның 3 ноябрендә аны пантюрикзмлыкта гаепләп атып үтерәләр. Каберенең кайдалыгы мәгълүм түгел. 1958 елда реабилитацияләнә.

Ахыры. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

ШӘФИГУЛЛИН ФАИЛ (1939-1982)

Татар язучысы Фаил Хафиз улы Шәфигуллин 1939 елның 18 маенда Татарстанның хәзерге Яшел Үзән районына караган Карашәм авылында туган.

Ул 1982 елның көзендә эштән кайтып килгәндә фаҗигале рәвештә һәлак булды. Әдипнең үлемендә милиция хезмәткәрләренең гаебе бар дигән фараз яши. Шул сәбәплеме, җинаятьчеләрнең кем булуы ачыкланмады (әллә ачыкларга теләмәделәрме?!).

ЯРУЛЛИН ФӘРИТ (1914-1943)

Татар композиторы Фәрит Заһидулла улы Яруллин Казанда туган.

1941 елда ул Ульяновскидагы җәяүле гаскәриләр училищесын тәмамлый, лейтенант дәрәҗәсен ала. 1942 елда исә очраклы рәвештә дусты-остазы Генрих Литинский белән очраша. Танылган профессор Фәрит Яруллинны Мәскәү консерваториясенең хәрби дирижерлык факультетына күчерү хакында югары командованиегә үтенеч хаты яза. Әмма, рөхсәт хаты килеп җиткәндә, татар композиторын янәдән фронтка озаткан булалар.

Фәрит Яруллин 1943 елның 17 октябрендә Белоруссиянең Витебск өлкәсендәге Дубровина районында барган бәрелешләрдә һәлак була. Ул озак вакыт хәбәрсез югалучылар исемлегендә йөри, кабере 40 елдан соң гына табыла. Композиторның җәсәде Новая Тухиня исемле авылдагы Туганнар каберлегендә җирләнгән.



ЯРУЛЛИН ФӘНИС (1938-2011)

Шагыйрь, прозаик һәм драматург Фәнис Яруллин (Фәниз Гатаулла улы Яруллин) 1938 елның 9 февралендә Татарстанның Баулы районындагы Кызылъяр авылында туган.

1957 елда ул Совет Армиясе сафларына чакырыла. Армиядә һава укчы радистлары мәктәбендә укый, спорт белән мавыга. Фәнис Яруллин, спорт күнегүләренең берсендә турниктан егылып, имгәнеп, гомерлеккә йөри алмас хәлдә кала.

Язучы 2011 елның 8 декабрендә Казан шәһәрендә вафат булды.

Текстны басмага
***Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Безнең мирас №7 июль 2022

Миләш

Миләш сүзен галимнәр фин-угыр телендәге пәлэз, пәлеш сүзләреннән кергән диләр. Ничек кенә булса да, без бу сүзне үзебезнеке дип исәплибез, әле аның башка сөйләшләрдәге вариантларын да яратып кабул итәбез. Мәсәлән, себер татарларының бер өлеше аны мыцыр дип атый, ә ләмберә мишәрләре аны йомшак итеп мәләш диләр.

Мәгълүм булганча, миләш ботагын яңа туган балаларның башлыкларына тагалар, кулларының беләзек өлешендә дә еш кына миләш ботагы кисәген күргәлибез. Бу миләш сабыйны күз тиюдән саклый дигән ышануга бәйле.

Татар авылларында йорт каршына утыртылган миләшләрне еш күрергә була. Монысы да йортка күз тимәсен, җәй башында хуш исле чәчәкләре, көзгә кергәч, менә шушы кып-кызыл фонарьларны хәтерләткән тәлгәшләре белән хөсетле кешеләрнең күз явын үзләренә тартып торсын, дип эшләнә.

Ул гына да түгел әле, беренче баланы бишеккә салгач, бишек кыршавына куакланып үсүче миләш ботагын элгәннәр. Миләш ботагының да тармаклысын эзләргә тырышканнар. Бу әлеге гаиләдә бишектәге бала артыннан шушы миләш тармаклары санынча башка сабыйлар да тусын дигән теләк белән башкарылган.

Кайбер якларда җаны урын тапмый якыннары күзенә өрәк булып күренеп йөргән кешенең каберенә дә, догалар укып, җиде чатта үсүче миләшнең ботагын күмү гадәтен дә ишеткәнебез бар. Бу миләшнең мәңгелек дөнья белән фани дөньяны тоташтырып тору сәләте бар дип ышануга бәйле.

Безнең халык миләшне табышмакларында да, җырларында да зурлый. Мисалга менә мондый табышмакны китерик әле:

Җиде юлның чатында
Тулган айтирәк утыра.
Канатыннан кан тамып,
Каргый-тирги утыра.

Миләш кенә димик бу агачны, дуслар! Хикмәтле ул, үзенә күрә бер сере бар аның!

*Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе **Фәнзилә Җәүһәрова**) белән берлектә әзерләнде.* ■

Миләш турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Безнең мирас №7 июль 2022

Миләш дәвалый

Иң әүвәл мәшһүребез Каюм Насыйриның «Хәвасе нәбатат» («Шифалы үләннәр») китабына игътибарыбызны юнәлтик әле:

«Миләш (русча – рябина красная, гарәпчә мәшмулла диләр) – күренекле агач. Җиләге кызыл була. Эч авырткан-га бик яхшы. Күп халык моны ашказаны авыруыннан куллана. Миләш җиләгенең суы азрак эчне йомшарта. Кайрысы да файдалы. Башка ис тигәндә миләш җиләге ашасаң, башны саф итәр, исне чыгарыр. Миләш хакында башка риваятьләр дә бар».

Миләштә аскорбин кислотасы күп. Шуңа ул температураны төшерергә булыша, салкын тигәндә файдасы зур, шул исәптән, ютәл һәм томаудан да ярдәм итә.

Миләштә ашкайнату эшчәнлеген яхшыртучы пектиннар бар. Аны чәйгә кушып эчәргә яки төнәтмәсен ясарга кирәк.

А витамины микъдары буенча миләш кишердән калышмый. Көн саен бер аш кашыгы миләшне (кайнатмасын да ярый) йогырт яки катыкка кушып ашый аласыз. Күз күреме өчен аеруча яхшы.

Миләштә бактерияләр, гөмбәчекләр үрчүгә соткарлык тудыручы җиләк-җимеш кислоталары күп.

Анда шулай ук нерв системасын ныгытырга ярдәм итүче, стресслардан саклаучы, йокыны яхшыртучы В төркеме витаминнары бар.

Миләш канның оючанлыгын яхшыртучы К витаминына да бай. Әмма тромбоз куркынычы булганда, аны ашамагыз.

Әчелеге бетсен өчен, миләшне кыраудан соң җыялар. Мондый җимешне шундук эшкәртергә кирәк. Суык төшкәнче җыйган миләшне берничә тәүлек туңдыргычта тотып тәмләндерергә була.

Медицинада миләш җимешләрен азканлылык белән авырган кешеләргә кулланырга киңәш ителә. 2 чәй кашыгы җимешкә 2 стакан кайнар су салып, төнәтмә ясап эчәләр. Бераз гына шикәр дә кушарга ярый. Көн дәвамында азазлап 3-4 тапкыр эчәргә мөмкин.

Ашказаны сыекчасының әчелеге аз булганда, ашарга 20-30 минут кала, 1 чәй кашыгы миләш согы эчәргә кушалар. Сок үт кудыру үзлегенә дә ия.

Миләштән төрле кайнатмалар да әзерлиләр.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Миләш тәлгәше

Миләш кайнатмасы

Безнең мирас №7 июль 2022

Түнтәрмә – куандырырлык тәмгә!

«Иртәнге ашны үзең аша, көндезгесен дустың белән бүлеш, ә кичке ашны дошманыңа бир» дигән халык әйтемендә бик дөрес һәм файдалы мәгънә ята. Иртәнге аш – кешенең рационында иң мөһим ризык кабул итү гадәтенең берседер. Ул безне көндәлек энергия белән тәэмин итә, кәефне күтәрә һәм сәламәтлеккә уңай йогынты ясый. Бу туклану гадәтенең әһәмияте безнең заманда гына түгел, ә тарих битләрендә сакланып калган борынгы халыклар арасында да актуаль булган. Шуны истә тотып, борынгы татарлар да иртәнге ашка зур игътибар биргәннәр. Иң беренче чиратта, бу аларның аш-суларында ачык чагыла.

Татар хатын-кызларының махсус аш-су китапларында иртәнге ашка яраклы тәмтомнар, кабымлыклар аерым бүлек булып язылган, чөнки алар ирләрен һәр иртәдә мул табын белән эшкә озатырга тырышканнар. Бу нигъмәтләргә мичтә пешкән коймак, төче һәм әче камырдан ризыклар, сөтле чәй, бал-май яисә төрле ярмалардан боткалар, тавык йомыркасыннан әзерләнгән кабымлыклар керә. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: татар халкының аш-суларында тавык йомыркасы бик еш кулланыла. Аны суда пешергәннәр, табада кыздырганнар, камырга кушканнар, төрле ашамлыкларга өстәгәннәр. Тавык йомыркасыннан әзерләнгән иртәнге ашлар рәтенә, һичшиксез, түнтәрмәне дә кертергә мөмкин.

Түнтәрмәне татарча йомырка тәбәсе дип тә әйтәләр, әмма бу дөрес түгел, чөнки тәме, кыяфәте һәм пешерү рәвеше ягыннан әлеге ризыклар бер-берсеннән аерылып тора. Без түнтәрмәне Юныс Әхмәтҗанов авторлыгындагы «Татар халык ашлары» китабындагы рецепт буенча әзерләп, тәмен татып карау бәхетенә ия булдык. Сез дә безгә кушылыгыз!

Кирәкле ингредиентлар:

- 5-6 йомырка;
- 200-300 мл сөт;
- 60-80 г манный ярмасы яки он;
- 100 г атланмай;
- кирәгенчә тоз.

Эш барышы:

1. Йомырканы тирән савытка сыталар да яхшылап туглыйлар, аннары сөт, эреткән атланмай, тоз өстәп, барысын бергә яхшылап болгаталар.
2. Манный ярмасы яки он өстәп, куе каймак кебек булганчы тагын туглыйлар.
3. Катнашманы майлы табага бушаталар һәм ут өстенә куялар. Куера башлагач, ут өстеннән алып, 4-5 минут духовкада тоталар.
4. Әзер түнтәрмәнең өстен майлап, табынга чыгаралар. (Түнтәрмәне кыек шакмаклап кискәләп тә табынга куярга була.)

Нәтиҗәдә, түнтәрмә иртәнге аш өчен бик туклыклы, әзерләргә җиңел һәм күп вакыт таләп итми торган сый булып чыкты. Традицион татар ашлары өчен майны күп итеп куллану хас, аларга зур күләмдә терлек һәм үсемлек майлары кушылган. Түнтәрмә дә искәрмә түгел. Шуңа атланмай күләмен ихтыяҗларыгызга, сәламәтлегегезгә карап кулланырга киңәш итәбез.

Түнтәрмә, татар халык ашы буларак, Татарстан Республикасындагы Әтнә районы авылларында, бигрәк тә Ташчишмә авылында бүгенге көнгә кадәр сакланып калган һәм әле дә табынга куела. Димәк, якыннарыгызны туклыклы һәм тәмле иртәнге аш белән куандырырга теләсәгез, игътибарыгызны түнтәрмәгә юнәлдерә аласыз.

Сәхифәне ***Айзилә Сабирова*** *әзерләде.* ■

Түнтәрмә әзерләү турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Көлке куа килә...

Гамил Афзал.
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

Гамил Афзал (1921-2003)

Өф-өф итеп...

Малай туды безнең. Нинди шатлык!
Икебезгә уртак бәхет таптык.
Сокланабыз аңа исебез китеп,
өф-өф итеп,
өф-өф итеп.

Егет үстерәбез туган илгә,
Мондый асыл малай бездә генә!
Тирбәтәбез йоклаганын көтеп,
өф-өф итеп,
өф-өф итеп.

Затлы кием, ефәк аңа гына,
Тәмле-татлы нәрсә тамагына.
Тәпи йөри башлый яңа гына
тып-тып итеп,
тып-тып итеп.

Малай үсә, буе, яше арта,
Бәби чагы инде калды артта.
Көн диванга ятып «Казбек» тарта,
пыф-пыф итеп,
пыф-пыф итеп.

«Әни, давай, минем битне юдыр,
Әни, давай, миңа шиблет кидер,
Әти, давай, папироска йөгер,
лап-лап итеп,
лап-лап итеп!»

Йөгерәсең, кала тузан тузып,
Автомобильләрне юлда узып,
Магазинга, магазинга тизрәк,
«Казбек» кирәк,
«Казбек» кирәк!

Соңгы мода костюм тапты уйлап,
Газиз парәң булгач, бостон юллап,
Йөгерәбез икәү урам буйлап,
анда лап-лап,
монда лап-лап...

Укырга җибәрдек, бармый анда,
Безнең сүзне алмый искә-санга,
Коньяк эчә хәзер ресторанда,
голт-голт итеп,
голт-голт итеп.

Шоколадлар белән прәннек ашый,
Акча сорап безгә допрос ясый,
Бирми торсаң, хәзер кыйнап ташлый,
дөп-дөп итеп,
дөп-дөп итеп.

1956

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Төгәллек

(Саба мәзәге)

Терлекчелекне генә түгел, анда эшләүчеләрнең яшәешен, эчке дөньяларын биш бармагы кебек белә иде Мәхмүт Сөнгатуллин. Берсендә колхоз рәисе Искәндәр Нигъмәтҗанов сүз уңаеннан болай дип сорый:

– Мәхмүт абый, безнең сыер савучы фәлән апаның декретка чыгарга күпме вакыты бар әле?

– Ике ай да өч көн, Искәндәр Галиханович, – ди, күзен дә йоммыйча, Мәхмүт ага.

– Ә дуңгыз караучы фәлән апаныкы?

– Аныкы бүгеннән соң төп-төгәл егерме җиде көн генә калып бара инде...

Гәрәй Рәхим (1941-2021)

Замана баласы

Вокзалда бер бәләкәй малай һаман бер чибәр генә ханым белән уйнарга итә: йә итәген тарта, йә чәбәкләп китә. Әнисе малайны ачулана:

– Шаярма апаң белән!..

– Мин бер китаптан укыдым, – ди малай, һич тә исе китмичә, – анда, матур апалар белән шаярырга һич тә тыелмый, дигән.

Гәрәй Рәхим.
Зөлфәт Хәйруллин шаржы

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Әхмәт Рәшит (1936-2020)

Банан тәмле буламы?

Ярātканы Искәндәрнең –
Карбыз, компот һәм... банан.
Шундый тәмле-томлы гына
Ашамакчы ул һаман.

Ярый инде – компотлар күп,
Карбызын да табарсың.
Әмма гел генә, банан, дип,
Кая чыгып чабарсың?!

Кыяр, кишер, кәбестәләр
Тулып ятса да монда,
Банан кибетләре фәкать
Бананстанда гына!

Ә анда – Бананстанда
Малайлар үсмиләр, ди.
Бөтенесе кәрләләр, ди, –
Лилипут төслеләр, ди.

Алар ит, икмәк, бәрәңге
Гомер буе күрми, ди.
Банан, бик тәмле булса да,
Тамакны туйдырмый, ди.

Банан үстергән әтиләр
Бары газап чигә, ди –
Өйдә малае ач булгач:
«Бананы нигә соң?» – ди...

Сөйләдем дә Искәндәргә
Шундый-шундый хәлләрне,
Ул андагы үсми калган
Малайларны җәлләде.

Банандамыни соң хикмәт!
Бөтен хикмәт – икмәктә.
Таза малай булыйм, дисәң,
Аш та аша, икмәк тә!..

Әйдәгез, уйныйбыз!

Без, без, без идек...

Уйнаучылар түгәрәк хасил итеп утыралар. Бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш кулларын бергәләп күтәреп-төшереп болай диләр:

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек,
Базга төштек – бал ашадык,
Келәткә кердек – май ашадык,
Өйгә мендек – өйрә эчтек,
Бер тактага тезелдек,
Таң атканчы юк булдык,
Авызыңны яп та йом!

Шуннан соң уйнаучыларның берсе дә авызын ачмаска, көлмәскә, сөйләшмәскә тиеш. Алар бер-берсен көлдерү өчен төрлечә кыланалар, күз-йөз белән төрлечә ымнар ясыйлар. Кем элек авызын ача йә көлеп җибәрә, аңа «җәза» (шигырь сөйләү, җырлау, бию һ.б.) бирәләр.

Бар иде бер Давыт...

(Такмаза)

Бар иде, ди, бер Давыт,
Җиккән, ди, сукыр тавык.
Төягән, ди, табак-савыт,
Салган, ди, ярма,
Җиккән, ди, кабык арба.
Барадыр иде, ди, чабып,
Абынды, ди, сукыр тавык.
Китте, ди, Давыт
Арба белән авып.
Ярылды, ди, арба,
Коелды, ди, ярма.
Тотынды, ди, Давыт
Җыярга ярма.
Җыя, ди, Давыт,
Чүпли, ди, тавык,
Бетми, ди, ярма,
Юнәткәнче арбаны,
Җыелды, ди, карга.
Чүпләде-бетте, ди, бар да.

Санамыш

Әке-бәке,
Эт колагы сәке,
Син дә бабай, мин дә бабай,
Печәнлектә акча санай.
Ничә булды?
Йөз булды.
Алпык-салпык,
Сары куян, әйдә, чык!



*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ИЮНЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Июньдә Уфада аталы-уллы Нурмөхәммәт һәм Илдар Хөсәеновларның «Бөек Татариянең контурлары: татар исеме белән аталган» китабы (1 нче китап: «Дөньяда tatar сүзе нигезендә ясалган топонимнар, терминнар һәм табигать яки җәмгыятьтә йөртелгән башка төр атамалар. Бөек Татария карталарда. Бөек Татариянең атрибутикасы. Чыңгызхан портреты. Татария – борынгыдан киләчәккә») дөнья күрде.

● 6 июньдә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы бөек рус шагыйре А.Пушкин һәйкәле каршында олуг әдипнең туган көне уңаеннан шигъри митинг узды. ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин А.Пушкин һәйкәленә чәчәкләр салды.

● 10 июньдә, Идел буе Болгарында ислам динен рәсми рәвештә кабул итүгә 1100 ел тулу һәм Касыйм шәһәренең 870 еллыгы уңаеннан, Рязань өлкәсенең Касыйм шәһәрендә Казан ханбикәсе Сөембикәгә һәйкәл ачу тантанасы булды.

Тарихи тантанада Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Ва-

сил Шәйхразыев, Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти шәех Равил хәзрәт Гайнетдин, РФ Дәүләт Думасы депутаты, Россия Герое Андрей Красов, Рязань өлкәсе хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары Анна Рослякова, РФ Дәүләт Думасы депутаты, «Татар федераль милли-мәдәни автономиясе» советы рәисе Илдар Гыйльметдинов, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башка дәрәҗәле кунаклар катнашты.

● 15-16 июньдә Г.Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театрында Идел буе Болгарында ислам динен рәсми рәвештә кабул итүнең 1100 еллыгына багышланган премьера – «Йосыф» спектакле (режиссеры – Ренат Әюпов) тәкъдим ителде.

● 16 июньдә Милли китапханәдә «Интертат»ның 20 еллыгы уңаеннан шигъри-

ят кичәсе үтте. Шагыйрә Йолдыз Миңнуллина алып барган әлеге кичәдә, Марсель Галиев, Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров, Рәдиф Гаташ, Газинур Морат, Илсөяр Иксанова һәм Рәмис Аймәт кебек күренекле шагыйрьләребез белән беррәттән, Рүзәл Мөхәммәтшин, Луиза Янсуар, Лилия Гыйбадуллина, Гөлүсә Батталова, Фәнил Гыйләҗев, Рифат Сәлах, Булат Ибраһим, Резеда Гобәева, Ләйлә Фаяз һәм Гүзәл Закирова кебек талантлы яшь каләм әһелләре дә чыгыш ясады.

● 18 июньдә Ульяновскида Федераль Сабан туе үтте. Әлеге күркәм бәйрәмгә Россиянең төрле төбәкләреннән милләттәшләребез килде. Бәйрәм кунаклары арасында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россиянең баш мөфтие Тәлгат хәзрәт Таҗетдин, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башкалар бар иде.

● 18 июньдә Минзәләдә, Татарстандагы ун дәүләт театры катнашында, ундүртенче театраль Сабан туе булып узды. Ул ТР Президенты, ТР Мәдәният министрлыгы, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, С.Өметбаев исемендәге Минзәлә театры һәм Минзәлә район җитәкчелеге ярдәме белән оештырылды.

● 22-25 июньдә Саха Республикасында, татар әдипләре Р.Зәйдулла, Ф.Сафин, Ф.Җамалетдинова, Х.Ибраһим, Р.Сабыр, И.Иксанова, Р.Галиуллин, Р.Мөхәммәтшин, Л.Гыйбадуллина һәм Л.Шәех, галим И.Һадиев, ТР Мәдәният министрлыгы хезмәткәре, галим А.Фәйзрахманов катнашында, Татарстан көннәре булып узды. Әлеге күркәм чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм, Якутия башлыгы Айсын Николаев белән бергә, якут язучысы Платон Ойунский һәйкәленә чәчәкләр салды. ■

МИРАСВОРД

Җөри авылында Питрау бәйрәме үтә торган алан

... Насыйри

Фәхрелислам ... (татар балалар язучысы)

Реформа (иск.)

Кәҗә бәтие (диал.)

Керәшеннәрнең дәүләт фольклор ансамбле

Гарәп язуындагы бер стиль

Композитор ... Даутов

Шәһәр яки авылның бер мәчеткә караган өлеше

Почмак үлчи торган приборда градусларга бүленгән түгәрәк

... акыл белән

Организмның мөһим өлешен тәшкил иткән матдә

Борынгы Рим императоры

Того башкаласы

Тибетның тарихи мәркәзе

Немец микробиологы

Чишмәле ... (Әтнә районындагы авыл)

Аштагы камыр кисәкләре

Матур, күрекле (бор.)

Химик элементның иң кечкенә кисәге

Фин-угыр халкы

Сөенү, канәгатьләнү хисләрен белдерүче ымлык

Согуд Гарәбстанындагы изге кала

Сахалин өлкәсендәге шәһәр

Ачы тәтен

Хәбир Ибраһимның 2001 елда чыккан китабы

Караиделнең сул кушылдыгы

«... ничек чыныкты» (Николай Островский)

Акча, тәңкә (иск.)

Агулы тропик агач

Краснодар краендагы курорт-шәһәр

Мичкә тишегеп томалый торган бөке

Эвальд ... (эстон композиторы)

... Эрнандес (Аргентина шагыйре)



2016 елгы Питрауда баш батыр калган көрәшче

Кытай табасы

Кардиохирург ... Бокерия

Иш янына ...



Берләшү, туплану

Умберто ... (италиян язучысы)

Сагыйть ... (башкорт язучысы)

6 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Дилә, итәк, сөкә, иске, Емеля, Гази, изен, «Мират», тияк, «Уку», арча, Рид, Җаек, иде, им, санам, Иркә, ахун, Наис, Чат, балет, мавр, АКМ, ыру, «Ялла», Ниш.
Өстән аска: Мурзин, мая, Еники, Рада, Рудаки, Вил, Досаева, әсәр, Таҗи, Ликия, «Рамай», Әтәс, илче, Аксу, Баян, Акъегет, анчак, «Аникин», Алмыш, Данте, «Илкәем», «Труд».

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»

елъязмасы / июль



Голҗа шәһәре күренеше. 2011 ел. Бүгенге көндә Кытай Халык Республикасының Сиңҗаң-Уйгыр автоном районына карый. ***Марат Закир фотосы***

665 ел элек (1357)

Алтын Урдада озак вакыт котырган чума авыруы тына төшә һәм Җанибәк хан җәй урталарында, 300 меңлек гаскәр туплап, яу сәфәренә кузгала. Яу бик уңышлы башлана, татар гаскәре Тимер Капу (Тимер Капка – Дербент каласын төркиләр шулай дип йөрткән) белән Ширванны ала. Яулап алган биләмәләр белән идарә итәргә Җанибәкнең улы Бирдебәк углан билгеләнә.

640 ел элек (1382)

Мәскәүне яулап алганнан соң, башында Туктамыш хан торган Алтын Урда гаскәре, берничә зур хәрби берләшмәгә әверелеп, төрле тарафка юнәлә һәм урыс калаларын «йөреп» чыга. Шул рәвешле, Владимир, Суздаль, Переяславль, Юрьев, Звенигород, Можайск, Боровск, Руза, Дмитров шәһәрләре вә янә бихисап авыл-салалар, җирләр кабаттан Бөек Сарай хакимияте карамагына кайта.

470 ел элек (1552)

3 июльдә 150 меңлек урыс гаскәре Казан тарафына кузгала...

300 ел элек (1722)

28 июльдә Россиядә беренче төрки-татар басмасы – Петр Iнең 1772 елгы манифесты бастырылып чыгарыла.

160 ел элек (1862)

Күренекле галим, төрки дөнья белгече Василий Радлов (Фридрих Вильгельм Радлов, 1837-1918) җәен Шәркый Төркестанның Голҗа шәһәренә сәяхәт кыла. Ул, ошбу сәяхәтен тасвирлаганда, биредә татарларның бик күп булуын, байтагының сәүдә эшендә уңыш казануын, аларның башка милләтләр белән дус-тату яшәвен, Русиядәгегә караганда, үзләрен шактый иркен вә азат итеп тоюларын ассызыклый.

105 ел елек (1917)

Акмәчет (Симферополь) шәһәрендә июль аеннан атнасына ике мәртәбә «Кырым учагы» дип аталган газета чыга башлый. Каширләре – Мөхәммәт һәм Вәли Ибраһимовлар, мөхәррире – Гарифзадә Хилми.

80 ел элек (1942)

4 июльдә Төньяк-көнбатыш фронтта атнага ике тапкыр татар телендә «Ватан өчен» газетасы чыга башлый. Редакциядә язучылар Г.Разин (Гомәр Бәширов) һәм Мирсәй Әмир озак вакытлы иҗат командировкасында булалар.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Июль 2022

И останется в мире слово моё...: Ямаш Игеней.

Историческое наследие: «Стамбульские письма». Ф.Карими; «Из истории одного строительства». А.Казаков; «Из дневника Б.Урманче».

Художественное наследие: «Барабан чей, балалайка кому принадлежит?» А.Чанышев.

Татарский мир: «Откуда появился термин «крященные татары?» Р.Ахмедьянов; «Выдающийся ученый и педагог». Г.Шакирова.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими; «Ислам. Религиозный словарь»; «Уроки религии». С.Бикбулат.

Литературное наследие: «Поэт Сирин и Мухаммед Парсин». А.Шарипов; «А годы летят и летят...» Ф.Зариф; «Стихи Егора Уткина».

В глубинах памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!»

Природное наследие: «Рябина».

Рәссам әдипләр

Мәшһүр Александр Сергеевич Пушкинның, каһарман шагыйребез Муса Җәлилнең, үлемсез әсәрләр иҗат итүдән тыш, рәсем ясау белән дә мавыгулары мәгълүм. Сөекле Тукаебыз рәсем-сурәт ясамаган ясавын, әмма аның үз китапларын яисә матбугатта басылган шигырь-язмаларын бизәүче рәссамнарга иллюстрацияләрне ничегрәк ясарга кирәклеген өйрәткәнлеге билгеле. Олуг драматургыбыз Галиәсгар Камал (1879-1933), шагыйрь Нури Арслан (1912-1991), Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов (1925-2000), күренекле режисссер Празат Исәнбәт (1927-2001) тә мөмкинлекләре булган чакларында рәсемнәр һәм шаржлар ясаган.

Бүгенге әһле каләм ияләре арасында да рәсем сәнгате белән шөгыльләнгән әдипләр бихисап. Мәсәлән, Татарстанның халык шагыйрьләре һәм язучылары Ренат Харис, Зиннур Мансуров, Марсель Галиев, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Ләбиб Лерон, прозаиклар Әхәт Мушинский, Дания Гайнетдинова һ.б. – шундыйлардан.

Басмабызның ошбу санындагы «Безнең мирас» галереясы»н Мамадыш районының Түбән Ушмы авылы тумасы, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров ясаган Рабит Батулла портреты белән ачып җибәрәбез. Кем белә, танылган шәхесләребез ясаган ул рәсемнәр, портретлар һәм шаржлар, Аллаһ насыйп әйләсә, киләчәктә аерым китап булып басылып чыгар... Амин, шулай була күрсен!

«Безнең мирас» галереясы

«Моңга ою. Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла». 2022 ел.
Кәгазь, карандаш. 42×30. Зиннур Мансуров эше

ТЫРЛАУ БУЙЛАРЫНДА ПИТРАУ

Илнар Төхфәтов фотолары

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.